әхрелислам
гиев

мәрхәмәт

Фәхрелислам Агиев

МӘРХӘМӘТ

Хикәяләр һәм әкиятләр

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1990

ББК 84(2Р-Тат)-4
А 29

Төзүчесе ФАТЫЙМА ИБРАҺИМОВА

Агиев Фәхрелислам

А 29 Мәрхәмәт: Хикәяләр һәм әкиятләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.—111 бит.

Бу китапка XX йөз башы балалар язучысы, журналист, педагог Ф. Агиевның «Ак юл» журналында басылган әйбәт хикәяләре, әкиятләре сайлап алынды.

ISBN 5—298—00468—7

А $\frac{4803560201-226}{М\ 131(03)-90}$ 163—90 **ББК 84(2Р-Тат)-4**

ISBN 5—298—00468—7

© Фатыйма Ибраһимова, төзү, 1990
© Искәндәр Галләмов рәсемнәре, 1990

ТӨЗҮЧЕДӘН

Хөрмәтле укучым! Әлеге китап сиңа беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Аның авторы — Фәхрелислам Нигмәтулла улы Агиев. Бу исем сиңа әллә ни таныш түгелдер. Моңа кадәр безнең күп кенә язучыларыбыз күләгәдә калып килде, әсәрләре укучыга барып ирешмәде. Ф. Агиев шундый язучыларның берсе иде. Хәзер заманалар үзгәрде, үткәндәге мирасыбызга игътибар артты. Ф. Агиевның да биографиясе ачыкланды. Ул 1887 елның 12 мартында хәзерге Мордва республикасына керә торган Тенеш авылында туган, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларның замандашы, алар белән бергә йөргән кеше.

Ф. Агиев күбрәк балалар өчен яза, гомеренең зур өлеше балалар арасында үтә. Ул Казанның рус-татар мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

1905 елгы революциядән соңгы елларда татарлар яши торган зур шәһәрләрдә кечкенәләр өчен әдәби кичәләр үткәрү гамәлгә керә. Бу кичәләрдә малайлар һәм кызлар төрле уеннар уйныйлар, күмәкләшеп җырлыйлар, әкият персонажлары булып, тамашалар күрсәтәләр, Казанда мондый кичәләрне оештыруда нәкъ менә Ф. Агиев башлап йөри, мәктәп укучыларыннан хор группалары төзеп, төрле кичәләрдә чыгышлар ясый.

Ул елларда җәйнең матур көннәрендә шәһәр урамнарында ак чәчәк сату оештырыла. Бу көннәрне «Ак чәчәк бәйрәме» дип атап йөртәләр. Шуннан җыелган акча үпкә чире белән авыручы ярлы балаларын дәвалауга тотыла. Ф. Агиев шушы «Ак чәчәк бәйрәме» комитетының да әгъзасы була.

Ф. Агиев патша хөкүмәте хакимлек иткән караңгы елларда өч ел буе (1913—1916) балалар өчен «Ак юл» исемле журнал чыгарып килә. Аның бу хезмәте аерым игътибарга лаек. Журнал үз вакытында татар дөньясын шаулата. Кечкенә укучылар Фәхрелислам абыйларына рәхмәтләр әйтеп хатлар язалар. Язмаслык та түгел: андагы рәсемнәргә сокланмаска мөмкин түгел, ә ул матур рәсемнәр Мәскәүдән эшләтеп кайтарыла.

Журнал, татар язучыларының әсәрләре белән бергә, рус, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларыннан үрнәкләр бирә, рәсем ясарга өйрәтү дәресләре оештыра, уен, табышмак почмаклары ача. Редакция, аерым саннарга өстәп, укучыларга бушлай китаплар бүләк итә. Ф. Агиевның «Балалык вакыты», Ф. Әмирханның «Нәҗип» исемле хикәяләре беренче мәртәбә «Ак юл»ның бүләк китаплары булып дөнья күрә.

Ф. Агиев журналның махсус бер санын Г. Тукайның үлеменә багышлый, шунда беренчеләрдән булып шагыйрьнең биографиясен урнаштыра. Һәр санда диярлек хикәяләр, әкиятләр бастыра. Әсәрләрендә хайваннар, кошлар, җәнлекләр дөньясы эченә алып керә, алар арасында усалларын, хәйләкәрләрен, ялкауларын, кеше ярдәменә мохтаҗларын күрсәтә, әлеге җан ияләренә кешегә яратып караучы миһербанлы балаларны, йомшак күңелле мөла-

ем әбиләрне, халык әкиятләрендә еш очрый торган акыл иясе ярдәмчел картларны төп геройлары итеп сайлый. Һәрхәлдә, Ф. Агиев иҗаты — изгелек эшләргә рухландыра торган кешелекле иҗат. Аның шулай булуы табигый дә. Әдип үзе дә йомшак күңелле, бала җанлы кеше булган. Язмаларында да кечкенә дусларына «туганнарым, сөеклеләрем» дип кенә эндәшә. Әгәр ул бала җанлы булмаса, акча кытлыгы кичереп, өч ел буе журнал чыгарып килер идеме, әдәби кичәләр, хор группалары оештырып, мәшәкатьләнеп йөрер идеме? «Безнең кан-кардәшләребез, дин кардәшләребез булган шул ятимнәр күңелләре ярсыган, күзләре яшь белән тулган килеш урам чатларында, былчырак эчендә боегышып, теләнеп йөргәндә — мин ничек шатланыйм?!» — дип, күңелле бәйрәм көннәрендә шулай ачынып әйтә алыр идеме? Юк, билгеле!

Ф. Агиев балаларның белем дәрәҗәләрен күтәрү турында кайгыртып, дәреслекләр дә төзи. Аның башлангыч класслар өчен китабы һәм әлифбасы бар.

Октябрь революциясеннән соң ул күбрәк Мәскәүдә яши. СССР Мәгариф халык комиссариатында методист-инструктор булып эшли. СССР халыклары Үзәк нәшриятында татар секциясе секретаре, Үзәк күчмә татар театры җитәкчесе вазифасын башкара. Әдәби иҗат эшен дә дәвам иттерә. Балалар өчен «Хикәяләр җыентыгы» бастырып чыгара. Тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнә.

Ф. Агиев шәхес культы чоры корбаны булды. Туганнарының әйтүенә караганда, ул ике мәртәбә кулга алынган. Беренчесендә Ак диңгез — Балтик каналы төзелешендә эшләп, срогын тутырып кайткан. Соңгысыннан кайта алмаган. 1938 елда үлеп калган. Кайда җирләнгәне әлегә билгеле түгел.

АНЫҢ ШАТЛЫГЫ

Көз көне. Күкне калын катламлы болытлар каплаган. Вак яңгыр ява. Аяк асты былчырак. Ләкин эшле кешеләр болытына да, яңгырына да, былчырагына да карамыйлар. Һәркем үз эшендә. Чаба да йөри.

Балалар да үз эшендә, алар хәзер укуга чумганнар. Һәр бала иртә торгач, чәй генә эчә дә, китапларын аркасына асып, мәктәпкә чаба. Анда иптәшләр күп. Анда яхшы, анда җылы, анда күңелле.

Атасыз-анасыз калган ятим Хөсәен дә моны күрә иде. Тиңдәшләренең мәктәпкә баруларын карап, моңаеп кала иде.

Ул ялгыз, аның бер якыны да юк иде. Көннәрен

ул урамда теләнеп: «Алла ризалыгы өчен, абый, бер тиен бир әле, абый, абый, җаным, бер тиен... бер тиен!» — дип соранып үткәрә иде.

Кулын сузып, әрнешкән тавыш белән инәлүләрен илтифатка алып, берәр кеше хәер бирсә, Хөсәен дә тук, бирмәсәләр, ач кала иде.

Шундый ач көннәрнең берендә, кич җиткәч, Хөсәен, кунарга урын эзләп килеп, зират сакчысының бусагасы астына кереп ятты. Монда, ичмасам, җир коры иде.

Шактый озак азапланып ятканнан соң Хөсәен йокыга китте.

Ул төш күрә башлады. Аның төшенә әнкәсе керде. Ул ап-ак кәфеннән, йөзендә кайгы, күзләрендә хәсрәт. Сөекле улының урамда теләнеп йөргәнен күргәч елый башлады. Хөсәенне янына чакырып алды да, күкрәгенә кысып, сөя, иркәли, башыннан сыйпый, күзләреннән үбәргә тотынды. Шуннан соң аның кулыннан тотты да алып китте. Анасы кәфеннән, Хөсәен өзгәләнгән ертык киемнән төнлә белән акрын гына урам буйлап баралар.

Урам караңгы, һәр җирдә утлар сүнгән, халык йоклый. Хөсәен белән анасы баралар, бер сүз дә сөйләшмичә баралар.

Менә алар бер өй каршына килеп туктадылар. Өй зур, ак таштан салынган, яшелгә буялган, тимер рәшәткә белән әйләндерелгән. Аның түбәсеннән серле бер нур балкып тора. Бу серле нурдан тирә-як яктыра, һәр нәрсә күренә. Өй алдына бер зур такта асылган: аңа «Мәктәп» дигән изге сүз язылган. Ләкин кечкенә Хөсәен бу сүзне укый белми.

Шул вакыт Хөсәеннең әнисе, кулы белән бу изге сүзгә күрсәтеп, салкын гына калтыранган тавыш белән сөйли башлый:

— Сөекле угылым! Ятим угылым! Син болай адәм хуры булып теләнеп йөрмә. Күрәсең, балам, бу өйнең түбәсеннән изге нур балкып тора. Кил дә шул өйгә кер! Бу өйдә ятимнәрнең күңелен сындырмыйлар. Бу бәхет өе!.. Монда һәр нәрсәне белерсең, барысын да өйрәнерсең, монда синең күзең ачылыр. Кил, бәгырем, кил, шунда кер, бәхетле булырсың!..

Хөсәенгә әнкәсе соңгы сүзләрен әйткәндә, зират сакчысы бабай моңлы гына тавыш белән иртәнге намазга азан әйтә башлады. Картның азан тавышы Хөсәеннең колагына әллә кайдан, җир астыннан килгән төсле тоела иде. Ул бу тавышка уянып китте. Ул күшеккән, куллары күм-күк булган, аның урыныннан тиз генә торасы да килмәде, төшендә күргән әнкәсе турында уйлана башлады. Бөтенләй таң атты. Анда-монда кеше тавышлары ишетелә башлады.

Хөсәен, көчкә-көчкә бусага астыннан чыгып, шәһәргә таба китте. Аяклары башта бик әрнесәләр дә, соңыннан язылдылар. Ул тизрәк атлый башлады. Малай шәһәргә теләнергә бара иде. Шәһәрдәге урам ташлары Хөсәеннең аякларын кисәләр иде. Ул чыраен сыта иде дә тагын юл белән китә иде. Ул зур-зур өйләр яныннан, кибетләр яныннан үтте.

Шулай ашыгып барганда, аның чабуыннан кемдер тоткан төсле булды. Ул, як-ягына каранды, ни күзе белән күрсен?! Хөсәен төшендә күргән ак таштан салынган өй алдында тора! Әйе, әйе, бүген төшендә әнкәсе аны шушы мәктәп алдына алып килгән иде. Шушы мәктәпкә керергә кушкан иде. Әйе, әйе, монда Хөсәен төсле кечкенә балалар укыйлар. Хөсәен аларны күрә, тәрәзә аркылы күрә. Әнә алар парталарга утырганнар, бөтенләй онытылганнар. Хәлфәнең дәресен тыңлыйлар!..

Хөсәен калтыранып китте. Аның күңелендә әллә

нинди шатлык туды. Йөрәк сикерә башлады. Үзе дә аңламаган килеш мәктәпнең ишеге төбенә килеп туктады. Мәктәпнең эченә кермәкче булды. Ләкин мәктәп караучы бабай Хөсәенне кертмәде, куды. Хөсәен китмәде. Шунда ишекнең тышкы ягында боегып калды. Шәкертләрнең тәнәфес вакытында ишек алдына чыгуларын көтеп калды.

Мәктәптә дәрес әле күптән түгел генә башланганга күрә, аңа шактый озак боегып көтеп торырга туры килде. Ул тәрәзә янынарак сөялде. Хәлфәнең кычкырып сөйләгән тавышы аны үзенә тарта башлаган шикелле булды.

— Менә шулай ул, туганнарым, менә шулай ул тормыш,— дип сөйли хәлфә,— ул ага да тора. Көннәрнең, айларның, хәтта елларның үтеп китүләре сизелми дә! Бүгенге көнне югалтасыгыз килми икән, сез тырышырга тиешле, бүгенге эшегезне бүген бетерергә тиешле! Инде шул бүгенге көнгә илтифат итмисез икән, ул үтә дә китә, сезнең илтифатсызлыгыгызга бер дә исе китми! Шуңар күрә, туганнарым, вакытыгызны бушка үткәрмичә, сез тырышырга бурычлысыз. Сез үзегез өчен генә укымыйсыз, юк! Сезнең алдыгызда милләтегез, халкыгыз; фәкыйрь, теләнеп, боегып, сезнең кеби тыныч кына укудан мәхрүм калып, көннәрен кайгылы күз яше эчендә үткәрә торган ташландык балалар — кардәшләрегез өчен сез тырышырга тиешсез! Шул ятимнәрне, шул теләнчеләрне, шул кызганыч балаларны киләчәктә сез, туганнарым, менә сез укый торган кеби җылы мәктәпләрдә укытсагыз, аларның өс-башларын киендерсәгез, аларны тәрбияләрлек кешеләр булырга тырышсагыз, сезгә аннан зарар килерме? Шундый шәфкатьле егетләр булып чыкканыгызга сез үкенерсезме?..

Хәлфә шул сүзләр белән үзенең дәресен бетерде.

Балалар, шатлыкларын эчләренә сыймаган төсле, көлешә-көлешә, йөгерешә-йөгерешә мәктәп ишек алдына чыктылар. Шәкертләрнең уеннарын, шаяруларын карар өчен ишек алдына хәлфә дә чыкты.

Тәрәзә янында сөялеп моңайган Хөсәенне күреп, аның янына килеп, йомшак кына тавыш белән:

— Нихәл, энем, ник син монда болай торасың? Туңасың бит,— дип сорады. Хәлфәнең бу сүзләре Хөсәенне уяткан төсле булды. Ул башын күтәрде дә хәлфәгә карады, чыдый алмады, кычкырып елый башлады, хәлфәнең аягына егылды да:

— Хәлфә, жаным, бәгырем, минем әтием юк, әнием дә юк! Мин ятим, мин теләнеп йөрим. Хәлфә, җаным, минем укыйсым килә! Мин кайда укыйм, хәлфә абый, мине кума! — дип, хәлфәгә инәлә башлады.

Хәлфә былчыракка тезләнгән Хөсәенне күтәреп торгызды... Ун минуттан соң Хөсәен алдагы партада яшьтәшләре янәшәсендә утыра иде. Аның күзләре хәзер шатлык нуры чәчә иде. Аның шатлыгы күкрәгенә сыймый иде!

1913

ШАТЛЫК ЭЧЕНДӘ КАЙГЫ

Фатих әткәсе исән чакта иртәгесе көн турында уйлау түгел, кайгының ни икәнен дә белми иде. Кайвакыт ул ни белән булса да шөгыльләнергә уйласа, әтисе, хәзер үк аны туктатып:

— Йә, балам, юк-бар эшләр белән вакытыңны юкка үткәрмә, сәламәт булсаң, эшләр көннәрең алда әле, эшләрсең дә, ә хәзер сабакларыңны әзерлә,— ди торган иде. Бер дә көтмәгәндә атасының үлеп китүе Фатихка зур авырлык тудырды. Унбер яшьлек Фатих анасына булыша башлады. Әтисеннән калган мал булса, начар булмаган булыр иде, әтисе кучер-

лыкта эшләп, айга ун гына сум алып торганга, әллә ни байлык җыя алмады. Тапкан акча бетеп бара иде. Җитешмәгән урыннарны Фатихның анасы Хәлимә абыстай керләр юып тапкан акчасы белән тутыра иде. Шулай итеп, көннәр җайлы гына үтәләр иде. Әтиләре үлгәч, Хәлимә абыстай белән кечкенә Фатихка шактый газапланырга туры килде. Үз-үзләрен генә туйдырырга кирәк булса, тагын бер хәл, үзләре өстенә карчык әбисе белән сеңлесе Рабига да бар иде.

Әбисе карт, тешсез, намаз укудан башка эш көченнән килми, сеңлесе яшь, аңа дүрт кенә тулган, уеннан башка бернәрсәгә дә ярамый. Ул кайдандыр кечерәк кенә бер агач кисәге табып алган да, шуны курчак иткән дә һәркөн шуның белән уйнап гомерен үткәрә. Башына әбисенең тастымалын чорный, борын очына гына әбисенең күзлеген элә дә, идәнгә утырып, «әлли-бәлли» диеп, тик курчагын юатып мәж килә.

Адәм балаларына дөньяда төрле авырлыкларга түзәргә туры килә. Ул атасыз торырга да күнегә.

Фатих та үз бурычын үтәр өчен кулыннан килгән кадәр тырышты. Кибеткә малай булып керергә теләде, берничә байга орынып карады — булмады. Шуннан соң ул күрше малае Зәки белән бергә гәҗит сатып йөри башлады. Элек көннәр буена көчкә биш-алты тиен табыш итә иде. Шул табыш өчен аңар көне буе газапланырга туры килә иде. Тора-бара ул эшнең җаена төшенде, иртән иртүк тора торган булды. Гәҗитне сатар өчен бер урам чатында гына тормыйча, шәһәрнең читтәрәк урыннарына да чаба башлады. Шулай эшли башлагач, Фатихның табышы көненә егерме-егерме биш тиенгә җитте. Эш җайланды. Һәр көн сәгать өчләрдә ул гәҗит эшеннән бушый, Хәлимә абыстайга өй эшләренә булыша. Әнисенә су

китерә, йә су буена аның керләрен илтешә, йә әнисе керләр юып кайтуга самовар куеп тора.

Рамазан шәриф[1] керү белән Фатих өчен тагын бер бәхет ачылды: ул мәчет алдында тәравих[2] кәләвәсе[3] белән сату итә башлады. Бу сәүдәсе Фатихка кайбер көннәрне утызар тиен табыш китерә иде, ә башка вакытлар егерме тиеннән дә ким кайтмый иде.

Шәриф ай үтте, иртәгә гает шәриф[4], халык әллә нинди бер кызулык, бер ашыгычлык белән бәйрәмне каршы алырга әзерләнә. Хәлимә абыстай да бу бәйрәмне каршы алуда башкалардан калышмаска тырыша: идәннәрен, тәрәзәләрен юа, өстәлгә җәяр өчен чиста ашъяулыкларын, сөлгеләрен чыгарып куя, самоварын әрчи, савыт-сабасын рәтли, кирәкле нәрсәләрен пешерә.

Рузаның бүген соңгы көне. Иртәгә гает. Гает намазына киеп барыр өчен ул Фатихның күлмәкләрен әзерләп куйды.

Ахшамнан[5] чыктылар. Фатих әле һаман кайтканы юк. Ястүгә[6] дә азан әйтелде. Хәлимә абыстай Фатихның кайтмавына борчыла да башлады.

Менә Фатих кайтып керде. Йөзе ябык, үзе күңелсез. Күзләрендә әллә нинди яшерен кайгы уты яна. Аның әле ифтар иткәне[7] дә юк. Фатихны күрү белән

---

[1] *Рамазан шәриф* — изге ай, ураза тоту ае.

[2] *Тәравих* — ураза аенда кичен мәчеткә җыелып догалар уку.

[3] *Кәләвә* — он белән бал-май катыштырып эшләнгән мамык сыман татлы ризык.

[4] *Гает шәриф* — монда изге ураза бәйрәме мәгънәсендә.

[5] *Акшам* — кояш баеп, эңгер-меңгер вакытта укыла торган намаз.

[6] *Ястү* — караңгы төшеп, күз бәйләнгәч укыла торган намаз.

[7] *Ифтар итү* — ураза тотканнан соң, кояш баегач, ашау, авыз ачу.

Хәлимә абыстай куркып киткән төсле булды. Ни дип әйтергә дә белмәде, шул арада Фатих тәравих кәләвәсе сата торган әрҗәсен почмакка куйды да, кесәсеннән чыгарып, әнисенә илле тиен акча бирде.

— Кара әле, Фатих,— дип әнисе сүз башлады,— әллә кәефең юкмы, бәбкәм? Ник болай күңелсез торасың? Әйдә тизрәк, ифтар ит, шул хәтле соңга калып ашамый-эчми йөриләрмени?

Фатих, әнисенә бер җавап та кайтармыйча, кулларын юды да ашарга тотынды. Намаз укыды, әтисенә коръән укыды, әбисен, сеңлесен бәйрәм белән котлап, йокларга ятты.

Ул озак йоклый алмады. Моннан соң аның көнлек егерме-утыз тиен табышы булмаячак. Шушы уй аның башын вата, йокысын качыра, бәйрәмгә булган шатлыгы эченә кечкенә генә бер кайгы сала иде.

Шул кайгысын уйлый-уйлый ул йокыга китте.

1913

МИН ШАТЛАНА АЛМЫЙМ!

Бүген бәйрәм диләр, бүген шатлык көне диләр, бүген һәр бала уйный диләр.

Әйе! Йомшак күңелле анасы, балалары өчен тырышып эшли торган атасы булган балалар — бик бәхетлеләр! Андый балалар, бәлки, уйнашып та, көлешеп тә йөри торганнардыр. Ник аларга көлешмәскә! Ник шатланмаска! Алар бәйрәм киеменә киенгән, күңелләре күтәренке, тамаклары тук. «Әнием, бәгырем!» — дип әйтерлек сөекле аналары исән. Авырый башласалар, баш очларында утырып, төрле хикәяләр сөйләп, күңелләрен юатучы шәфкатьле аналары бар.

Шундый балалар өчен бүген ник бәйрәм булмасын да, шундый балалар бүген ничек шатланмасыннар?!

Шулай һәрбер бала бүген бәхетлеме? Шулай шатмы, күңеле шулай күтәренкеме?

Теләнче балалары — урам чатларында иртәдән кичкә чаклы туңып, боегып, күгәренеп теләнеп йөри торган балалар. Алар да шулай ук бәхетлеләрме? Юк! Мең мәртәбә юк! Мондый балалар өчен бүген бәйрәм түгел, аларның өс-башлары былчырак, киемнәре өзгәләнгән, аларның күңелләре төшенке, аларны караучы юк, алар ташланганнар, ата-аналары юк. Алар, алар... былчырак урам балалары.

Тамаклары ач, күңелләре ярсыган килеш, алар һәр узгынчы артыннан: «Абый, абый, җаным, бер тиен бир! Абый җаным, бер тиен генә бир әле!» — дип моңаешып, кулларын сузып калалар. Бу — мөселман балалары. Безнең динебез бер. Без һәммәбез — бөтен дөньяга мәхәббәт нурын чәчәр өчен күндерелгән балалар. Безнең каныбыз, милләтебез бер!

Безнең кан-кардәшләребез булган шул ятимнәр күңелләре ярсыган, күзләре яшь белән тулган килеш урам чатларында былчырак эчендә боегышып, теләнеп йөргәндә — мин ничек шатланыйм?!

Шатлык белән капкан ашым зәһәрле канга әйләнер иде!..

Юк... мин, шул ташландык ятимнәрнең төркеменә кушылып, алар белән бергә егълашуны артык күрәм... Мин шатлана алмыйм!..

1913

ЯЛГЫЗ КАБЕР

— Рәфикъ, Рәфикъ! Кайда син? Кил әле бире! Иртәгә Әхмәт абзыең белән калага барасың киләме?

— Әнием, бәгырем! Килә, бик килә. Мин бит каланы бер дә күргәнем юк.

— Алайса, Әхмәт абзыең хәзер кайтыр. Ул күршегә генә керде. Ул кайткач та, су коенырга барыгыз. Яхшы гына коен, колак эчләреңдә тузаннар калмасын. Әйдә, чиста күлмәк-ыштаннар бирим,— дип, Хәлимә абыстай үзенең төпчек, шуңа күрә иң яраткан улы Рәфикъны өйгә алып керде. Әнкәсеннән «калага барасың киләме?» дигән сүзне ишеткәч тә, Рәфикъның йөрәге урыныннан чыгар төсле булып тибә башлады. Ул шатланды, аның калага барганы юк иде бит. Кала турында иптәшләреннән ишеткәне генә бар иде. Шуңа күрә кала аны бик тарта иде. Калага илтә торган юл бик киң, имеш. Юлның уң ягында буйдан-буйга куе урман сузыла. Анда бүреләр, аюлар, төлкеләр, боланнар туп-тулы, имеш. Сул якта киң болын, анда матур чәчәкләр, төрле күбәләкләр, сайрар кошларның исәбе-хисабы юк, имеш. Калага барып җиткәнче, өч тау менәргә туры килә, имеш. Алдагы тау астыннан бик тәмле, бик салкын сулы чишмә чыга, калага баручылар бу чишмәдән атларын эчерәләр. Калага нәкъ ярты юлда әллә нинди бер ялгыз кабер, мөселман кабере бар, имеш. Рәфикъ боларның һәммәсен ачык кына күз алдына китерә алмый: алар барысы бергә чуалышып бетәләр иде.

Иртәгә Рәфикъ боларның һәммәсен үз күзе белән күрәчәк. Үзе кебек каланы күрмәгән иптәшләренә берсен дә калдырмыйча, озын-озын итеп сөйләячәк.

Рәфикъның көләсе, кычкырасы, йөгерәсе, тагын әллә нәрсәләр эшлисе килә иде. Хәзер ул үзенең ип-

тәшләренә калага барасын, аннан аларга бүләкләр алып кайтасын сөйләр иде. Ләкин хәзер соң инде. Әнә ахшамнан да чыктылар. Җәен төн кыска бит. Йокларга ятарга кирәк. Сәгать икеләрдә юлга чыгарга туры килер. Рәфикъның эчендә ниндидер бер ышанмаучылык та бар иде. Әнисе: «Калага барасың киләме?» — генә дип сорады бит, «Калага барырсың»,— дип әйтмәде. Ул шаярткан гына булса?

Бу икеләнүләрдән котылу өчен Рәфикъ Әхмәт абзыйсына әйләнде дә:

— Әхмәт абзый, бүген Хөсәен (Хөсәен Рәфикъларның ялчы малае иде) нинди атларны куна алып барачак? — дип сорады.

— Бүген Хөсәен куна бармас, атлар калага барырга кирәк.— Әхмәт абзыйсының җавабы Рәфикъны тынычландырды. Рәфикъ каланы күрәчәк!!!

Таң беленә генә башлаган иде. Мөәзиннең азан тавышы Әхмәт абзыйны башыннан сыйпаган төсле итеп уятты. Ул тәһарәтләнеп [1] иртәнге намазын укыды. Шуннан соң йортка чыгып, атларны җигә башлады. Ул атларын җигеп бетергәнче, табигать патшасы кояш та чыкты.

Рәфикъ һаман үлек төсле йоклый иде. Әхмәт абзый да аны йокысыннан аерасы килмәде. Ул тарантаста йомшак кына урын әзерләде, Рәфикъ бүлмәсенә шыпырт кына керде дә, аны йоклаган килеш күтәреп алып чыгып, акрын гына тарантаска яткырды, киемнәрен дә үз янына куйды. Үзе тарантасның алдына утырып, акрын гына юлга чыгып киттеләр.

Кала юлының начарлыгы, шунлыктан тарантасның әле бер, әле икенче якка бәрелгәләве Рәфикъны да татлы йокысыннан уяткан булыр иде, ләкин олы юлга

---

[1] *Тәһарәт* — намаз алдыннан юыну.

чыкканчы биш чакрымнарга сузылган йомшак чирәмле юл малайны тирбәтеп кенә йоклата иде.

Рәфикъ төш күрде.

Үткән ел аның иң сөекле апасы Шәфика үлгән иде. Рәфикъ аны бар җаны-тәне белән сөйгән кебек, апасы да аның өчен җанын бирер иде. Рәфикъ шул апасы кулында үскән төсле үсте. Рәфикъ унбер яшенә җиткәнче апасыннан бер авыр сүз ишеткәнен хәтерләми.

Имеш, шушы сөекле апасы күкрәгеннән муенына хәтле ап-ак матур чәчәкләр белән капланган, башына энҗеле калфак киеп, шатлык нуры белән нурланган. Рәфикъка көлемсерәп карап торды. Рәфикъ шатлана, көләсе килә, апасы янына барасы килә, ләкин аяклары атламый, ул көчәнә. Шул арада бер яктан икенче якка әйләнеп ята, Шәфика апасы да күздән югала.

Рәфикъ һаман йоклый. Кояш күтәрелә, әкрен генә таң җиле исә. Тирә-як авыллардан кырга көтүләр чыга. Әнә, кәрван төсле тезелешеп, болынга казлар төшә. Әнә кызгылт түшле, аеры койрыклы карлыгачлар бер-берсен куышып уйныйлар. Менә мөселман авылы зиратлары. Әхмәт абзый акрын гына тавыш белән коръән укый. Дога кыла. Шуннан соң, бисмилла әйтеп, Рәфикъны йокысыннан уята.

Рәфикъ:

— Әхмәт абзый, без кайда? — дип сорый.

— Безме? Без хәзер Күлтеш авылына керәбез. Менә монда инешчек бар. Әйдә, төшеп яхшылап кына битеңне юып ал. Коенсаң да яхшы булыр, атларны шунда читкәрәк таратып куярбыз.

Әхмәт абзый атларны юлдан бераз читкәрәк туктатты да үзе Рәфикъны инешчеккә коенырга алып китте. Күлтеш авылының инеше дә шулай дип атала иде. Авылның үз янындагы бу инеш сай гына булса

да, күпер янында шактый тирән иде. Рәфикъ яхшы йөзә белгәнгә, бер дә исә китмичә, чишенеп, киемнәрен Әхмәт абзыйсына тоттырды да үзе суга сикереп төште. Инешнең салкын суы тәненә тигәч, «аһ» дип кычкырып җибәрде, шундагы камышлар эченнән үрдәк бәбкәләре йөзеп чыкканын күргәч, аларга таба бара башлады. Бәбкәләрнең әниләре, Рәфикъның балалары янына килүен күргәч, шунда ук килеп җитте. «Хсс, бак-бак, хсс!» — дип, Рәфикъ белән талаша башлады. Малай бәбкәләргә тия башласа, ул бөтен көче белән аларны саклаячак иде. Ана өчен балалардан да кадерле нәрсә бар!

Рәфикъ моны аңлады булырга кирәк, бәбкәләрдән читкәрәк китте. Шактый озак коенгач, йөзеп туйгач, Рәфикъ судан чыкты, киенде һәм алар, атларына утырып, Күлтеш авылы аркылы чыгып, кала юлына керделәр. Телеграф чыбыкларының пырылдап торулары, биек-биек баганаларга тагылган озын-озын тимер чыбыклар Рәфикъка бик кызык тоелдылар. Рәфикъ чыдый алмады:

— Әхмәт абзый, бу нинди чыбыклар? Ни өчен аларны баганаларга такканнар? — дип сорады.

— Бу чыбыкларның серләрен инде, улым, алла гына белә, әйтәләр менә шул чыбыклар аркылы кешеләр ерактан, бер шәһәрдән икенче шәһәрдә торып, бер-берсе белән сөйләшәләр ди, телеграммнар йөртәләр ди.

— Чыбыкларның эчләре куыш булса кирәк, шуннан сүзләр йөри булса кирәк, — диде Рәфикъ, бүтән сорашып та тормады.

Шул арада Рәфикъның исенә кылт итеп ялгыз кабер килеп төште. Бу ялгыз кабер турында ул күп ишеткән иде.

— Әхмәт абзый, теге кабергә тиз җитәбезме әле? — дип сорады.

— Нинди кабер турында әйтәсең?

— Әнә, кала юлында бер кабер бар ди бит. Ялгыз кабер, әллә нинди мөселман кабере.

— Әйе, бар, бар! Без аңар тиздән җитәрбез. Ул кабер кала юлының нәкъ уртасында.

— Әхмәт абзый, ник соң ул кабер кала юлында, мөселман кабере ич. Шулай булгач, ул кабергә мөселман мәете күмелгәндер бит. Ник ул мөселманны кала юлына күмгәннәр? Мөселман зиратына күммәгәннәр?

— Әй, бала, бала, ни сөйлисең син? Исерек кешене ничек итеп мөселман зиратына күмсеннәр! Ул бит эчеп-исереп үлгән. Эчеп-исереп үлгән кешене мөселман зиратына күмәргә муллалар кушмый, китап кушмый,— диләр.

Рәфикъ бераз уйланып торды да тагын сүз башлады:

— Ул кеше карт булганмы, яшьме?

— Ул кырык бишләр чамасында иде.

— Син, Әхмәт абзый, аны беләсеңмени?

— Бик яхшы беләм. Ул үзе болай егет кеше иде. Усал телле, кешегә начарлык итә торган түгел иде. Менә шул эчүгә бәйләнгән иде.

— Соң, ул юлда үлгән, өенә кайтып җитә алмаган микәнни?

— Шул инде, бичара, җитә алмаган инде. Кыш көне булган, салкын буранлы төн булган, адаштырганнар булырга кирәк.

— Кемнәр адаштырганнар?

— Кемнәр булсын, әлбәттә, җеннәр.

— Ничек адаштырганнар?

— Шулай инде, юлдан саптырганнардыр. Исерек кешенең күзенә әллә нәрсәләр күренә диләр бит.

— Соң, аны кайчан таптылар?

— Яз башында, карлар эреп беткәч. Бичараның киемнәре череп беткән ди, арты ачылган, итен каргалар чукый башлаганнар, көчкә-көчкә генә таныганнар.

Әхмәт абзый соңгы сүзләрен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, алар ялгыз кабер янына килеп җиттеләр. Атларны туктаттылар.

Әхмәт абзый дилбегәне Рәфикъка бирде дә, үзе ялгыз кабер янына барып тезләнеп, коръән укый башлады. Бик озын иттереп дога кылды. Шуннан соң утырып, юлларына киттеләр.

Әхмәт абзыйның, шул эчеп-исереп, хур булып үлгән кешенең кабере янына туктап, коръән укуын Рәфикъ аңлап җиткерә алмый иде. Эчеп үлгән кешенең җаны җәһәннәмгә[1] китә икән. Рәфикъ әллә ничә мәртәбә ишеткәне бар. Чыдый алмады, абзыйсыннан:

— Гөнаһ булмасмы? Ул бит эчеп үлгән, мордар[2] киткән кеше, андый кешенең кабере өстендә коръән уку гөнаһ диләр бит? — дип сорады.

— Әй, бала, ул болай да гөнаһлы бәндә инде, савап булсын өчен, аның газабы кимесен өчен укыдым.

Рәфикъ онытылып торган төсле бара иде. Әхмәт абзыйсының сүзләре аның күңелендә әллә нинди кызганыч тойгылар уята иде.

Әхмәт абзый атларын куды. Атлар ук кебек атылып киттеләр. Артларыннан кара болыт төсле тузан күтәрелеп кала иде.

Алар кала юлындагы өч тауның берсенә җиттеләр. Әхмәт абзый аттан төште. Урта атның ыңгырчагын бушатты да атлар яныннан үзе җәяү менеп китте.

---

[1] *Җәһәннәм* — тәмугъ төбе.

[2] *Мордар* — имансыз.

Тауга менгәч, ыңгырчакны тагын бәйләде. Икенче, өченче тауларны менгән чакта тагын чиште, тагын бәйләде.

Соңгы таудан калага биш кенә чакрым. Рәфикъ инде каланы күрә. Җаладагы йортлар ак таштан салынган, шунлыктан ул әллә кайдан күренә. Рәфикъның йөрәге еш-еш тибә, тизрәк калага җитәсе иде, мөмкин булса, ул очып барып җитәр иде!

Көтәчәк җитәчәк, ди халык, Рәфикълар да калага җиттеләр. Зур-зур йортлар, яхшы киемнәрдән генә йөри торган халык — Рәфикъ өчен болар яңа бер дөнья төсле тоела иде.

Фатирларында чәй эчеп, атларны ашатканнан соң, алар кирәк-яракларны алу өчен калага чыктылар. Рәфикъ сеңлесенә унбиш тиенлек курчак сатып алды. Әнисе белән әбисенә чәчәкле кәгазьгә төрелгән ярты кило конфет алды. Дуслары — Хөсәен белән Зәкигә бер кадак көнбагыш һәм берәр кармак алды.

Хәзер Рәфикъның тизрәк өйгә кайтасы килә башлады. Әйе, тизрәк кайтып, күргәннәрен иптәшләренә сөйлисе, бүләкләрне тизрәк бирәсе иде...

Җирәк-яракларын алып бетергәч, алар фатирларына кайтып чәй эчтеләр дә юлга чыктылар. Кояш баер алдыннан өйләренә кайтып кērделәр.

Монда Рәфикъны сеңлесе, әнисе Хәлимә һәм дуслары Хөсәен белән Зәки әллә кайчаннан бирле көтеп торалар иде.

Рәфикъ тарантастан төште, алып кайткан бүләкләрен ияләренә өләште һәм зур кызулык белән күргәннәрен, ишеткәннәрен сөйләргә тотынды.

Сүзләрнең иң күбесе ялгыз кабер турысында иде...

1913

ҚЕЧҚЕНӘ ҚАРАК

Қөннәрдән бер көнне кечкенә генә бер күсе мәчеләр өеннән бер кисәк эремчек урлады. Қарак өйгә кергәндә, сакларга калган Мәче йокымсыраган иде. Шуңа күрә кечкенә каракның эремчекне урлап китүен сизми дә калды.

Сакчы мәче кисәктән генә уянып китте, аны кемдер инә белән чәнечкән кебек булды. Күзләрен ачып җибәрсә, ни күзе белән күрсен, эремчектән җилләр искән!

Мәче ары йөгерде, бире йөгерде, берни дә чыкмады. Қаракның эзе дә юк. Шуннан соң ул елыйелый урамга чыкты. Ишектән генә чыккан иде, аны Полицейский мәче туктатты.

— Қара әле, чибәр егет, урамда еларга ярамый,— диде ул.

— Еларга ярамый, дигән була. Эремчегеңне урласалар, син дә елар идең,— диде Сакчы мәче.

— Җүләр, аны башта ук шулай дип әйтәләр. Мин синең эремчегең югалганын кайдан белим. Менә без хәзер ул явыз каракны эләктерербез,— дип, Сакчы мәчене юатты да, үзе иптәшләрен алып, каракны эзләргә китте.

Күп тә үтмәде, полицейский мәчеләр кечкенә карак күсене, ике кулын артка бәйләп, хөкемгә алып килделәр. Ул бичара әле эремчекне ашап та өлгермәгән иде. Қарак белән бергә эремчекне дә китерделәр.

Эремчек полицейский мәчеләрнең күзен яндырды. Эремчек исенә чыдый алмый, алар мырылдаша башладылар. Эремчек аларның һушына шулкадәр китте ки, аны кулдан-кулга йөртеп, Қечкенә каракны бөтенләй оныттылар. Үз чиратында Қечкенә карак та

авыз ачып тормады. Әкрен-әкрен артка чигеп сызды да китте. Ләкин мәчеләр моңа кайгырмадылар. Карак күздән югалса да, эремчек аларның күз алдында иде.

1914

ФАТИХАНЫҢ ЯШЕРЕН СЕРЕ

Җәйге матур көннәрнең берсендә Фатиха иртә белән бакчага чыкты. Бакчада матур сирень агачлары яныннан үтеп барганда күзенә бер оя чалынды. Йомшак кына, нечкә генә кыллардан ясалган оя. Фатиха аңа сокланып карап торды, аның күңеле яшерен бер шатлык белән тулды. «Оя! Матур оя!» — дип кычкырып җибәрде. Ояга якынрак килгәч, ул оя эчендә кечкенә генә чуар йомыркалар күрде. «Әнием, җаным, йомыркалары да бар!» — дип тагын бер кычкырып җибәрде. Шатлыгыннан аның күзләре ут кебек янды. Ояны ул әйләнеп-әйләнеп карап йөрде, шатлыгы эченә сыймады. Кыз, ояның хуҗалары да бардыр әле, дип уйлады. Ләкин алар юк иде. Оя тирәсендә бер җанвар да күренми иде. Фатиха һаман шул туктаган урыныннан китә алмый тора. Ояны ясаган хуҗа кошларны көтә иде. Ул озак көтте, килүче булмады.

Фатиханың бераз гына ачуы да килде.

— Бу ниткән эшләре инде, кайтсалар, мин аларга тимим бит. Ул хуҗа кошларны күрәсем генә килгән иде,— дип сөйләнә-сөйләнә, өенә кереп китте.

Фатиха, өйгә кергәч, әбисенә үзенең әлеге серен сөйләде. Йомшак күңелле карчык куркынып китте. Ул тиз генә Фатиханың кулыннан тотып алды да: «Син оядагы йомыркаларга тимәгәнсең бит, ояны ватып-җимереп ташламагансың бит?» — дип сораша башлады.

— Юк, әбием, җаным, тимәдем дә, җимермәдем дә.

— Шулай шул, бәбкәм, шулай, кечкенә кошчыкларның ояларына, йомыркаларына тияргә ярамый, яхшы түгел, аларны карарга гына мөмкин. Шулай һәркөнне үзең генә кара да кит, бүтәннәргә белгертмә.

Әбисенең «бүтәннәргә белгертмә» дигән сүзләре Фатихага бик үк ошап бетмәде.

— Ник белгертмәскә, карасыннар, Суфия белән сеңлемне дә алып киләм, алар да карасыннар,— дип бакты. Фатиханың бу сүзенә дә әбисе каршы килде:

— Кирәкми, бәбкәм, кирәкми, йә тагын алар кошларны куркытырлар, йомыркаларына тиярләр... Әйдә, үзең генә бел, үзеңнең сереңбулсын.

— Әйе, әйе шул, әбием, әйдә, үземнең серем генә булсын, берәү дә белмәсен. Хәзер Фатиханың бүтәннәрдән яшерен сере бар!

Фатиха һәркөн килеп ояны карый башлады. Кошлар Фатихадан куркалар, ул килә башлагач, оядан чырылдашып чыгалар да очып китәләр. Аларның болай куркулары Фатиханы күңелсезләндерә иде. Ул:

— Җаннарым, былбылларым, нигә сез миннән куркасыз, мин бит сезнең дустыгыз, сезгә тимим, сезне саклыйм гына,— дип үз-үзенә сөйләнә иде.

Көннәр үтте, атналар үтте. Оядагы чуар йомыркалардан кечкенә генә сары борынлы чебиләр чыккач, кошлар ихтыярсыз Фатихага ияләшә башладылар. Аңардан курыкмыйлар, элекке кебек чыркылдашып, оядан чыгып качмыйлар, шундагы ботакларга утырып, кечкенә генә кара күзләре белән Фатихага карыйлар, аңа нидер әйтмәкче булалар кебек иде. Ләкин кошның теле юк шул!

Көннәр шулай үтте. Кечкенә кош балалары үстеләр, аларның канатлары ката башлады. Хәзер алар, оядан чыгып, ботакларга утыра алалар.

Фатиха хәзер шатлыгыннан кая барырга, нишләргә белми. Чыннан да, ничек шатланмассың: менә кечкенә генә оя, түгәрәк кенә, кечкенә генә ояда нәни генә чуар йомыркалар, менә бер-ике җомга үтәргә өлгермәде, зур авызлы, сары борынлы ялан тәнле чебиләр. Болар барысы да искитәрлек эшләр! Болар барысы да Фатиханың күз алдында булып үттеләр!

Кечкенә кош балалары көннән-көн үсә, көннән-көн матурая иделәр. Әти-әниләре, төрле бөҗәкләр, чебеннәр китереп, аларны туйдыра, авызларына алып килгән су тамчылары белән балаларының сусаганнарын баса иделәр.

Беркөнне Фатиха, кош балаларын карарга дип, үзенең дусларын да алып килде. Ни күзләре белән күрсеннәр, кош балаларыннан җилләр искән.

— Болай гына киткәннәрдер, хәзер кайтырлар,— дип, Фатиха үзен-үзе юатса да булмады — аның дуслары иркен һәм киң болынга күчкәннәр иде.

Фатиха башта бик күңелсезләнде, пошынды. Шундый күңелсез чакларында ул үзен болай дип юата иде:

— Дусларымның оясын берәүгә дә күрсәтмәдем, аларны саклап кына үстердем. Бу минем яшерен серем иде,— ди торган иде. Шул сүзләрдән соң Фатиханың күңеле нindидер бер рәхәтлек тоя, тынычлык таба иде.

1914

ҚЕЧҚЕНӘ ГАЙШӘНЕҢ БҮЛӘҚЛӘРЕ

Гайшәнең әткәсе үткән ел Мәкәрҗәдән[1] бер юлбарыс тиресе алып кайткан иде. Бу чуар юлбарыс тиресенең күзләре ут кебек янып, авызын ачып, тешләрен ыржайтып торганга, Гайшә аның янына барырга курка иде. Кечкенә Гайшә әтисен яратканга күрә, билгеле инде, аның бүлмәсендә идәнгә җәелгән юлбарыс тиресен дә бик ярата иде. Никадәр генә куркыныч булса да, Гайшәнең бу юлбарыс белән дуслашасы килә иде.

Менә ул кеше юк чагында гына, аяк очларына басып, әтисенең бүлмә ишеге янына бара да, ишекне аз гына ачып, идәндә яткан юлбарыс тиресен карый, аның белән нидер сөйләшмәкче була. Ләкин курку дигән нәрсә курку инде ул!.. Шулай да кеше барысына да иялэшә. Элек безнең Гайшә ишекне аз гына ачып караса, хәзер инде ул бүлмәнең эченә үк керә башлады. Бервакыт ул, үзе дә сизмәстән, юлбарысның янына ук килеп җиткән, моны күргәч, ул үзе дә сискәнеп китте.

— Абау, нинди усалга охшый, алла сакласын, ашап бетерә күрмәсен,— дип, үзалдына сөйләнеп тә куйды, ләкин бу шикләнүе озакка бармады, әтисенең юлбарысы аңа якын тоела башлады. Әтием аны сөя, дус итә, шулай булгач, мин дә аның белән дус булырга тиеш, әтиемне яраткан кебек, ул мине дә яратырга тиеш дип, юлбарыс янына килде, чүгәләде, аның башыннан сыйпый башлады.

Шул минуттан Гайшә белән юлбарыс арасында дуслык башланды. Гайшә һәркөн үзенең дусты янына

---

[1] *Мәкәрҗә* — XVI гасыр урталарында Идел буендагы Макарьев монастыре янында барлыкка килгән зур ярминкә.

килә, аның белән серләшә, аңа үзенең кайгысын, шатлыгын сөйли. Еш-еш кына аның аркасына утырып, курчак уйный, юлбарыска әллә нинди җырлар җырлый. Кыскасы, урыныннан кузгалмыйча ятып тора торган дусты белән көннәрен кызыклы итеп үткәрә башлады. Тынсыз гына җәелеп яткан юлбарыс та кечкенә дустының яшерен серләрен, җырларын сүзсез генә аңлап тора кебек иде. Шуның өчен Гайшә аны конфетлар белән сыйлый иде. Юлбарыс конфет яратмаганга, Гайшә ул конфетларны үзе үк ашап бетерә иде.

Соңгы көннәрдә Гайшә бераз күңелсезрәк йөри, тиздән бәйрәм җитә, Гайшәнең бер нәрсәсе дә әзерләнмәгән. Шулай булгач, Гайшә бәйрәм көнне әтисе белән әнисен бәйрәм белән котлап нәрсә бирер инде?

Бу турыда ул юлбарыска берничә мәртәбә серен чишеп карады, ләкин дусты тын гына карап торудан башка бер сүз дә әйтә алмады. Гайшәнең кайгысы исә көннән-көн арта гына бара иде. Беркөнне инде ул чыдый алмады, юлбарыс аркасына ятты да елаган сыман тавыш белән:

— Син мине бер дә яратмыйсың булырга кирәк, бер киңәшемә дә җавап биргәнең юк,— диде, Гайшәнең бу сүзләре җавапсыз калмады.

— Син, Гайшә, бер дә юкка минем турыда начар уйлыйсың, мин сине бик яратам, кайгыңны да беләм, сине шатландырырлык бер нәрсә дә уйлап чыгардым,— диде юлбарыс.

Кисәктән генә юлбарыс тиресенең адәм теле белән сөйли башлавыннан Гайшә бер дә курыкмады, киресенчә, үзенең күңелендә хәтта бер кечкенә генә шатлык сизде. Юлбарыс исә һаман сөйләвендә:

— Синең кайгыңа чара табар өчен безгә синең белән Бөкре бабай Аксакалга барырга кирәк. Ул бик

яхшы карт. Балаларны бик ярата. Бәйрәм көнне ата-анага нинди бүләк бирү яхшы икәнне менә ул әйтер.

— Кара әле, дустым, Бөкре бабай Аксакал кем була, кайда тора ул? — дип сорады Гайшә.

— Ул моннан шактый ерак шул. Ат белән барганда, йөз ел барырга кирәк. Кошта очып барганда, йөз көн кирәк. Ә без аңар йөз минутта җитәрбез! Ул урманнар, кырлар, диңгезләр патшасы була. Менә ят син аркама, муенымнан нык кына кочакла, әти-әниләрең кайтканчы, без кире кайтып өлгерербез.

Шул сүзләрдән соң юлбарыс яткан урыныннан торып аякка басты да, өй эчендәге әйберләргә тимәс өчен, бүлмәләр аркылы акрын гына узып, баскычтан төшеп чыгып китте. Яшен ташы кебек шәһәр урамнарыннан чабып барганда, өйгә кайтып килә торган этисе белән әнисе очрадылар. Алар шаккаттылар, күзләре акайды. Икесе дә бердән ачы тавыш белән:

— Гайшә, бу ниткән эшең, кая киттең? — дип кычкыра башладылар. Боларның ачынып кычкыруларына каршы юлбарыс:

— Гафу итегез, хуҗаларым, безне туктата күрмәгез, безнең юлыбыз бик ерак, ашка чаклы барып кайтырга кирәк,— диде дә, ук шикелле атылып, үз юлына китә бирде. Әмма соң чабалар үзләре!.. Җирдә чабу уңайсыз була башлагач, юлбарыс һавага очып китте. Җилең бер якта торсын, кошларың бер якта торсын!..

Шулай һавада ук кебек атылып бара торгач, алар күз камашырлык матур сарай янына килеп туктадылар.

— Безгә кирәк булган Бөкре бабай Аксакал менә шушы сарайда тора инде,— диде юлбарыс,— безгә аның үзен күргәнче шактый авырлыклар кичерергә

туры килер, син инде чыдарга тырыш, иң әлек безгә конфет бакчасыннан үтәргә туры килер, ул конфетларга син күңел салмаска тиеш, күп конфет ашаган кешенең тешләре авыртканын үзең дә беләсең, монда тешләрең авырта башласа, докторга күренеп, әллә никадәр вакыт үтәр. Икенче бакчада гел уенчыклар тулган булыр. Җаның теләгән уенчык шунда бар инде! Монда да син үзеңне кулга алырга тиешсең. Уенчыкларга күңелеңне бирә күрмә, юкса эш харап. Бәйрәмгә чаклы өйгә кайтып җитү түгел, йөз елда да кайтып өлгерә алмабыз. Үзең дә беләсең бит, без монда эш артыннан килгән. Бу бакчадан соң безгә хөрмә бакчасы кала. Монда аз гына караңгырак булыр. Шуның өчен бу бакчаны узганда күзләреңне йома күр, юкса харап булырбыз.

Алар Бөкре бабай Аксакалның сарай ишегалдына керделәр. Ишегалдына кергәч тә, конфет бакчасы башланды. Илаһем, ярабби! Нинди генә тәмле конфетлар юк монда! Һәммәсе Гайшәнең авызына үзләре керергә торалар.

Ләкин Гайшә аларны иснәп тә карамый.

Конфет ашап, аның тешләре авырткалаганы бар. Алар бу бакчаны зарарсыз гына үтеп киттеләр. Икенче бакчага керделәр. Монда уенчыкларның исәбе-хисабы юк! Берсе икенчесеннән матурраклар! Гайшә исә аларга илтифат итмәде. Чөнки уенчыкларың артык күп булса, аның кызыгы бетә.

Монда да тыныч кына үттеләр.

Иң соңгы караңгырак бакчага керделәр. Гайшә: «Абау, нинди караңгы», дип шырпы яндырып җибәрде. Шул минутта ук дөньяның асты өскә килеп, «шарт-шорт, трах-тррарах» дип, хөрмәләр төрле яктан ут булып атыла башладылар, аларга ут капты. Утлар төрле яктан очкын булып явалар иде.

Юлбарысның «харап булдык» диюенә каршы Гайшә, шатлыгына чыдый алмый, шаркылдап көлеп җибәрде. Шул арада ут эченнән чыккан, үзе дә ут кебек янып торган Бөкре бабай Аксакал Гайшәгә таба килеп кулын сузды.

— Ай-һай, Гайшүкхан! Килеп җиттеңме? Мин сине күптән көтә идем,— диде.— Бәйрәм көн җитә бит, бүләк алырга килгәнсеңдер,— диде, үзе Гайшәгә кулын сузды. Гайшә дә бабай белән күреште. Шуннан соң Бөкре бабай Аксакалга үзенең ни өчен килгәнен сөйләде.

— Юк, бабакай,— дип сүз башлады Гайшә,— мин синнән үзем өчен бүләк сорарга килмәдем. Тиздән бәйрәм җитә, минем әти белән әнигә бүләк бирәсем килә. Аларга нинди бүләк бирсәм, яхшырак булыр, шуны сорарга дип бире килдем. Үземнең уенчыкларым да бар, курчакларым да бар, ә этием белән әниемә бүләк итеп бирерлек бернәрсәм дә юк.

Гайшәнең сүзләре беткәч, Бөкре бабай Аксакал шаркылдап бер көлеп алды да:

— Ай, җүләрем син минем, ай, кечкенә генә Гайшугым син минем, ай, кечкенә генә былбылым син минем. Әти-әниеңә бүләк бирәсем килә, дидең, ә? Бик яхшы, бик яхшы. Менә без аларга синең белән иң яхшы бүләк бирербез, алла кушса! — диде бабай һәм кесәсеннән матур гына ике тартма чыгарды.

— Менә бусында (бер тартмасын күрсәтеп) тылсымлы инә булыр, өйгә кайткач, әниеңнән кечкенә генә канва кисәге сорап алырсың да, аның тишекләре буенча матур гына итеп әниеңнең борын яулыгына аның исемен чигәрсең. Ә менә бусында (икенче тартмада) тылсымлы каләм булыр. Бусы белән бәйрәм көнен котлап, этиеңә бер шигырь язарсың. Боларның һәр икесен бәйрәм көнне этиең белән әниеңә

бүләк итеп бирерсең. Хәзер инде үзегезгә кайтып китәргә дә ярый, юкса соңга калырсыз. Әтиең белән әниең кайтканда, сез инде өйдә булырга тиешсез,— диде бабай.

Кечкенә Гайшә белән юлбарыс, бабайга рәхмәт әйткәннән соң, өйләренә кайтып киттеләр. Гайшә күзен ачканда алар әтисенең язу бүлмәсендәләр иде.

— Шулай тиз килеп җиттекмени? — диде Гайшә. Юлбарыс җавап кайтармады, идәнгә җәелгән килеш тын гына сүзсез калды. Кайдан беләсең, бәлки ул бик арыгандыр?..

Икенче көнне Гайшә әнисенең борын яулыгына чигә башлады. Берничә көннән соң әнисенең борын яулыгында «Хәлимә» дигән сүз матур гына булып күренеп тора иде. Бәйрәм өчен бүләк әзер иде.

Шул ук көнне әтисенә дә бүләк әзерләнеп бетте. Гайшә аңа тылсымлы каләм белән түбәндәге шигырьне язды:

Котлы булсын, әткәем,
Синең гает бәйрәмең,
Бу шигырьне язучы
Кызың Гайшә, әткәем!

Шулай итеп, кечкенә Гайшә әтисе белән әнисе өчен кирәкле булган бүләкләрне бирәүгә дә белгертмичә генә хәзерләп куйды.

Әлбәттә, бәйрәм көнне бирер инде!

1914

КҮБӘЛӘК

Матур җәй көне. Таң ату белән бергә тора торган кечкенә кошчыклар әле анда, әле монда сайрашып, чиркылдашып, дөньяны яңгыраталар. Үлән сабакла-

рындагы чык бөртекләре, мең төрле төскә кереп, асыл ташлар кебек җемелдәшәләр, күзләрне камаштыралар. Шундый матур бер иртәдә бер кечкенә Күбәләк, урыннан-урынга күчеп, күңелләнеп очып йөри иде.

Бу күбәләкнең дөньяда тора башлавына ике генә сәгать әле. Яшь кенә булса да, гомеренең кыска булуын белгәнгә, ул бу дөньяның рәхәтен, ямен, шатлыгын татып калырга ашыга иде.

Бакчадагы чәчәк исләре, яфрак исләре Күбәләкнең башын әйләндерә иде.

— Уф алла, тәкатем калмады, бөтен буыннарым талды, аз гына ял итеп алыйм әле,— дип, ул үзалдына сөйләнеп куйды. Рәхәтләнеп кояш җылысында канатларын җәеп киптерә башлады. Агып торган кояш нурларында аның канатлары тагын да матуррак, ямьлерәк күренә иде.

Шул арада аның колагы янында гына «бум, без, выз, гззз» итеп выжлаган тавыш ишетелгән кебек булды. Бу безелдәп узган нәрсә Умарта корты иде. Күбәләкнең үзенә дә, аның матур канатларына да Умарта кортының исе китмәде. Ул ашыгып, чәчәкләрдән бал суырырга, эш белән бара иде. Менә ул чәчәккә кунды. Чәчәкнең төрле якка җәелеп торган яфраклары арасына эчкәрәк керергә тырышты һәм шунда кереп тәмам югалды. Чәчәк эченнән чыкканда аның бар гәүдәсе, канатлары чәчәк тузаны белән капланган иде.

— Бая ул эш белән ашыгып барганга, минем белән исәнләшә дә алмады, хәзер инде минем белән күрешер! — дип уйласа да, булмады, Умарта корты әүвәлгечә Күбәләккә илтифат итмәде, ашыгып кына икенче чәчәккә барып кунды.

Күбәләкнең моңа кәефе китте. Умарта кортының чәчәктән чыкканын көтеп тора башлады.

Менә Умарта корты күренде. Күбәләк ашыгып сүзгә кереште:

— Карале син бу агайны. Анда нишләп ятасың? Мин әллә кайчаннан бирле сиңа карап торам, ә син миңа илтифат та итмисең,— дип кычкырды.

— Күрәсең бит, мин эшләп йөрим. Кояшта канатларыңны киптереп, матурлыкта назланып эшсез ятканчы, син дә үзең өчен файдалы булган берәр эшкә керешсәң, шәбрәк булыр иде дип уйлыйм. Дөньяда рәхәт өчен генә яшәп булмый шул, җаным. Һәр нәрсәне тырышып, үз кул көчең белән табарга кирәк, гомер кыска, картлык тиз килеп җитә, үзең исән чакта эшләп калсаң, картаймыш көнеңдә кеше кулына калмассың. Җаның тыныч булыр. Шуның өчен дә вакытны бушка үткәрергә ярамый.

Шулай диде дә Умарта корты тагын очып китте.

Умарта кортының бу гакыллы сүзләре Күбәләккә ошап бетмәде.

— Менә җүләр.— Шуннан башка әйтер сүз табалмады. Шул инде, «Җүләрнең бүреге җүләр булмый, үзе җүләр була», диләр. Эшлә, имеш! Эшләми ни?! Нигә мин тыныч башымны тынычсыз итим? Алла рәхәт биргән икән, шул рәхәтне татып калырга кирәк.

Озак та үтмәде, безнең Күбәләк икенче күбәләкләр белән очрашты. Алар күрештеләр. Бер-берләрен куышып, һавада уйнарга тотындылар. Бара торгач, уен да туйдырды. Бер-берләре белән саубуллашып, төрлесе төрле якка таралып киттеләр. Безнең Күбәләк бик сусаган иде. Калын имән астында үскән үләннәрдәге чык тамчылары әле кояш нурына эләкмәгәннәр, парга әйләнеп, һавага очарга өлгермәгәннәр иде. Безнең Күбәләк шул яфракларның берсендәге чык суын рәхәтләнеп эчте дә, бераз тынып торыр өчен, ак чәчәккә кунды. Күзләрен йомды. Менә

хәзер йокыга китәм дигәндә генә, колагына мыштырдаган тавышлар ишетелә башлады. Ялкау гына күзен ачып караса, ни күрсен, түбәндә — кырмыска оясында кырмыскалар «у-у-у-у» килеп кайнашалар. Кайсы кечкенә генә таш күтәргән, кайсы кечкенә генә гөмбә кисәге күтәргән, кайсы тагын башка бер әйбер күтәргән, мәж килеп эшләп йөриләр. Кайсы өенә керә, кайсы өеннән чыгып чаба иде.

Безнең Күбәләкнең бу шау-шуга эче пошты, чыдарлык сабырлыгы калмады.

— Карагыз әле, әфәнделәр, бераз шаулашмый торырга ярамыймы? Монда сезнең тавышыгыздан колак чукракланып бетте. Кешегә ял итәргә дә ирек бирмисез, әллә дөньяның астын өскә әйләндермәкче буласызмы? — дип дулый башлады.

Күбәләкнең болай шапырынуы кырмыскаларның колагына да кермәде. Аларның һәрберсе үз эше белән мәшгуль иде. Кырмыскаларның башлыгына гына Күбәләкнең сүзләре кызыклы тоелды. Чөнки ул дөньяда эшсез ятучылар да бар икәнен бу көнгә кадәр белми иде. Күбәләкне ул чын күңеленнән кызганды. Карт кешенең сүзләре, бәлки, бушка китмәс дип, Күбәләкне үгетли башлады.

— Җаным, син әле яшь, алай дуамалланып, гомереңне әрәм итмә, дөньяда бот күтәреп ятканнарның ахырда теләнче булып йөргәннәрен әллә ишеткәнең юкмы? Адәм рәтле булып яшисең килсә, яшьлегеңдә эшләп кал. Безнең эшебез күп, шау-шуыбыз белән башыңны томалыйбыз икән, икенче урынга күч, туган, — диде.

Карт кырмысканың да гакыллы сүзләре бушка китте. Күбәләк аларның берсен дә колагына алмады.

— Дөньяда рәхәт дигән нәрсә бар икән, гомерне рәхәттә үткәрергә кирәк, уйнарга, көләргә кирәк, шат-

ланып очып йөрергә кирәк,— диде дә очып китте. Шул арада: «Абау, нинди матур күбәләк, моны ничек булса да тотып алырга кирәк!» — дигән тавыш ишетелде. Бу — күбәләкләр тотарга чыккан Гали тавышы иде. Галинең кулында озын сап эчендә нечкә генә кызыл җептән теккән капчык — күбәләк тоткыч иде. Малайның тавышына Күбәләк шатланды. «Ул бала мине куар, мин аңардан качармын, вакыт үткәне дә тоелмас»,— дип, Күбәләк әле ары, әле бире килеп оча башлады. Гали аның артыннан йөгерергә тотынды. Шактый куышып йөргәннән соң, Гали арыды, битләре кызарды, маңгаеннан борчак-борчак тирләр тәгәри башлады.

— Юк, артык куар хәл юк, сабакларым да әзерләнмәгән, аларны әзерлисем бар, хәлфә орышыр, кайтып шуларны эшләп бетерергә кирәк,— диде дә өенә кереп китте. Галинең «эшләргә кирәк» дигән сүзләре Күбәләкнең кәефен җибәрде. Ул тагын ялгыз калды. Һәммә кеше эшли, ул гына эшсез. Ялгыз уйнау да күңелсез була башлады. Ләкин соң иде инде.

Кояш баеды, караңгылана башлады. Күбәләкнең уйныйсы да, йоклыйсы да килми иде. Эшкә өйрәтүче булса, эшкә дә өйрәнер иде, Умарта корты очрамасмы, кырмыскалар күренмәсме дип, ул урманга таба юнәлде. Ләкин аларның берсен дә очрата алмады. Чөнки алар көне буе эшләп арыганнар, йоклыйлар, иртәгәсе көнгә көч җыеп яталар иде.

Төнлә дә үз тамакларын үзе туйдыру артыннан йөрүчеләр юк түгел икән. Менә төнлә генә күрүче Ярканат та үзенә азык эзләп чыккан иде. «Мине эшкә өйрәтсә, ул өйрәтер инде»,— дип, бичара Күбәләк туп-туры аның авызына барып керде. Дөнья шулай инде ул, нинди упкынга барып абынасын алдан белеп булмый, — ~~берәү дә белми.~~

1914

ГАРМУН

Мин гармун ярата идем. Бер җирдән гармун тавышы ишетсәм, шунда бармый калсам, әллә нәрсәм югалган кебек була иде, көне буе эчем пошып йөри идем.

Гармуны булган кешеләрне, аңарда уйный белгәннәрне, уйнаганны тыңлый алган кешеләрне иң бәхетлеләрдән санап, боларның барысыннан да мәхрүм калган кешеләрне иң бәхетсезләрдән санап йөри идем.

Гармун турындагы уйлар минем белән бергә яталар, минем белән бергә торалар иде.

Мин мулла баласы. Мулла балаларына гармун

тоту түгел, хәтта аны тыңларга да ярамый, гармунлы кешеләр белән дус булырга да ярамый иде.

Ул чакта шулай әйтәләр иде. Мин моны яхшы белә идем. Шулай булса да, күңел сөйгән нәрсәгә каршы торып булмый, күрәсең. Мин дә тора алмадым. Ничек булса да гармун сатып алып, шуны уйнарга өйрәнү теләге миңа тынгылык бирмәде.

Мулла баласының кулына акча керүчән була. Әле берсе садака итеп бирә, икенчесе күчтәнәч алырсың дип бирә. Ничек булса да: акмаса да, тама инде. Шул тамчыларны мин дә җыя башладым. Берике ай җыйдым. Җитмеш өч тиенгә тулды. Серне гармунчы Хөсәенгә ачтым. Таза тәнле, киң күкрәкле, урта буйлы Хөсәен исемле бу егет минем әбиләрдә ялчылыкта тора иде. Бик оста гармун уйнаганга, аны һәммә кеше «Гармунчы Хөсәен» дип йөртәләр иде.

— Хөсәен агай! Минем сиңа бер сер әйтәсем килә,— дидем мин аңа.

— Йә, сөйлә,— диде ул.

— Игайны күпмегә алырга мөмкин,— дидем (авыл егетләре арасында гармунны игай диләр).

Ул көлеп җибәрде. Минем серем игай турында булачагын ул башына да китермәгән икән.

— Сиңа аны белергә ярамый, син мулла баласы лабаса,— диде ул.

Бу сүзләре белән ул минем иң әрнегән җиремне чеметеп алган кебек булды. Ләкин ни булса да серне бирмәскә тырыштым.

— Әллә әйтсәң, үзеңә кимчелек килә дип уйлыйсыңмы? Беләсем килмәсә, сорамас идем, беләсем килә шул: мин гармун яратам, сатып аласым килә, моның өчен бераз җыйган акчам да бар. Дөрес, мулла баласына гармун сатып алу ошамас та ошавын, ләкин бит мин берәүгә дә күрсәтмәм,— дидем.

Хөсәен агайның күзләре акайды, ул эшеннән туктады, келәт бусагасына утырып, тәмәкесен чорный башлады. Мин дә аның янына утырдым. Йөрәгем тибә, мин аның җавабын көтәм. Минем азрак каушаганны ул да сизде булса кирәк, бөтенләй икенче тавыш белән сөйли башлады:

— Гармун аласым килә диген, ярый, аның инде төрлесе була. Яхшырагын алсаң, биш-алты тәңкә тора, начарын алсаң, андыйларын бер сумга да табып була. Бак, хәзрәт белә күрмәсен, юкса икебезне дә авылдан куар...— диде.

Хөсәен агай соңгы сүзләрен дә әйтеп бетерергә өлгермәде, минем башта «тагын егерме җиде тиен табарга кирәк икән» дигән фикер туды. Бәхет ишеге ачылса, ачыла ул. Егерме җиде тиен өчен күп борчыларга туры килмәде. Өйгә кайтуга ат җигелгән, җиңгине алып килергә мине генә көтеп торалар иде.

Кодагый әби мине ярата. Менә өч ел тула инде, җиңги артыннан һаман мин йөрим. Барган саен егерме биш тиеннән дә ким эләкми. Бу юлы да, инша алла, тамар әле!..

Бүген базар көн. Мин авыл очына чыгып, Хөсәен агайның кайтканын көтәм. Иртә сәгать уннан бирле мин шунда, ашаган-эчкән юк. Сәгать уникеләрдә базардан кайта башладылар, халыкның иге-чиге юк. Көн кичкә авышып бара. Кайтучылар бөтенләй азайды. Хөсәен агай һаман юк. Алар бүген базардан такта алганнар икән. Шуңа күрә кичеккәннәр.

Көтүләр дә кайтты, кояш та баеды. Картлар ахшамга да чыктылар, Хөсәен агай һаман юк. Мин чыдый алмадым, базар юлы белән аларга каршы киттем. Бер яктан аның шулай кичегүенә шатлана да идем. Берәү дә күрмәс, берәү дә белмәс!

Мин барам да барам. Тизрәк гармунымны күрә-

сем килә. Икенчедән куркам да. Җен-пәри чыкса, нишләрмен? Бүрегә очрасам нишләрмен? Вакыты-вакыты белән бөтен тәнем чымырдап китә. Караңгы төшеп килә бит. Ләкин мин бернигә дә карамыйм, барам да барам.

Шул арада ерактан атлылар күренә, миңа җан кергән кебек була... Тукта, әнә гармун тавышы, Хөсәен агай уйный, минем гармунда уйный! Нинди моңлы итеп уйный!

Мин дә шулай уйнармын, һәммә кеше мине белер, мине тыңлар өчен әллә кайлардан килерләр. Зурлар мине үз араларына кертерләр. Мин уйнармын, алар миңа кушылып җырларлар! Уф, алла!..

Мин ялгышмадым. Болар дөрестән дә Хөсәен агайлар булып чыктылар. Хәзер инде мин моңлы «Зиләйлүк» тавышын ачык ишетәм...

Мин гармунлы булдым, теләгемә ирештем. Ләкин бу гармун минем өчен бер бәла булып чыкты. Иң элек мин уйный белмим, икенчедән, аны кайда куярга урын таба алмыйм. Кайда куйсам да, күрерләр кебек тоела. Кайда яшерсәм дә, табарлар төсле була. Бәлки, минем гармун турысында уйлаган кеше дә юктыр, «курыкканга куш», диләр бит. Миңа да һәрнәрсә булырга тиеш төсле тоела. Хисапсыз күзләр миңа карыйлар кебек күренә. Кайда аңарда уйнау, ялгыш кына тавышы чыга күрмәсен, булса эш харап дип кот очып йөри.

— Бу башыма үзем тапкан бәладән ничек котылырга? — дип уйлап йөри торгач, шундый фикергә килдем:

— Шундый урын табарга кирәк, аны берәү дә белмәслек, анда барып йөрмәслек булсын. Шулай уйлап йөри торгач, башыма кылт итеп мәктәп чормасы төште. Җәй көне мәктәпнең чормасына түгел, үзенә

дә кереп йөрүче юк. Әйе, шуннан да яхшырак урын табып булмас! Бу фикер миңа әлеге бәладән котылу юлын күрсәткән кебек булды. Болай үзем куркаграк булсам да, бу минутта минем батырлыкның чиге юк иде.

Төнгә-нигә карамыйча мәктәп чормасына менеп, бакча ягына чыккан кәрнизгә гармунны яшердем. Өстемнән тау төшкән кебек булды.

Бу вакытта җәйнең иң эссе көннәре иде. Бер җомга чамасы мин гармунның янына да бармадым. Беркөнне әби белән әни күрше авылга әбиләргә кунакка киттеләр. Апалар, абыйлар кырга тары утарга чыктылар. Өйдә берүзем генә калдым. Исемә кылт итеп гармуным төште.

— Тукта әле, барып карыйм, хәзер иркенләбрәк уйнарга да мөмкин булыр,— дип, мин тиз генә мәктәп чормасына үрмәләдем. Қарыйм, игай үз урынында тора, аның өстенә бераз тузан гына кунган. Аны кулга алдым, тузанын сөрттем, бармакларым белән телләренә бастым. Игайны бер тартып җибәргән идем — шаккаттым. Ул моңлы тавыш чыгару урынына ютәл авыруына дучар булган кеше кебек «их, мих, пыш!» дигән тавышлар чыгара.

Аңар ни булган дип сорамакчы буласызмы? Нәрсә булсын, ул картаймаган, ютәл авыруына да сабышмаган. Қамыр, җилем белән бер-беренә ябыштырылган кәгазьләрен тычканнар кимергәннәр...

Тиз генә чабып барып, чоландагы тоз капчыгын алып килдем, игайны шул капчыкка тыктым, янына йодрык зурлыгы берничә таш куйдым. Қараңгы төшкәч, тегермән суының иң тирән җиренә илтеп ташладым!

Хәзер уйлап торам-торам да исем китә: киң далаларны яңратып, күңелне ярсыта торган курай бар.

Үзенең кыска, шулай да гаять моңлы тавышы белән колакларны кытыклый торган думбра бар. Уйнаганда күңелдә булган бар шатлыкны, бар кайгыны тышка чыгара торган саз бар. Шулар белән бергә моңлы гармун бар. Мин ничек итеп аны суга ташлый алдым икән?!

1915

ИКЕ ҖИРДӘ ИКЕ — ДҮРТ

(Швед халык әкиятеннән)

Куян белән тиеннең дуслашуларына байтак вакыт узган иде. Шуңа күрә алар бер-берсенә эндәшкәндә, ияссә әфәнде, куррә әфәнде дип эндәшмичә, туп-туры ияссә, куррә[1] дип кенә эндәшәләр иде.

— Исән-сау йөрисеңме, Ияссә? — диде тиен үзенең дустына. Алар урман алдындагы яланда очраштылар.

— Аллага шөкер, Куррә, үзең бик исән генәме? Анда-монда этләр өргәнен ишетмәдеңме? — дип сорады куян.

— Кыңгыраучының Приссәсе генә үзенчә өреп маташкан була шунда. Ләкин инде Приссәдән куркыр хәл юк. Аның өрүе колагыма да керми,— диде Ияссә.

— Кара әле, Ияссә, әйдә без синең белән табышка чыгыйк! Мин бу турыда әллә кайчаннан бирле уйлап йөрим, бик күңелле булыр иде, ни генә тапсак та, уртак булыр иде. Беребез дә артык алмас иде. Син дә мин алган хәтле генә алыр идең. Менә шәп булыр иде дә соң! Чынлап әйтәм, әйдә китик,— диде Куррә.

---

[1] Швед халкы хайваннарга төрле исемнәр бирергә ярата. Мәсәлән, аюны — *наллә,* тиенне — *куррә,* куянны — *ияссә,* мәчене — *муррә* дип атыйлар. *(Ф. Агиев.)*

— Ярый, синең белән булганда, мин дөньяның теге ягына барырга да риза.

«Әйткән сүз — каккан казык» дигән кебек, безнең дуслар да табыш эзләп киттеләр. Шулай бара торгач, алар бер миләш агачы янына җиттеләр. Куррә яшен ташы кебек атылып миләш агачы башына менеп китте. Агач башыннан үзенең юлдашына миләш ташлый башлады. Ияссә дә бөтен эшне Куррәдән генә эшләтми иде. Ул үзе дә җае килгәндә бик тырышып эшли һәм дусты Куррәне дә онытмый иде. Мәсәлән, кәбестә яки шалкан бакчасына очраса, яфракларны өзә дә Куррә янына чаба. Кыскасы, бу дуслар сүздә генә түгел, чын мәгънәсендә дуслар иде.

Бервакыт Ияссә белән Куррә юлда дүрт алма таптылар. Бу табышка алар бик шатландылар, чөнки алмалар искиткеч матурлар һәм түп-түгәрәкләр иде. Әлбәттә, бу алмалар күктән төшмәгәннәр, аларны иртә белән мәктәпкә барганда Каллә төшереп калдырган иде. Калләгә бу алмаларны әнисе бүләк иткән иде. Чөнки Каллә бик тырышып укый һәм иптәшләре арасында үзен беренче итеп тота иде. Әлбәттә, Калләнең капчыгында дүрт алма гына түгел иде. Анда китаплар, бер кисәк күмәч, бер шешә сөт, бер кисәк эремчек тә бар иде. Болар, зуррак булганга, капчыкта калганнар, ә түгәрәк алмалар исә капчыктан берсе артыннан берсе төшеп киткәннәр. Каллә моны сизми дә калган.

Менә безнең дуслар — Куррә белән Ияссә — табышларын бүлә башладылар. Элек Куррә бүләргә тотынды. Ул болай бүлде: бер алманы дусты Ияссәгә бирде, өчесен үзенә алып калды.

— Тукта әле, туган, син дөрес бүлдеңме икән? — дип, Ияссә алмаларны үзенчә бүләргә кереште. Ул да Куррә кебек өчесен үзенә алып калды, ә берсен Куррәгә бирде.

— Кара әле, Ияссә, бу бүлү бер дә яхшы булып чыкмады бит әле,— диде Куррә. Мәсьәлә катлауланды, читенләште. Ничек итеп тигез генә бүләргә икән моны дип, иптәшләр уйлаша башладылар.

Шулвакыт безнең Каллә, татлы тамакланып китеп, бер алмасын ашарга уйлады. Капчыгына кулын тагып караса, ни күзе белән күрсен — алмалардан җилләр искән! Шунда, якында гына төшеп калганнардыр дип, Каллә алмаларын эзләп кире кайтып китте. Кайтып килгәндә, ни күзе белән күрсен, юлда Ияссә белән Куррә утыралар. Боларны күргәч, Каллә исе китеп туктады. «Бу бит Куррә белән Ияссә»,— дип кычкырып җибәрде. Аларның янына барып: «Карагыз әле, дускайлар, сез минем алмаларны очратмадыгызмы?» — дип сорады.

— Менә без баядан бирле шул дүрт алманы бүлеп маташабыз да, ләкин һаман да тигез итеп бүлеп булмый, аптырап беттек инде,— диде Куррә.

— Бу бер дә авыр түгел,— диде Каллә.— Сезнең һәр икегезгә икешәр алма тия ич!

— Менә сиңа! — дип, Куррә белән Ияссә икесе дә беравыздан кычкырып җибәрделәр. «Син аны ничек итеп шулай тигез итеп бүлдең?» — дип, Каллләдән сорадылар.

— Сез бигрәк кызык халык икән, шуны да белмәскә. Мин мәктәптә укыйм ич. Анда безне хисапка өйрәтәләр. Ике җирдә икең дүрт икәнен бездә иң кечкенә малай да белә,— диде Каллә.

Калләнең бу сүзләре безнең Куррә белән Ияссәне аяктан ега язды, беразга аларның телләре бәйләнгән кебек булды. Тора-бара гына исләренә килә башладылар.

— Әйтче, зинһар, син бөтен нәрсәне дә шулай беләсеңме? — дип сорадылар Калләдән.

— Әйе,— диде Каллә,— ике җирдә икең дүртне генә түгел, җиде җирдә җидене дә беләм.

Шуннан артыкны Куррә белән Ияссә инде сораша да алмадылар. Калләнең бу хәтле галим кеше булып чыгуы аларның гакылын алды.

Калләнең гыйлемлелеген файдаланып калырга уйлап, әлеге алмаларны ике икең дүрт кагыйдәсе буенча бүләргә керештеләр.

— Туктагыз әле, дускайлар, алмаларны бүлүен бүләсез дә, алар бит минем алмалар,— диде Каллә.

— Менә җитмәсә тагын! — диештеләр безнең дуслар,— ул инде моны да белеп алган. Бу малай ахыры дөньядагы барлык гыйлемне белеп бетергәндер. Безгә дә шулай, мәктәпкә кереп, аның кебек бераз укысак зыян итмәс иде,— диештеләр дуслар бер-берсенә.

— Менә монысы ичмаса шәп фикер,— диде Каллә.— Әйдәгез, теләсәгез хәзер үк мәктәпкә алып барам. Сез анда көрсиләр[1] артында тын гына утырырсыз. Сабак вакытында шау-шу куптарган кешене бөтенләй мәктәптән чыгаралар.

— Анда, сезнең мәктәптә этләр юктыр бит? — дип сорады Ияссә.

— Мәктәпкә этләр нишләп йөрсеннәр? Хәер, кайсы вакытта кыңгыраучының Приссәсе килеп, көрсиләр астында качып утыргалый. Ләкин аны шунда ук куып чыгаралар.

— Менә шул әллә нигә бер килә торган Приссә, бүген дә килеп, безне тешләсә нишләрбез?

— Сез бигрәк арттырып җибәрәсез инде, Приссә кебек юаш эт дөньяда да юк. Ул колагыннан тартып йөртсәң дә бернәрсә дә эшләми, көлә генә.

— Ул көлә генә? — дип сорадылар Ияссә белән Куррә, исләре китеп, һәм бер-берсенә караша башла-

---

[1] *Көрси* — парта мәгънәсендә.

дылар. Этләр дә көлә белә микәнни? Алар бу турыда гомерләрендә беренче мәртәбә ишетәләр. Мәктәптә бөтен нәрсәгә өйрәнеп була, күрәсең, дип уйлашып алдылар дуслар.

— Бер караганда, без алай ук куркаклар түгел! — дип, Ияссә батыраеп алды. Ияссә белән Куррә кебек шәп сикерүчеләргә мәктәп юлы бик кыска булды. Берничә минуттан инде алар көрси астында иде. Аларны беркем дә күрмәде.

Һәммә шәкерт мөгаллимне урыннарыннан торып каршы алдылар. Сабак башланды. Мөгаллим шәкертләрдән: «Сигез җирдә сигез ничә була?» — дип сорады. Моны белү җиңел эш түгел инде дип уйлады Куррә. Дуслар, чын күңелләрен биреп, хәлфәнең һәр сүзен ишетеп калырга тырыштылар.

Гөнаһ шомлыгы, нәкъ шул вакытта дәрескә Приссә килеп кермәсенме? Хәлфә аны күрү белән куарга тотынды. Башка вакыт булса, Приссә чыгып та киткән булыр иде. Ләкин аның борынына бөтенләй ят ис килеп керде. Эт этлеген итми булмый шул! Әнә Приссә дә бер төчкерде, бер йөткерде дә дөньяны куптарып өрә башлады. Шәкертләр урыннарыннан тордылар, һәммәсе як-якка карана башлады, сыйныфта шау-шу купты.

Ияссә белән Куррәнең бәхетенә каршы, классның бер тәрәзәсе ачык калган. Менә өстәлләр өстеннән Куян сикерә, Тиен сикерә, алар артыннан Приссә сикерә! Харап, сыйныфта кыямәт купты. Хәлфәнең сөале дә онытылды.

Ияссә белән Куррә, ук кебек атылып, урманга таба чабалар. Юаш Приссә дә алар артыннан чаба. Телен асылындырып чаба. Башка вакытта, чаба башласа, өрә дә иде, хәзер өрүдән дә тукталган. Приссә үзенең дошманнарын, урманга хәтле куа барса да,

тота алмады. Урманга җиткәч, Куррә ук кебек агач башына менеп китте. Агачның куе яфраклары аны күздән югалтты. Приссә, агач башына карап, койрыгын бутый-бутый өрә башлады. Ул шулай Куррәгә карап өреп торганда, Ияссәнең дә эзләреннән җилләр искән иде. Ул әллә кайчан куе куаклар арасына качып өлгергән.

Картларның «Авызың ашка тисә, борының бозга тия» дигәннәре шул буладыр инде. Приссә агач төбендә торып-торып эш чыкмагач, элеккечә койрыгын түгәрәкләндереп, өенә кайтып китте. Усал Приссәдән котылгач, безнең дуслар тагын очраштылар. Мәктәптә чагында алар көләргә өйрәнгәннәр, шуңа күрә хәзер бөтен урманны яңгыратып көләләр иде. Алар көлешеп кенә калмадылар, үзара мактаныша да башладылар.

— Уйлап-уйлап торам да, Ияссә дустым, без бу хәтле үк куркак түгелбез икән әле дип шатланам,— диде Куррә, үзе шулвакыт, Ияссәнең Приссәдән ничек качып чабуын искә төшереп, оста гына көлеп тә алды.

— Юк, син менә, дускай, Приссәнең чыйнавын ишетсәң иде,— дип, Ияссә сүзне икенчегә борып алды,— эчең катып көләр идең.

— Приссә акыллы ул, колагыннан өстерәп йөртсәң дә көлә генә ул диләр бит шунда,— диде Куррә.

— Ә без, җүләр, шуңа ышандык тагын, Каллә күп белә, имеш.

— Хәер, мәктәптә күп нәрсәләргә өйрәнеп була булуын. Ләкин ике җирдә икең дүрт икәнен белү бар нәрсәдән дә авыррак, күрәсең.

1915

НИ ӨЧЕН ДӨЯНЕҢ АРКАСЫНА БҮКӘН[1] ҮСКӘН?

Борын-борын заманда, дөнья әле яңа гына яратылган, хайваннар кешеләр файдасына эшли генә башлаган вакытта бер Дөя булган, ди. Дөянең яши торган урыны да үзе кебек үк күңелсез сахра булган, ди. Дөянең мондый күңелсез сахрада торуының бер сәбәбе бар икән, ул ифрат та ялкау икән. Адәмнәргә файда китерер өчен аның мәшәкатьләнәсе килми икән. Ул үзенең тамагын яшел яфраклар, төрле чәнечкеле үләннәр белән туйдыра икән. Ул бу үсемлекләрне дә бик ялкауланып кына ашый, ди. Инде берәр кеше аның белән сөйләшә башласа яки аңар берәр сүз кушса, бу Дөя «бихыр» дип төчкереп кенә җавап биргән.

Дүшәмбе көн иртә белән Дөя янына иярле, авызлыклы килеш бер ат килеп туктаган.

— Дөя, Дөя, дим, ташла инде ялкаулыгыңны, рәхәтләнеп безнең белән чабып эшләп йөр! — ди ул Дөягә. «Бихыр!» — дип кенә җавап кайтарды, ди, Дөя аңар. Шуннан соң Ат кайтып китте, ди, Дөядән алган җавабы тугрысында Адәмгә сөйләде, ди.

Тагын бераздан Дөя янына, авызына таяк кабып, бер Эт килде, ди.

— Дөя, Дөя, дим, ташла шул ялкаулыгыңны, кузгал урыныңнан, менә безнең кебек, әйбер ташып, эшләп чабып йөр! — диде, ди, Эт Дөягә. «Бихыр!» — дип кенә җавап кайтарды, ди, Дөя Эткә. Эт кайтып китте һәм Адәм янына барып Дөядән ишеткәнен сөйләде, ди.

Озак та үтмәде, әлеге Дөя янына бер Үгез килде. Үгезнең муенында сука камыты иде.

---

[1] Дөянең аркасындагы шешекне бәгъзе бер җирләрдә «үргәч» дип тә йөртәләр. *(Ф. Агиев.)*

— Дөя, Дөя, дим, ташла шул ялкаулыгыңны, кузгал урыныңнан, менә безнең кебек сукалап, эшләп гомереңне үткәр,— диде Үгез Дөягә. «Бихыр!» — дип кенә җавап кайтарды моңа Дөя. Үгез дә ишеткәнен Адәмгә кайтып сөйләде.

Кич җиткәч тә, әлеге Адәм Атны, Этне һәм Үгезне чакырып алды.

— Өч хайван, өч дус, мин сезне бик кызганам, ләкин шулай булса да, сезгә бернәрсәне аңлатырга тиешмен: әлеге сезнең һәрберегезгә «бихыр» дип кенә җавап кайтарган Дөя эшкә өйрәнмәгән, юкса инде ул күптән безнең янга килгән булыр иде. Шуңа күрә моннан соң мин аны артык борчымаска уйлыйм. Моның өчен сезгә тагын да күбрәк эшләргә туры килер, чөнки Дөя эшен кем дә булса эшләргә тиеш ләбаса!

Адәмнең бу сүзләре әлеге өч хайванны бик ачуландырды. Алар, сахра кырыенарак китеп, үзара сөйләшә, кычкырыша башладылар.

Шул вакытта ялкау Дөя әлеге өч хайван янына килде, үзе ялкау гына үлән чәйни иде. Өч хайван өстенә карады да көлеп җибәрде. Шуннан соң, ялкау гына атлап, сахра эченә кереп китте.

Озак та үтмәде, бу өч хайван бер Җенне күрделәр. Бу Җен бөтен сахраларны караштыргалап йөри торган Җен иде. Ул, комнан зур өермә күтәреп, шул өермә эчендә йөри иде, чөнки ул Җен иде. Җеннәр өермә эчендә генә йөри бит. Сөйләшәсе килеп, ул әлеге өч хайван янына туктады.

— Бөтен сахраларның патшасы булган Җен, әйтсәңче, зинһар, дөньяның әле яратылган гына чагында шулай эшләми яту яхшы эшме? — диде Ат.

— Әлбәттә, начар,— диде Җен.

— Без дә шулай уйлыйбыз,— дип, Ат тагын сүзгә кереште.— Әнә синең күңелсез сахраңда озын аяклы,

озын муенлы Дөя дүшәмбе көннән бирле тузан хәтле булса да эш эшләгәне юк. Аның йөгереп тә йөрисе килми.

— Сез беләсезме, ул хайван бит минем Дөям була, бөтен Гарәбстан алтынын тотып ант итәмен,— диде Җен.— Ул сезгә нәрсә турында сөйләде.

— Нәрсә сөйләсәк тә, ул безгә «бихыр» дип кенә җавап кайтарып торды, үзенең тагын эшлисе дә килми! — диде Эт.

— Тагын ни дә булса сөйләдеме? — дип сорады Җен.

— Фәкать «бихыр» дип кенә торды, үзенең әле сука сукалыйсы да килми,— диде Үгез.

— Яхшы, менә тагын бераз көтсәгез, мин күрсәтермен аңар «бихыр»ны,— диде Җен.

Шуннан соң Җен, үзенең өермәсенә чолганып, сахра эченә кереп югалды. Бераздан ул ялкау Дөяне эзләп тапты. Бу вакытта ялкау Дөя су кырыенда, үзенең суда күренгән сурәтенә карап, матурланып тора иде.

— Минем озын муенлы ялкау дускаем,— дип Җен сүзгә керeште,— һәр урында миңа синең эшсезлегең, ялкаулыгың тугрысында сөйләделәр, бу ниткән эш, шундый яңа дөнья яратылганда эшсез тору мөмкинме? — диде Җен. Дөя һаман «бихыр» дип кенә җавап бирде.

Җен утырды. Кулы белән яңакларына таянып, тирән уйга калды. Ул сихергә керешкән иде. Ә Дөя һаман да үзенең матурлыгына исе киткән кебек суга карап тора иде.

— Үзеңнең ялкаулыгың аркасында, дүшәмбе көннән бирле тик ятасың, ә өч хайван синең өчен азапланып эшлиләр,— диде Җен.

Дөянең моңар да бик исе китмәде, «бихыр» дип кенә җавап бирде.

— Мин синең урынында булсам, бу «бихыр» дигән сүзеңне әллә ничә мәртәбә әйтеп тормас идем, ә син үзеңнең ялкаулыгың аркасында һаман бер сүзне сөйләп торасың, мин синең ялкаулыгыңны күрәсем дә килми, син эшләргә тиеш.

Моңа каршы да Дөя «бихыр» дип кенә җавап бирде. Шул сүзне әйтеп кенә бетергән иде, менә Дөянең аркасы күбә башлады: менә күбә, менә күбә. Элек Дөя үзенең аркасы белән бик мактана иде, чөнки аның аркасы бик тигез иде. Менә күбә, менә шешә башлады Дөянең аркасы. Шулай күбә торгач, Дөянең аркасына зур бер «бихыр» үсте, Дөянең хәтерен саклар өчен бу «бихыр»ны «бүкән» дип атадылар.

— Менә күрәсеңме? — диде Җен.— Бу инде синең үзең теләп үстергән бүкәнең. Син эшләргә теләмәдең, шуңа күрә аркаңа бүкән үсте. Бүтәннәр дүшәмбе көн иртәдән бирле эшләп киләләр. Бүген кече атна инде, хәзер син дә эшли башларга тиеш.

— Аркамда шундый бүкән килеш ничек эшли алыйм мин? — диде Дөя.

— Син инде, туганым, бу турыда алдан ук уйлаган булырга тиеш идең, инде бит өченче көн эшләмисең. Хәзер син өчәр көн ашамый-эчми эшләп тора алырсың. Аркаңдагы бүкәнең сиңа азык булыр. Син хәзер бар да баягы өч хайванга кушыл, үзеңне әдәпле генә тот!

Җеннең шушы сүзләреннән соң Дөя, сахрага чыгып, баягы өч хайванга кушылды. Шул көннән бирле аның бүкәне һаман да аркасында йөри.

1915

ЗУР СУГЫШ

Мондый вакытта без Сәлим белән дус кына тора идек. Ләкин тормыш үзгәрми тормый икән. Сәлим белән минем арада зур сугыш башланды. Һәрнәрсәнең сәбәбе булган кебек, безнең сугышның да сәбәбе юк түгел иде. Эш болай булды.

Бу ел мәктәптә укулар тукталгач, без авылга кайттык. Һәр җәйне мин ни булса да эшләп өйрәнгәнгә күрә, бу ел да шулай ни дә булса эшләп, күңелле генә итеп җәйне үткәрергә уйладым. Үткән ел мин күбәләк куып йөрдем. Ул эшем файдасыз булып чыкмады. Җәй буена төрле күбәләкләр җыеп, берничә тартмадан матур гына бер ящик ясап, аларны шунда куйган идем, кипкәч, бигрәк тә матур булып чыктылар. Мин ул күбәләкләремне килгән бер кешегә күрсәтеп мактана идем. Мактанырлык та иде шул!

Бу ел җәйне балык тотып уздырырмын дип уйлап куйдым. Беркөнне болынга, су буена чыгып, матур гына урын да сайлап куйдым. Курташ дигән елга безнең болынлыкны ярып үтә. Аның ярларында куаклар, агачлар үсә. Шунда бер матур гына урынны сайлап «үземнеке» дип атап куйдым. Урын минеке булган кебек, бу урынның суындагы балыклар да үземнеке иде. Һәркөн таң алдыннан барып, мин шул урында балык тота башладым. Балык монда чиксез күп булмаса да, юк түгел иде, буш кул белән кайткан көннәр булмый иде. Беркөнне таң белән теге урыныма килсәм, ни күрим, минем урынымда Сәлим утырган да, берни булмаган кебек, рәхәтләнеп балык тотып ята.

Сәлимнең бу эше мине ачуландырды гына түгел, бөтен тамырларыма зәһәрле кайнар кан йөгерде. Бө-

тенләй чит бер кеше, минем урынымны алып, минем суымда минем балыкны тотсын әле! Сорамый-нитми кил дә кешенең суында, кешенең балыгын тотып ят, имеш! Юк, моны болай гына калдырырга ярамый. Моның өчен миңа Сәлимнең кабыргалары җавап бирергә тиеш дип, мин Сәлим янына килдем.

— Пычрак малай, хәзер минем урынымнан кит, эзең булмасын монда, мин синең өчен урын әзерләп куймадым, юкса кабыргаларыңны санармын! — дидем мин Сәлимгә. Ләкин минем ачу катыш әйткән кызу сүзләремә, гайрәт чәчүләремә Сәлимнең артык исе китмәде. Ул миңа салкын гына карады да:

— Китте ли. синең кебек куыкларны без күрмәгән түгел, күп күргән, китәсең килсә, әйдә, рәхим ит, болын бик киң, синең өчен моннан китәрлек кешеләр килмәгән! — дип җавап кайтармасынмы?

Мондый җаваптан соң тагын сөйләшерлек урын калмады. Бу җавап мине әче кычытканнан бигрәк үртәде. Мин озак уйлап-нитеп тормыйча, яшен ташы кебек атылып, Сәлимнең якасына ябыштым.

Сәлимнең көче минекеннән артыграк булса да, мин җитезлек белән алдырам. Шуңар күрә бер-беребезгә бирешмибез. Мин Сәлимнең кабыргаларын санаган кебек, ул да минем яңакларны кыздыра. Шулай итеп, без, бер-беребезгә бирешмичә, вакытыбызны сугыша-сугыша үткәреп, кояш баер алдыннан гына өйләребезгә кайтып киттек.

Икенче көнне мин алданрак барырга дип уйлап, иртәрәк чыгып китсәм дә, Сәлим анда иде инде. Бүген ул мине бөтенләйгә җиңәр өчен булса кирәк, үзе белән Җәләйне дә алып килгән. Ябык кына, көчсез генә Җәләйне күргәч, мин Сәлимне үртәргә тотындым:

— Ә, ялгыз килергә курыктыңмыни, шулай була

ул, тагын берничә малай алып килер идең,— дидем.

— Курыкмыйни, курыккан ди, мин аны алып килергә уйлаганым да юк.

Сәлим әйтәсе сүзләрен әйтеп бетермәде, мин, Җәләйне бер якка этеп, Сәлимгә ыргылдым.

Җәләй көчсез малай булса да, Сәлим өчен дә файдалы булып чыкты. Әле уң кулга асылынып, әле сул кулны тотып, әле беләктән кочаклап, миңа һаман комачаулап торды. Мин бар көчемне җыеп, аларны җиңәргә тырышсам да булмады. Дүрт кулга каршы ике кул көчсезрәк шул. Сәлим мине җиңде. Бу минутта мин Җәләйне кырыкка өзгәләп ташлардай идем. Рәтләп балык тотмыйча сугышып, арып-талып бүген дә өйгә буш кайтып киттек.

Ашап-эчкәннән соң, караңгы төшкәнче дип, мин урамга чыктым. Капка алдына чыккач та Җәләйне очраттым. Аңардан үч аласым килде. Ләкин аны кыйнау файдасыз. Ничек тә булса аны үз ягыма аударып, Сәлимнән үч алырга кирәк.

Җәләйгә әйттем:

— Үзең көчсез, үзең зәгыйфь, шулай да сугышка катнашып йөргән буласың. Алла сакласын, бая сугып тешеңне сындырган булсам, нишләр идең? — дидем.

— Катышмас идем дә бит, ул миңа шуның өчен карандаш бирде.

— Бик зур нәрсә биргән икән! Мин әле сиңа үземнең өр-яңа пеналымны бирмәкче булып тора идем,— дидем. Пенал сүзен ишеткәч, малайның колаклары шәм кебек торды.

— Син күптән шулай дигән булыр идең, синең пенал бирәсеңне белсәм, мин Сәлимгә әйләнеп тә карамас идем. Теләсәң иртәгә үк синең яклы булам! — диде Җәләй.

Мин шунда ук өйгә чабып кердем дә Җәләйгә пеналны чыгарып бирдем. Ул да сүзендә торды. Икенче көнне минем яклы булып, икәүләшеп Сәлимнең көлен күккә очырдык. Инде моннан соң Җәләй һәрвакыт минем яклы булыр. Сәлим белән икебез арасында сугыш бетәр дип торсам, ни күзем белән күрим?!

Өченче көнне әлеге Җәләй, Сәлимнән пәке алып, шуның өчен аның яклы булып, мине пыр туздырмасыннармы?! Инде нишләргә? Шулай Сәлимнән җиңелеп калыргамы? Үзеңдә Сәлимнән җиңелмәслек көч барлыгын сизә торып, сугышны туктатып, үз суыңнан, үз балыгыңнан колак кагаргамы? Моның гарьлегенә ничек түзәргә кирәк? Сугышның минем өчен күңелсез бетүен иртәгә бөтен дөнья беләчәк һәм көчлесе-көчсезе миннән көләчәк түгелме? Ничек булса да мин Сәлимне җиңәргә тиеш. Юкса минем горурлыгым тапталачак. Моның өчен Җәләйне ничек кенә булса да үз ягыма аудару чарасын табарга кирәк.

Монысы да бар бит әле аның. Мин Җәләйнең ярдәменә мохтаҗ булган кебек, Сәлим дә аның ярдәменә мохтаҗ бит. Шуңа күрә безнең алда бу көчсез, зәгыйфь малайның бәһасе көннән-көн күтәрелә бара иде. Бүген мин Җәләйне, аңа егерме тиен акча биреп, үз ягыма аударсам, икенче көнне Сәлим, ун алма биреп, аны үзенә карата иде.

Тора-бара моны Җәләй үзе дә сизеп алды, үзенең бәһасен көннән-көн күтәрергә тырыша башлады. Без ни өчен көн саен сугышабыз, кабыргаларыбызны санашабыз, хакыйкать кем ягында — Җәләйнең башына мондый сөальләр килми дә иде. Ул күбрәк бирүчене генә эзли иде. Бүген мин күбрәк бирсәм — минем яклы булып, Сәлимне кыйнаша. Иртәгә Сәлим күбрәк бирә икән — аның яклы булып, мине кыйнаша. Минем кебек Сәлим дә эченнән генә аны күрә алмас-

лык дәрәҗәдә дошманлык тота иде. Ләкин ни эшләмәк кирәк, «минем яклы бул», «минем яклы бул» дип, шул малайга икебез дә ялынып йөри идек шул. Болай аның артыннан чабып йөрүебез көннән-көн аның тәкәбберлеген генә арттыра иде. Тора-бара ул безнең белән киңәшеп тә тормый, әмер генә бирә башлады:

— Әй син, Сәлим, иртәгә биш алма китер!

— Әй син, Шәрифҗан, кайда, ун конфетыңны бир әле монда,— дип кенә кычкыра.

Сәлим дә, мин дә бу малайның әмеренә буйсына идек шул, юкса үзеңне җиңелгән итеп санарга курка идек.

Җәйнең матур көннәре акрын-акрын гына көзгә авыша башлады. Болындагы үләннәр чабылды, кырлар ялангач калды. Агачлардагы яфраклар саргаеп коела башлады. Көннәр салкынайды. Балыкка йөрү дә бетте, күңелсезләнде. Уку вакыты да якынайды. Бу җәйнең минем өчен шул кадәр мәгънәсез, шул хәтле ямьсез үтүенә эчем поша башлады. Җәй буе Сәлим белән дошманлашып йөрүемә дә үкенәм. Берդән, Сәлим белән дошманлаштым, икенчедән, җәем әрәм китте. Әтәч кебек сугышып йөрүдән миңа нинди файда килде дип, үзалдыма уйланам һәм үземнән хисап сорый башладым. Юк, мин Сәлим белән килешергә тиеш дип, кармакларымны алып, балыкка киттем. Мин барып җиткәндә, Сәлим инде анда иде. Кармакларымны Сәлимнекеннән югары салдым да үзем аның янына килдем. Сәлимнең йөзендә дә усаллык күренми иде. Күрәсең, ул да «килешсәк яхшырак булыр иде» дигән фикергә килгән. Мин аның янына бардым да: «Сәлим, әйдә килешәбез!» — дидем.

— Әйдә! — диде Сәлим. Без бер-беребезгә кул

бирештек. Без килешеп торганда, Җәләй дә килеп чыкты. Безнең килешүдән аның хәбәре юк иде әле. Ул бүген Сәлим яклы буласы булганга: «Әй, син, Сәлим, кайда алып килгән алмаларың? Китер аларны монда»,— дип кычкырды, Җәләй сүзен рәтләп әйтеп бетерергә дә өлгермәде, Сәлим аның уң кулыннан тотып алды, мин сул кулыннан тоттым.

Сәлим аның сул яңагына берне ялтыратты да: «Шәрифҗанга яхшы булып, мине кыйнашкан көннәрең өчен бу миннән сиңа чәйлек булсын!» — диде. Мин, аның уң яңагына ялтыратып: «Сәлимгә яхшы булып, мине кыйнашкан көннәрең өчен бусы инде минем чәйлек булсын!» — дидем. Без аңа башкача сукмадык, чөнки ул, «берәр чәйлекне» алгач та, бөтен гәүдәсе белән дерелди башлады. Ләкин аны, болай гына калдырмыйча, ант иттердек: «Моннан соң ике кешенең сугышканын күрсәм, бар көчемне биреп, аларны килештерергә тырышырмын. Үзем бер якка кушылып та сугышка катнашмам»,— дип әйттердек. Шуннан соң, барыбыз да дуслашып, өйләребезгә таралыштык.

1915

БУЛДЫКЛЫ ТАБИБ [1]

Төн караңгы. Урак кебек нечкә ай, күк итәгендәрәк күренеп алса да, бераздан соң бөтенләй югалды.

Бүтән көннәрдә булса, инде Разия бу вакытта күптән йоклаган булыр иде. Аны тугыз быргы белән уятыр хәл булмас иде. Һәркөн сәгать җидедә ята торган Разия, сәгать иртәнге җидене сукмыйча, җылы урыныннан торуның нәрсә икәнен дә белми иде.

Ә бүген йоклый алмый, эчең пошып торса, җаның тыныч булмаса, күңелең һаман да нәрсәдер көтеп торса — йоклап булмый икән шул!

---

[1] *Табиб* — врач.

Разия дә йокларга дип бик тырышып карады, берничә мәртәбә күзләрен дә йомып торды, йокыга киткән булып берничә мәртәбә борын тишекләреннән «хыррр-хыррр» итеп тавышлар да чыгарып карады — ләкин нишләмәк кирәк, йокыга китә алмый да мә сиңа.

Әлбәттә, Разиянең бу хәтле тырышып та йокыга китә алмавының сәбәбе юк түгел иде. Бу сәбәп бик зур иде.

Беләсегез киләме бу сәбәпне? Рәхим итегез. Разия белән безнең кешедән яшерерлек серләребез булганы юк әле.

Безнең Разия курчак көтә.

— Әбәү, моның өчен кеше шулай ук пошынамыни? Бигрәк инде! — димәкче буласызмы?

Шулайдыр шул! Сезнең кебек дүрт-биш курчаклары булган балалар өчен йоклый алмаслык булып пошынулар көлкедер шул. Ләкин Разиянең эше бөтенләй башка. Сәламәт булса, аңар менә иртәгә дүрт тулып бишенчегә китә. Ә аның бер курчагы да юк!

Курчак юк дип уйнамый торып булмый, әлбәттә. Разия дә һәркөн диярлек курчак уены уйный. Әнисенең шәлен ала да аны бер каты нәрсәгә чорный. Шул чорнаган нәрсә Разиянең курчагы була. Разия аның белән сөйләшә дә, аны үзенә кунакка да чакыра, кечкенә генә чынаягыннан аңа чәй дә эчерә. Әтисе алып кайткан кечкенә арбасына салып, өй эчендә тартып та йөри. Шулай да чорнап ясаган курчак чын курчак түгел инде. Ләкин нишләмәк кирәк? «Ит күрмәгәнгә үпкә-бавыр тансык», диләр картлар.

Ярый әле, Разиянең чорнап ясаган курчак белән уйнап утыруын беркөнне Зөләйха апасы күрде һәм «менә туган көнеңә котлап һәйбәт кенә курчак алып китерермен», дип вәгъдә бирде.

Иртәгә Разиянең туган көне. Димәк, Зөләйха апасы аңар курчак алып китерәчәк. Шундый шатлыклы көнне көткәндә, нинди җан тынычлыгы булсын, нинди күзләр йокыга йомылсын!

Сәгать инде сигезне сукты, Разия әле һаман йокыга китә алмый.

— Күзләре нинди булыр икән? Зәңгәр күзлене алса, шәп булыр иде. Аның инде күлмәге булыр, чәчләре дә булыр. Әй, алла, бу төн кайчанга чаклы сузылыр икән. Ичмасам, тизрәк әтәчләр кычкырсалар иде.

Шулай йоклый алмыйча, үзалдына сөйләнеп, озак азапланып ятканнан соң, ахыры йокы җиңде, Разия йокыга китте.

Иртә белән йокыдан торганда аның урыны янында үзеннән аз гына кечерәк, матур күзле, сары чәчле, чуар күлмәкле курчак белән кәгазьгә төргән бер тартма конфет ята иде.

Разия башта конфетны исенә дә алмады. Курчагын кочаклап бөтен дөньясын онытып бүлмә саен чабып йөрде. Курчагы белән мактаныр өчен абыйсы Сәлимнең мәктәптән кайтканын көтә башлады. Өйдәгеләрнең барысына да курчагын күрсәтеп чыкты. Аш өенә чыгып, асраулар алдында да мактанырга өлгерде. Көткән минут җитте дигән кебек, Сәлим дә мәктәптән кайтты.

— Абый, абый, җаным, кара моны! Күрәмсең, Зөләйха апа бүләк итеп китерде,— дип, Сәлим алдына килеп басты.

— Абау, һәйбәт лә инде курчагың,— дип, Сәлим сеңлесен туган көне белән котлап үбеп алды.

— Ә монысы нәрсә? — дип, конфет тартмасына күрсәтте.

— Монысы конфет, аны да Зөләйха апа китерде. Курчагыңны сыйларсың, ди Зөләйха апа.

Разия өчен иң кадерлесе курчак булса да, Сәлимнең күзе конфетка төште. Сеңлесенә курчак та, конфет та китереп, Сәлимгә бер нәрсә дә китермәгәне өчен, ул Зөләйха апасына бераз үпкәләп тә алды.

— Ичмасам, конфетны миңа китерү кирәк иде,— дип, ул үзалдына сөйләнеп куйды. Абыйсы өстенә карап торган Разия, аның әллә нинди яшерен уйлары барлыгын аңлаган кебек, кулына курчагын да, конфетын да алып, дәү әнисе янына чыгып китте. Дәү әнисе бүлмәсенә кергәч шаккатты. Яңакларын зур тастымал белән бәйләгән дәү әнисе бүлмәне күтәрердәй булып уфылдап утыра иде.

— Дәү әни, җаным, сиңа ни булды, нигә болай уфылданасың? Әллә бер-бер җиреӊ авыртамы? — дип, Разия дәү әнисеннән сорады.

— Уф алла, тешләрем, тешләрем! Бар әле моннан, нәнием, бар чык,— дип, дәү әнисе әрнешә-әрнешә Разияне яныннан чыгарып җибәрде. Разия әтисенең бүлмәсенә кереп, курчагы белән уйнарга тотынды. Аның янына Сәлим дә керде.

— Абый, дәү әнинең тешләре авырта икән. Башына, яңакларына җылы шәл чолгап утырган да офтана бирә, мин аны бик кызгандым,— диде Разия.

— Әйе шул, хәзер теш авыруы рәт кастасы[1] булып йөри ди. Ул теш авыруы бик начар нәрсә икән, күп кеше аңардан үлә дә икән. Әни әйтә: «Бик сакланырга кирәк», ди,— диде Сәлим.

Абыйсының сүзен тыңлап торганда, Разиянең курчагы, кинәт кенә кулыннан ычкынып, идәнгә төшеп китте. Разиянең башы ташка бәрелгән кебек булды. Ул тиз генә сикереп торды да идәннән курчагын күтәрде, күкрәгенә кысып үбә башлады.

---

[1] *Каста* — хаста (авыру).

Разиянең конфетын уртак итәр өчен Сәлим төрлечә уйлап караса да, бер ачык чара таба алганы юк иде әле. Курчак идәнгә төшкәч, аның башына кылт итеп бер уй килде.

— Абау, Разия, синең курчагың авырый икән! Эшең бик хәтәр икән, кара аның йөзе ничек агарып киткән, аны табибка күрсәтергә кирәк. Алла сакласын, үлеп китә калса, тагын курчаксыз калырсың,— диде Сәлим.

Сәлимнең бу сүзләре Разиянең котын алды, ул бөтенләй аптырап калды.

— Соң, нишләтергә кирәк? — дип абыйсына карады.

— Әлбәттә, аны табибка күрсәтергә кирәк, бүтән чара юк.

— Ул табибны кайдан алабыз, мин, авыру курчагымны ташлап, табиб артыннан бара алмыйм бит инде, абый, җаным, зинһар, үзең барып табибны алып килсәнә,— дип, ул Сәлимгә ялына башлады.

Хәзер табибны алып киләм дип, Сәлим чыгып китте. Абыйсы чыгып киткәч, Разия үзалдына сөйләнә башлады: «И, җаныем, сиңа ни булды икән, кай җирең авырта икән, дәү әни янына бая юкка кердем, аның теш авыртуы йоккандыр, мөгаен, тукта әле, бәбкәем, яңакларыңны бәйләп куйыйм, бәлки, авыруың тизрәк китәр»,— дип сөйләнә-сөйләнә, икенче бүлмәгә чыгып, чуар ситсы яулык алып килде дә курчагының яңакларын бәйләп куйды.

Берничә минут үткәч тә, чын табиблар кебек, салмак кына атлап, акрын гына ишекне ачып, бүлмәгә Сәлим килеп керде. Башына ул атасының эшләпәсен кигән, борын очына гына әнисенең күзлеген элгән, кулларына әнисенең ак катыргы җиңсәләрен кигән килеш килеп кергән Сәлимнең өстенә карарга көлке иде.

— Исәнмесез, абыстай, сездә авыру кеше булырга кирәк, аны күрергә мөмкинме? — диде Сәлим.

— Әйе шул, табиб әфәнде, минә курчагымның тешләре авыртып китте, рәхим итеп берәр ярдәм күрсәтә алмассызмы? — диде Разия.

Сәлим:

— Зарар юк, безнең бүтән эшебез дә юк бит. Шуңар күрә авыруларга ярдәм итүне көтеп кенә торабыз,— дип сөйләнә-сөйләнә, урындык алып, Разиянең каршына килеп утырды, кесәсеннән әтисенең сәгатен чыгарып карап куйды. Үзе шул арада, курчакның уң кулыннан җан тамырын табып, аның тибүен санарга кереште.

Сеңлесе, тын алырга да куркып, аңа карап утыра иде.

Бераздан соң табиб, башын чайкаган булып, бик тирән сулыш алды.

— Авыруның хәле шактый начар шул, аны хәзер тыныч кына тотарга кирәк, аңарга күп ашарга, күп эчәргә ярамый. Конфет дигән нәрсәләр аның янында булмаска тиеш, юкса алла сакласын, эшләрнең зурга китү ихтималы бар,— диде.

— Мәшәкатьләвем өчен гафу итегез, минә миннән шушы бүләкне генә алыгыз, ичмасам,— диде дә Разия һәм, үзе дә аңламастан, конфетны тартмасы белән Сәлимгә бирде.

— Йа алла, бер дә кирәкмәс иде, бүләксез дә ярар иде,— дисә дә, табиб бүләкне алды.

Конфеттан аерылу Разия өчен бер дә авыр булмады, ул курчагының сәламәтлеге өчен бер нәрсәсен дә кызганмас иде.

— Абау, бигрәк булдыклы табиб соң үзе,— дип, Разия курчагын да ул кушканча тынычлыкта калдырып, үз мендәренә генә яткырып, үзе абыйсы янына чыгып китте.

Тартманы ачып конфет белән бергәләп чәй эчәргә дип, Сәлим сеңлесен көтеп утыра иде.

1915

СӘМРУГ ҺӘМ МАЙ ҚОҢГЫЗЫ

Борын-борын заманда булган ди, тыныч кына торган ди дөньяда бер кечкенә генә Май коңгызы. Қайгылы көннәрендә кайгысын, шатлыклы көннәрендә шатлыгын уртаклашучы хатыны да булган ди. Болар әбиле-бабайлы бик шәп, бик тату торганнар.

Май коңгызының ире үзен-үзе иң зур, иң көчле батырлардан санаган ди.

Бөтен дөнья халкы миңа гына карап тора, ничек миннән курыкмасыннар, көчледән куркалар шул, мин батыр булганга миннән куркалар шул дип, карчыгы алдында һәрвакыт мактана торган булган ди. Бервакыт шулай мактанып торганда, һавада очып баручы кошны күргән ди.

Менә сиңа батыр, менә сиңа көчле! Сәмругны күрү белән ул «тыз-быз» килеп кычкырырга, канлы яшьләр түгеп еларга тотынмасынмы?!

— Қарчык, кайда син, харап булдым, Сәмруг минем түбә өстемнән генә оча, мине чукып алмакчы була! Қая, тизрәк китер балаларны, килегез тизрәк һәммәгез! Ичмасам, соңгы минутларымда сезнең белән күрешеп калыйм! Әй алла, харап булдык!..— дип, дөньяны яңгырата башлаган ди.

Май коңгызының бу кыйланышларын күргән, кычкыруларын тыңлап торган Қарга эче катканчы көлгән ди һәм Май коңгызына әйткән ди:

— Әй җүләр коңгыз, җүләр коңгыз! Сәмруг түгел, мин дә сине чукып торуны үзем өчен кимчелек са-

ныйм. Сәмруг түгел, чыпчык чукырлык та итең юк лабаса, дөнья күтәреп дулаган буласың шунда,— дип әйткән ди.

Май коңгызы, башын күтәреп, каргага караган да, оятыннан колак артларына кадәр кызарып, оясына кереп киткән ди.

1915

СУКЫР ИЛЬЯСНЫ БЕЗ ҺАМАН ДА КҮРӘ АЛМЫЙ ИДЕК

1

Без ярлы идек. Өстебезгә кияргә кием-салым булмаган кебек, тамак туярлык аш-су да булмый иде. Ярлы ата-анага ничек иттереп биш-алты баланы киендерергә, ничек иттереп аларның барысын да тукландырырга? Алар өчен бу эш, әлбәттә, авыр иде. Безнең ачлыкны күреп, өзгәләнеп беткән чүпрәкләргә төренеп йөрүләрне күреп, алар, әлбәттә, шатланмыйлар иде. Безне шулай йөртүләренә пошыналар, ярлылыкларыннан үзара зарланалар иде.

Нишләмәк кирәк? Булмаган байлыкны һавадан тотып алып булмый лабаса?!

Без балалар өчен тормыш шактый күңелсез булса да, шул ук ярлы тормышның күңелле ягы да юк түгел иде.

Без өмет белән тора идек.

Нинди өмет белән тора идегез, дип сорамакчы буласызмы? Азрак сабыр итегез. Безнең нинди өмет белән торганны белерсез!

Безнең алты балага бер әбиебез бар иде. Без аны тешсез әби дип йөртә идек. Аны болай атап йөрүебезнең сәбәбе дә юк түгел иде, чөнки аның

авызында бер-ике азу теше генә калган иде. Шуңа күрә дә ул сөйләшкәндә «р» белән «л» хәрефләрен әйтә алмый, бу хәрефләр урынына аңарда «и» хәрефе килеп чыга иде.

Әбиебезне шулай булса да без бик ярата идек. Әз генә буш вакыты булдымы, ул безне үзенең янына җыеп, төрле әкиятләр, хикәяләр сөйли. Ул безне үлемнән һәм үзе кебек тешсез калудан саклый иде. Без аны бигрәк тә шуның өчен ярата идек. Бала булсак та, үләсе дә, әбиебез шикелле тешсез каласы да килми иде шул! Ашаган-эчкән чакларда, ул бездән бер дә аерылмый, безнең белән бергә ашый, безнең белән бергә эчә иде.

Әти-әниләрдән калган сыек кына чәйне эчәргә тотындык исә, әбиебез хәзер безне үгетләргә тотына:

— Ай-һай, балалар, чәйне берәр чынаяктан артык эчә күрмәгез, юкса эчегез күбеп үләрсез,— ди торган иде. Без дә аның сүзләреннән чыкмый идек, берәр генә чынаяк эчә идек тә, чынаякларны чылтыратып каплап куя торган идек. Чөнки эчебез күбеп үлүдән бик курка идек. Ул безне шикәрне күп ашаудан да саклый иде. Без чәй янына килгәч, ул кесәсеннән борчак зурлыгында гына бер кисәк шикәрне чыгара да, шуны алтыга бүлеп, безне яңадан өйрәтергә керешә:

— Шикәрне күп итеп ашарга ярамый, юкса сез дә минем кебек тешсез калырсыз, балакайлар,— ди торган иде.

Шикәрне күп ашаганнан тешләре коелып беткән әбиебезне күреп, ничек иттереп аның сүзләрен тыңламассың? Кайвакытта шул кечкенә генә шикәрләребезне дә калдыра идек. Әбиебез, аларны җыеп, бер кәгазьгә төреп:

— Ай, акыллыларым, менә шулай, шикәрдән

сакланырга кирәк. Бу калганнары икенче чәегезгә ярар,— дип, кесәсенә салып куя һәм икенче чәй эчкәндә тагын бирә иде.

Аш ашаганда да әбиебез безнең белән бергә була иде. Көндезге аш вакытында без өйдә булмый идек. Кайберләребез күрше казларын сакларга, кайберләребез күрше атларын сакларга китә. Өйдә калырга туры килгәннәрнең дә берәүсе дә өйдә тормыйлар — йә уйнап йөриләр, йә көн буе су коенып, су буенда юып киптерә торган ашлыкларны саклап утыралар. Кичке ашка исә әбиебез барыбызны да җыя. Кичке аш дигәч тә, әллә нинди аерым пешерелгән аш дип уйламагыз, көндезге ашның калдыкларыннан башка монда бернәрсә дә булмый иде. Кояш баегач, караңгы төшкәч, без үзебезнең сөекле әбиебез белән өстәл тирәсенә тезелешеп утырабыз.

Әбиебез безгә кечкенә генә бер телем икмәк кисеп бирә, бармакларының очлары белән генә чеметеп алып, һәрберебезнең алдына тоз да куя.

— Бераз сабыр итегез, балакайлар. Хәзер бик һәйбәтләп кенә аш китерәм,— дип, үзе мич алдына китә.

Әбиебез агач табак төбенә генә салган бәрәңгене безнең алга китереп куйганчыга кадәр, без икмәкләребезгә кагылмый идек. Шуннан соң гына ябырылып ашарга тотына идек.

Бер-икешәр бәрәңгене ашап өлгерүгә, әбиебез безне тагын үгетләргә керешә:

— Балакайларым! Сез инде күп ашамагыз, беләсез бит, сезнең әле Сукыр Ильяска кунакка барасыгыз бар. Өйдә эчләрегезне тутырсагыз, анда рәтләп ашый алмассыз. Сукыр Ильяста бик тәмле ашлар була, бер капканда телеңне йотарлык буласың, тизрәк ятарга кирәк, юкса кичә дә артыграк ашаганга

күрә, авыраеп, каты йоклап киткәнсез. Сукыр Ильяс артыгыздан килгән иде, азапландык-азапландык, һаман да уята алмадык үзегезне. Сукыр Ильяс бик кайгырып китте, шулай да әле мин аны юатып җибәрдем, иртәгә, әлбәттә, йокламаслар, дидем. Йокласалар да, иртәрәк ятканга һәм азрак ашаганга күрә, уятуы җиңел булыр дидем.

— Әбием, җаным, Сукыр Ильяста шалкан булырмы? — дип сорады Әхмәт.

— Ә алма булырмы? — диде Сара.

— Чия дә булырмы? — дип өстәде Фәрит.

— Барысы да булыр аңарда, ул бик бай бит. Шалканын да, алмасын да, чиясен дә туйганчы ашарсыз, җаннарым,— диде әбиебез.

— Кишер булырмы? — диде Сәлман.

— Кишер дә булыр,— диде әбиебез.

— Калач та булырмы? — дип сорады Сәрби.

— Калач та булыр,— диде әбиебез.

— Алай булса, мин икмәкне артык ашамыйм, анда баргач, калач белән сөт ашармын! — диде Сәлман.

Бер кулына икмәк кисәге, бер кулына кечкенә генә бәрәңге тотып торган Сәрби боларны кире өстәлгә куйды да:

— Алай булса, мин бәрәңгене дә, икмәкне дә ашамыйм. Сукыр Ильяс бабайда калач, токмач, үрдәк ите ашармын,— диде ул.

— Мин дә артык ашамыйм, юкса калач белән балга урын да калмас,— диде Сәлман. Башкаларыбыз да ашаудан туктадык.

— Җә, балакайларым, алай булса, әйдәгез, кулларыгызны һәйбәтләп юыгыз да, тизрәк ятыгыз,— диде әбиебез. Без, гөж килеп, өстәл тирәсеннән торып, кулларыбызны юарга керештек. Биш-алты ми-

нуттан инде без, ындыр табагында тезелгән көлтәләр шикелле, идәнгә тезелешеп йокларга яткан идек. Әбиебез безгә якын гына сандык өстенә урын җәеп ятты.

— Ягез, балакайлар, тизрәк йокыга китәргә тырышыгыз, Сукыр Ильяс та озакламый килеп җитәр. Ул килер алдыннан гына йокыга китәр булсагыз, харап булырсыз, үзегезне тагын уятып та булмас, йоклагыз, бәбкәйләрем, йоклагыз! — диде әбиебез, үзе дә күзләрен йомды.

2

Өй эче бераз тын калды. Һәммәбез йокыга киткән төсле булдык. Бүтәннәрне белмим, ләкин үзем чын күңелдән тирән йокыга китәргә тырыша идем. Бәлагә каршы, мин ничаклы тырышсам да, йокы дигән нәрсә ичмасам якын да килми иде. Инде харап булам, бүтәннәр Сукыр Ильяска барырлар, тәмле ашлар белән сыйланырлар, ә мин, мин йоклап калачакмын. Бишмәтне дә баштан ук ябынып карадым, икенче якка да әйләндем. Булмаса булмый шул! Мин гөнәме шулай йокысыз азапланам! Әллә бүтәннәр дә йоклый алмыймы? Туктале, дәшеп карыйм әле?

— Фәрит, син йоклыйсыңмы? — дип, янымда яткан Фәритнең кабыргасына төрттем.

— Күрәсең бит, йоклыйм, нигә төрткәләнеп кешегә йокларга бирмисең?! — диде ул. Үзе тагын да көчлерәк мышный башлады. Сирәк-мирәк кенә борынын да сызгыртып ала. Фәритнең уяу булуы, йоклый алмавы мине бераз тынычландырды. Калсак, икәү бармый калабыз икән, дип уйладым мин, шулай да тизрәк йокыга китеп булмасмы дип, күзләремне тагын да ныграк йомдым. Шул арада пыш-пыш сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады. Мин күзләремне ачып

җибәрдем, сулышымны кысып тыңлый башладым. Сөйләшүчеләр Сара белән Сәрби иде.

— Сәрби, Сәрби, син йоклыйсыңмы? Мин йокыга китә алмыйм бит, җаным. Сукыр Ильяс бабай килгәндә йоклап китсәм, ничек булса да уят, җаным. Үзегез барып, мине генә калдырмагыз,— диде Сара.

— Син бик каты йоклыйсың бит, ничек итеп уянырсың икән? — ди Сәрби.

— Уят инде, яхшылыгыңны үзем дә онытмам, тавышка уянмасам, төрткәләп уят,— диде Сара.

— Яравын ярый да бит, мин әле үзем дә йоклый алмыйм.

Сәрби, Сара, Фәритләрнең йокыга китә алмаулары мине тәмам тынычландырды. Тик Әхмәт белән Сәлман гына мыш-мыш итеп яталар иде. Калсак, барыбыз да бергә калабыз икән, Ильяс бабай бер-икәүне генә алып китмәс. Шулай булса да, эчтә әллә нәрсә кыймылдый төсле. Бүтәннәрне алдар өчен мин гырылдап «йоклый» башладым. Берничә минут үтәргә өлгермәде, билем янында гына нәрсәдер кыймылдый башлады. Әллә күлмәк астына тычкан керде инде дип уйлаган идем, тычкан булмады. Инде күзләремне йомыйм дигәндә генә:

— Фу! Әбәү... Сәлман! Бу ниткән эшең бу? Борын төбенә генә! Шакшы,— ди Сәрби.

— Ай-яй! Билләһи чыдар гына хәл дә юк, кайсыгыз болай итә, фу, сасы,— дип Сара өстәде.

Сәлман үзенең гаебен белепме яки бүтән хәйлә беләнме, телсез калган кебек тик кенә ята иде.

— Кояштыр, чыдар хәлем юк, мин моннан икенче җиргә күчәм, юкса монда тончыгып бетәрсең,— дип, Сәрби урыныннан гына торган иде, Сәлманның теле ачылды:

— Ни пычагыма кешегә йокларга бирмисез, кем

күлмәгемнән тарта, җибәр, дим! Булмаса, икмәктер, авызыңа бирәм, җибәр, диләр! — дип кычкырына башлаган иде, тавышка әбиебез дә уянды.

— Нәрсә бүлешә алмыйсыз, нинди тавыш бу? Шулмы йоклавыгыз? — диде дә, ут кабызып, безнең янга килде. Һәммәбез дә тордык. Ни күзебез белән күрик?! Сара белән Сәлманның күлмәк итәкләре бәйләнгән. Әбиебез килеп тикшергәннән соң гына без хәлнең төбенә төшендек. Сәлман арабызда иң сак йоклаучы, Сәрби уйлаган-уйлаган да, Сукыр Ильяс килә калса, Сәлман уяначак, күлмәк итәкләребезне төенләп куйсак, ул торып кисәктән мине тартуга, мин дә уянып китәрмен дип, әлеге төенне эшләгән. Сара артыннан торып икенче җиргә күчим дигәндә, аның бу шаянлыгы хәтереннән чыккан булган.

Барыбыз да көлештек.

Тик арабызда Фәрит кенә бер күзен йомып, бер күзе ачык хәлендә моңаеп утыра иде. Көлүләр басылгач, яңадан ятабыз дигәндә генә, ул тирән итеп бер уфтанды да, үпкәләгән тавыш белән, Сәлманга таба әйләнеп:

— Булмады... бүген дә бара алмый калабыз, ахыры, менә генә татлы йокыга китәм дип тора идем, бар, йокла инде, барысына да, Сәлман, син гаепле, менә сиңа, чия белән калач аша инде,— диде дә үзе шап итеп кире урынына ятты.

Тик әбиебез генә тыныч иде. Ул безне тынычландырды да, утны сүндереп, үзе дә ятты:

— Әле вакыт бар, тизрәк йокыга китсәгез, уяна алырсыз, бер дә курыкмагыз,— диде ул безгә.

Фәрит белән Сәлманга шул гына кирәк булган, күрәсең, әбиебезнең сүзләреннән соң, алар сеңгән кебек йокыга киттеләр.

Сара белән Сәрби бездән аерым яттылар. Биш-ун

минут үтәргә өлгермәде, аларның да сулышы акрынайды, алар да татлы йокыга киткәннәрдер. Өй эче тәмам тынычланды. Барысы йокыга китте. Тик йокы дигән нәрсә мине генә ташлаган, күрәсең, мин йокыга китүдән бөтенләй өметемне өздем. Пошынуым мине бер эссегә, бер салкынга ташлый иде.

Шул арада әллә кайда бер чикерткә чырылдап җибәрде. Аның тавышы, миңа бик моңлы, бик мәхәббәтле булып, минем ялгызлыгымны бетергән кебек тоелды.

Мин генә түгел икән, йоклый алмый торган җаннар бар икән әле, дидем мин үз-үземә. Артык пошынып яткангадыр инде, өй эче дә бөркү була башлады. Һава тыгызланды кебек, өстемә ябынып яткан бишмәтемне дә ачып җибәрдем. Бераз җиңелрәк булып китте. Шул арада кемнеңдер иңбашыма төрткәнен сиздем. Әхмәт икән.

— Кәрим, Кәрим,— ди ул.

— Нәрсә? — дидем мин.

— Әйдә, тышка чыгып көтәбез.

— Кемне көтәбез?

— Сукыр Ильяс бабайны, юкса мине йокы баса башлады. Каты йокыга китәрмен дип куркам,— ди Әхмәт. Аның Сукыр Ильяс бабайны тышка чыгып көтик дигән фикере миңа да ошады.

— Әйдә, шулай итик,— дидем дә урынымнан тора башладым. Ләкин кемдер мине күлмәгемнән тарта, торып китәргә ирек бирми, капшап карасам, минем белән Фәритнең күлмәге бәйләнгән булып чыкты. Ах, кызык. Кай арада бәйләп өлгергән! Әйтәм аны Сәя оил тирәсендә нидер кыймылдаган кебек иде. Чишеп маташканда, Фәрит, уянып китеп, минем кулгаябышты: «Килеп тә җиттеме әллә?» — диде ул.

— Юк,— дидем мин.

— Сез кая барасыз соң? — дип сорады Фәрит.

— Аны көтәргә тышка чыгабыз,— дидем.

— Алай булса, мин дә синең белән киттем,— диде ул һәм, сикереп торып, безгә кушылды. Без тышка чыгуга, Сәлман, Сәрби, Саралар да безнең арттан килеп җиттеләр. Безнең пышылдашуга Сәлман уянган да тиз генә Сәрби белән Сараны да уяткан икән...

3

Безнең өй каршында әллә кайчаннан бирле ята торган бер имән бүрәнәсе бар. Кышын ул кар астында калган була. Язын, кар эрегәч тә, ул үз урынында кала бирә. Җәй көннәрендә күрше картлар һәм әбиләр, аның өстенә утырып, үзләренең үткән заманнарын сагынып сөйләшеп утыралар. Ул инде шомарып беткән. Өйдән чыгып, без дә шул бүрәнә өстенә утырыштык. Бик күптәннән салынганга күрә өебез азрак алга таба иелгән. Аның түбәсе дәртле карт бабайның яшәрергә тырышып кыңгыррак салып кигән бүрегенә охшый төшә. Бүрәнә аралары салам катыш сары балчык белән сыланган, үзенең ике кечкенә генә күзле тәрәзәләре белән алдыбызда җәелеп яткан болынга карый иде.

Текел, текел, текел итеп шакылдатып, акрын гына атлап, авыл сакчысы йөри. Авылның икенче очында бер-ике генә кат ялкау гына өреп алган эт тавышлары ишетелә. Тик шулар гына төннең тынлыгын боза иде.

Төн матур... Зәңгәр күктә бер генә болыт кисәге дә күренми, уртада дулкынланып, нурын түгеп торган тулы ай, аның тирә-юнендә җемелдәп торган йолдызлар тәртипсез рәвештә күк битенә сибелгәннәр. Тик әллә кайда бер сызылып очкан, адашкан

йолдыз гына бу матурлыкны беразга бозган кебек була. Ләкин ул да бер-ике секундтан соң ук күздән югала.

— Их, шул йолдызның койрыгына ябышып очсаң иде!.. Кайда алып барып төшерер икән? — диде Сәрби.

— Кайда төшерсен, Каф тавы[1] артына төшерер иде,— диде Әхмәт.

— Төшермәгән кайда. Төшерде ди Каф тавы артына, ничек анда менәргә кирәк, Каф тавы күктән биегрәк,— дип сүзгә кушылды Сәлман.

— Җүләр, күктән дә биегрәк нәрсә дөньяда буламы? — диде Әхмәт.

— Була шул, Каф тавы күктән биегрәк шул,— дип Сәлман җавап кайтарды.

— Ниткән сүз бу, Каф тавы күктән биегрәк булсын, имеш. Күктән биегрәк булса, кайда ул синең Каф тавың? Нигә күренми? Җә, нигә күренми? — диде Сәрби.

— Күктән ай белән йолдызлар ничек җиргә өзелеп төшмиләр? — дип, Сара сүзне икенчегә борды.

— Әйтте сүз, соң, җүләр, алар күккә тагылып куелганнар ич, шулай булгач, ничек өзелеп төшсеннәр. Безнең өйдәге тагылып куелган лампа төшми ич,— диде Әхмәт.

— Йолдызлар башка, лампа башка, лампаны әни тагып куйган, ә йолдызларны кем таккан?

— Кем таксын? Аларны борынгылар такканнар,— диде Әхмәт.

— Ничек аларның буйлары җиткән шундый биеккә? — диде Сара.

— Борынгылар буйга озын булганнар, аларның

---

[1] *Каф тавы* — Кавказ тавы.

буйлары гына ике мең аршын[1] озынлыгында булган,— диде Әхмәт.

— Соң, ничек алар такканнар? — дип, Сара һаман Әхмәткә бәйләнә бирде.

— Әүвәл йолдызларны, айны капчыкларга төяп, Қаф тавына менгәннәр, шуннан соң күк буена тагып йөргәннәр.

— Қайдан шулкадәр күп йолдызларны тапканнар икән? — дип сорады Сәрби.

— Менә тагын, әйтте сүз! Иске айлар кайда китә дип беләсең. Иске айларны кискәләгәннәр дә йолдызлар ясаганнар,— диде Сәлман.

— Алайса, аны кискәләгән чакта ничек куллары пешмәгән икән? — дип, Сара сүзгә тыгылды. Сәлман җиңелде. Сараның соңгы сүзләренә җавап таба алмады.

Безнең акрын гына сөйләшкәнне ишетеп булса кирәк, яныбызга авыл сакчысы Исмәгыйль карт килеп туктады.

— Нишләп монда торасыз, балалар? Төн уртасында йокларга кирәк, халык барысы да йоклый, ә сез йокламыйсыз,— диде бабай.

— Йоклыйсы килми, өйдә бөркү, төн матур, шуңа күрә чыктык та утырдык,— дидем мин.

Моңа чаклы бер дә сүзгә кушылмаган Фәрит, кисәктән Исмәгыйль картка борылып:

— Бабай, әнә күктәге айны һәм йолдызларны күккә кемнәр кадаклап куйганнар икән? — диде. Фәритнең бу соравы бабайны бераз аптырашта калдырды булса кирәк, ул тиз үк җавап бирмәде.

— Қем кадакласын, аларны алла шулай яраткан,— диде ул бераздан соң һәм шакылдавыгын шакылдатып китеп барды.

---

[1] *Аршын* —71 сантиметрга тигез озынлык берәмлеге.

Чү, бу нинди тавыш, әллә кайдан, еракта моңлы гына кыңгырау тавышы ишетелә башлады. Һәммәбез кыңгырау тавышы ишетелә торган якка борылып тыңлый башладык. Телләребез бәйләнгән кебек булды. Минем йөрәк урынымнан чыгардай булып тибә иде. Кыңгырау тавышлары әле якынлаша, әле ераклаша, өзелеп калган кебек тә була.

Сәрби калтырана башлады. Мин әбиемне уятам дип, Сара чабып китмәкче иде, ләкин Әхмәт аны туктатты. Тукта әле, кая ашыгасың, килеп җиткәч тә уятырга өлгерербез. Сара Әхмәтнең сүзенә карышмады. Шул арада без, үзебез дә сизмәстән, тәмам бер кешедәй булып тыгызланыштык, кул-кулга тотыштык. Кыңгырау тавышлары якынайганнан-якыная иде.

— Мин ат аяклары тавышын да ишеттем,— диде колакка сак Сәлман,— теге оч тавыннан күтәреләләр инде...

— Мин дә ишетәм,— диде Фәрит.— Өч ат җигелгәнгә охшый.

— Ике генә ат җигелгән, тыңла яхшылап кына, берсе дөп-дөп итеп сикереп килә, берсе юырта,— диде Сәлман.

— Мин куркам,— диде Сара.— Мин барып әбиемне уятам.

— Җүләр, нидән куркасың, ул пәри түгел ләбаса,— дип, аны Әхмәт юатырга тырышты.

— Мин сөйләшкән тавышларын да ишетәм,— диде Сәлман,— икәү киләләр булырга кирәк.

— Кучеры белән сөйләшә торгандыр, бәлки безнең өйне таба алмый торганнардыр,— диде Фәрит.

— Нигә безнең өйне таный алмасыннар. Ничә мәртәбә ич безгә килгәннәре бар?! — диде Әхмәт.

— Кәрим, мин синең янда барырмын, яме,— диде миңа Сәрби.

— Ә мин кучерга утырырмын,— диде Сәлман.

— Мин дә кучерга утырырмын,— диде Фәрит.

— Мин әбием янына утырырмын,— диде Сара.

— Мин Сукыр Ильяс бабайның итәгенә утырырмын! — диде Әхмәт.

— Тукта әле, мин бишмәтемне киеп чыгыйм, юкса бабай күчтәнәчләр бирсә, куяр җирем дә юк,— диде дә Фәрит өйгә кереп китте.

— Мин дә, ичмасам, баш яулыгымны алыйм,— диде Сара.

— Фәритнең әйткәне дөрес, бишмәтләрне кияргә кирәк шул,— диделәр дә Әхмәт белән Сәлман да чабып өйгә кереп киттеләр. Сәрби белән икәү генә урамда калдык. Сәрби миннән аерылырга курыктымы, әллә бабай биргән күчтәнәчләрне итәгенә салып алып кайтырмын диепме, урыныннан кузгалмады. Мин инде озакласалар кычкырырмын дигән фикер белән өйгә кермәдем. Күчтәнәчләрне ыштан кесәмә генә тутырып алып кайтырмын дип уйладым.

Кыңгырау тавышы тәмам якынлашты, ат аякларының тыкылдау тавышларын инде мин дә ачыктан-ачык ишетә башладым.

— Кәрим, бабай усал түгелдер бит, ә? — диде Сәрби.

— Нигә усал булсын, усал булса, безне кунакка алырга килмәс иде,— дидем мин, Сәрбине юатыр өчен. Ләкин эчемнән генә үзем бераз курка идем. Сәрби исә бөтенләй яфрак кебек калтырый иде бичаракаем.

— Ул моннан ерак тора микән? — диде Сәрби.

— Кайдан беләсең, бәлки ерактыр, бәлки якындыр, мин белмим.

— Ә ул безне Каф тавы артына алып китсә, нишләрбез? — диде тагын Сәрби.

— Алай итмәстер, әбием әйтә, ул бик яхшы карт, ди, безнең кебек балаларны бик ярата, ди.

Соңгы сүзләремне әйтеп бетергәндә, Әхмәтләр дә киенеп чыктылар.

— Җиттеләр, җиттеләр,— диде Сәлман.

— Ай-һай! Атлары шәп тә соң! Канатлары бармыни, әйтерсең очалар! — диде Әхмәт һәм үзе, шатлыгына чыдый алмый, сикергәләнә башлады. Сәлман, Фәрит, Саралар да аның артыннан кул чабарга тотындылар.

Сәрби белән мин генә телсез кебек дәшми генә тора идек.

Шул арада атларына «фию» дип сызгырып, пар атта берсе — түргә, берсе кучерга утырган ике кеше — волостной[1] белән кучер узып та киттеләр. Артларыннан күтәрелгән тузан эчендә күздән дә югалдылар. Безне яшен суккан кебек булды. Авызларыбызны ачып, тузанга байтак карап тордык та, өметләребезне өзмичә, кире бүрәнә өстенә барып утырыштык. Тагын Сукыр Ильяс бабайны көтә башладык.

Иртә белән без уянганда нурланып кояш калкып килә иде инде.

1915

КУЯННАР

— Тор, тор, угылым, йокының очы булмый ул,— ди дәү әти. Җылы урыннан торасы килми шул! Бераз киерелгән буласың, сузылган буласың, тагын күзләреңне йомасың. Ләкин берничә минут үтүгә, тагын дәү әти килә:

---

[1] *Волость* — патша Россиясендә район урынында йөргән.

— Әй, балакай, балакай, каты йоклыйсың да үзең, без яшь чакта бер эндәшүгә чаткы кебек атылып тора идек, эшкә кичегәбез ич! — ди.

Артык назланып торып булмый инде, дәү әти ачулана башлый. Торам, киенәм, бу вакыт инде тырмалар әзерләнгән, атлар җигелгән була. Уҗым кырын тырмаларга барабыз.

Салкынча гына таң җиле биткә бәрә. Кояш әле яңа калкырга гына әзерләнә. Күк йөзен куе кызыллык каплаган. Үлән яфракларындагы чык тамчылары хәзер тәгәрәп төшәргә тора.

Анда-санда гына булса да тырмачылар күренә. Алар янына җиткәч дәү әти:

— Эшләр уңсын, күрше! — дип кычкыра.

— Рәхмәт, алла ярлыкасын! — диләр аңар каршы.

Менә без дә үз җиребез өстенә килеп җиттек. Тырмаларны рәтләдек. Менә хәзер кузгалып китәбез дигәндә генә, дәү әти:

— Тсс, — дип, миңа кузгалмаска куша. Шул арада үзе бармак белән межага[1] күрсәтә. Ни күзем белән күрим: межада безгә таба алды белән куян яткан, колаклары белән уйный, әле берсен, әле икенчесен торгыза. Мин гомеремдә беренче мәртәбә куян күрәм.

Ул соры төстә, үзе зур түгел. Мин сулышымны алмый аңа таба карап торам. Дәү әти акрын гына межа буйлап аңа таба китә. Куянның күзләре алдан килгәнне күрми. Аның күзләре ике якка карый.

Дәү әти акрын гына барып аны тотмакчы була. Ул инде аның янына ук җитә. Тагын бер-ике атласа, куян кулга керәчәк. Шул арада күрше җиреннән:

— На, рәхмәт яугыры! — дип, берәү атына кычкы-

[1] *Межа* — ызан.

ра. Куянны инә белән чәнечкән кебек булалар. Ул тиз генә сикереп тора, як-ягына карангалый да яшен ташы кебек чабып китә. Минем йөрәк өзелеп төшкән кебек була. Күршегә ачуым килә.

— Каһәр суккыры! — дим мин аңар авыз эченнән генә.

— Әй, булмаган, малны кулдан ычкындырды бит! — дип, дәү әти дә мыгырдана.

Шул арада кайдан күреп алган койрыксыз Акбай, әй чаба, әй чаба! Куянны куа, имеш. Бичара үзе чиный, өрә, ләкин кая ул җитү!

Дәү әти бар шул, юкса үзем дә Акбай белән бергә чабып киткән булыр идем!

— Бу алай ук кызык түгел,— дип, дустым Әхмәт минем сүземне бүлә.

— Менә без үткән ел калага барганда Сураж авылы ындыры янында атларыбызны эчәргә туктаттык. Шулай ук таң алды иде. Мин йоклар-йокламас кына тарантаста тезләнеп утырып торам.

Хәлил абзый әйтә:

— Исмәгыйль, күрәсеңме бу хайваннарны, куенына куеп алып китәрлек бит, ә! — ди.

— Нәрсә күрим мин? — дим.

— Уңга борылып кара,— ди ул. Мин карыйм. Исләрем дә китә, йөрәгем тибә, мин кычкырып җибәрәм.

— Куяннар! — дим. Алар ап-ак, кечкенә генәләр, дүртәү йөриләр. Минем кычкыру аларны кузгатмады. Колакларын торгызып, бераз караштыргаладылар да, алгы аяклары арасына кыстырып, нәрсәдер кимерә башладылар.

— Куяннар түгел,— ди Хәлил абзый,— аларның балалары гына, олы куяннар булса күптән сызган булырлар иде,— ди.

— Хәлил абзый, җаным, тотыйк,— дим.

— Тотып кара,— ди Хәлил абзый. Мин тиз генә тарантастан сикереп төшәм, чабып бара башлыйм. Яннарына гына җитәм дигәндә, алар миннән качып китәләр, бераз киткәч тә, мине мыскыллаган кебек, тагын туктыйлар. Мин тагын аларга таба барам. Алар ап-ак, кыска гына койрыклары мамык кебек күпереп тора. Алгы аяклары кып-кыска.

Алар мине алдый-алдый әллә кая хәтле алып киткән булырлар иде, ләкин бу вакытта атларны эчереп бетергән Хәлил абзый:

— Әйдә, Исмәгыйль, күрәсең, аларны тота алмассың. Юлда куян куып йөрергә безнең вакытыбыз юк,— ди.

Аның сүзләре йөрәгемне умырган кебек була. Нишләмәк кирәк? Утырып китәбез. Мин куян балалары киткән яктан күземне алмыйча һаман карап барам.

Каладан кайтканда да, шул турыга җиткәч, әлеге куян балаларын эзлим, ләкин аларны күрә алмыйм.

1915

КЫЗ-ПАТША

(Кыргыз әкияте. Әбүбәкер Диваевтан) [1]

Борын заманда Солтан Хөсәен исемле бер бик зур патша булган ди. Аның олы вәзирен Миргалишир дип йөрткәннәр. Бердәнбер көнне Солтан Хөсәен патша ауга чыккан. Күп җирләрдә йөри торгач, ул Кыз-патшаның искиткеч матур бакчасына килеп чык-

---

[1] *Әбүбәер Диваев* — кыргыз, казакъ, үзбәк халык авыз иҗатын җыючы күренекле галим.

кан. Шул вакыт Кыз-патша үзенең бакчасында йөри икән. Солтан Хөсәен аны күрү белән гашыйк булган.

Бер көн уздырмыйча, бу кыз-падишаһны үзенә хатынлыкка сорап, яучы җибәргән. Солтанның яучысына Кыз-патша болай дигән: «Падишаһыңа бер сөаль бирәсем бар. Шул сөальнең җавабын таба алса гына мин аңа хатынлыкка барырга риза булырмын. Сөальләрнең җавабын таба алмый икән, мин аның хатыны булачак түгел. Падишаһка бирәчәк сөаль шул: минем бер симерткән бәрәнем бар, шул бәрәннең ите күбрәкме яки мае күбрәкме?» — дигән.

Яучы алып кайткан бу сорауга Солтан Хөсәен нихәтле баш ватса да, җавап таба алмады.

Солтан, Кыз-падишаһка илче җибәреп: «Сөальнең җавабын таба алмадым, инде аның җавабын таба алырлык кеше эзләргә рөхсәт бирсә иде!» — дип әйттергән.

Кыз-патша моңар риза булган.

Солтан Хөсәен үзенең мәмләкәтендәге иң атаклы галимнәрне җыйган да әйткән: «Минем бик симерткән бер бәрәнем бар, шул симез бәрәнемнең йоны күбрәкме яки мае күбрәкме?» — дигән. Падишаһның сөаленә берәү дә җавап бирә алмаган, шуннан соң Солтан Хөсәен, яңадан әмер биреп:

— Күрәм, минем мәмләкәтемдә бер дә гакыллы адәм юк икән. Шуның өчен мәмләкәттәге иң начар кешеләрдән, иң начар үсемлекләрдән һәм иң начар кошлардан берәрне алып килегез! — дигән.

Падишаһның кушканын үтәр өчен төрле якка илчеләр таралган.

Илчеләр көне буе йөргәч, иң начар үсемлек дип күс кубнасны, иң начар кош санап, байгышны[1] алып

---

[1] *Байгыш* — ябалак.

кайтырга булганнар. Ләкин начар адәмне табуда шактый кыенлыкка очраганнар. Эзләнә торгач, алар бер туйга килеп чыкканнар. Туйда халык күп икән. Монда яхшы тун кигән кешеләр булган кебек, ачялангачлар да юк түгел иде. Шул халык арасында бигрәк тә күзгә чалынып торганы Қара кол бар иде. Аның колаклары да юк иде, аяклары да зәгыйфь иде, күрер күзгә дә начар, ябык иде. «Мәмләкәттә очратырга мөмкин булган иң начар кеше шул булыр инде»,— дип, илчеләр аны патша катына алып киттеләр. Бу кол үзенең хәленнән хәбәрсез иде, патша илчеләре үзен кайда алып китүләре турында ул белми иде. Менә бервакыт үзен алып баручылардан: «Мине кайда вә ни өчен алып барасыз?» — дип сорады.

Илчеләр аны ни өчен алып барганнарын һәм патша аңар нинди сөаль бирәчәген барын да сөйләп бирделәр. Эшнең төбен белгәч, Қара кол илчеләргә болай диде: «Үсемлекләрнең начары күс кубнас түгел, начар үсемлек дип иблек санала, чөнки ул янганда ут та чыкмый, янып беткәч, аның күмере дә калмый. Қошлардан иң начары — саескан, чөнки Идрис пәйгамбәрнең кяферләрдән качкан урынын эзләүчеләргә саескан күрсәткән, шунда Идрис пәйгамбәрне кяферләр тотып үтергәннәр.

Инде кешеләрдән иң начарын табасыгыз килә икән, аны да әйтеп китим, иң начар кеше дип яшь кияү санала[1]. Қешеләрнең начары, сез уйлаганча, мин түгел, шуңа күрә мине патша катына алып баруыгыздан файда чыкмас. Мин аңар бер нәрсә дә әйтә алмам, чөнки мин хуҗам тарафыннан мең акчага сатып алынган бер ирексез колмын.

---

[1] Қыргызларча: *яшь кияү* бик сүз йөртүчән икән, ди. Шуңа күрә һәр яшь гаиләдә тавыш чыгуга яшь кияү сәбәпче була икән, ди. *(Ф. Агиев.)*

Инде падишагыз үзенең сөале хакында минем фикеремне беләсе килә икән, сез аңар әйтегез, ул мине хуҗамнан сатып алсын».

Илчеләр кайтып, патшага Кара колның сүзләрен әйттеләр. Патша ул колны мең акча түләп хуҗасыннан сатып алырга әмер бирде. Илчеләр патшаның әмерен җиренә җиткерделәр. Колны, мең акчага сатып алып, патша хозурына китерделәр. Патша Кара колга әйтте:

— Минем бик симерткән бер бәрәнем бар. Менә шул бәрәннең йоны күбрәкме яки маемы? — диде.

— Сезнең бу сөалегезгә мин Кыз-патша сараенда гына җавап бирә алам,— диде Кара кол.

— Ярый, берни итәр хәл юк, Кыз-патша сараена үземә барырга туры килә, күрәсең,— диде Солтан Хөсәен.

Солтан Хөсәен, аның олуг вәзире һәм Кара кол бергә Кыз-патшаның сараена киттеләр.

Кыз-патша боларның өчесен дә аерым бүлмәләргә куйды да башта Солтан Хөсәеннән:

— Минем бик симерткән бер бәрәнем бар, менә шул бәрәннең мае күбрәкме яки ите күбрәкме? — дип сорады.

— Симез бәрәнегезнең ите күбрәк,— диде Солтан Хөсәен, Кыз-патша, аны үз бүлмәсенә озатып, олуг вәзирне чакырып алды һәм шул ук сорауны аңа бирде. Олуг вәзир дә падишаһ җавабын әйтте.

Кыз-патша, олуг вәзирне үз бүлмәсенә озатканнан соң, Кара колны чакырды.

— Минем бик симез бер бәрәнем бар, менә шул бәрәннең мае күбрәкме яки итеме? — диде Кыз-патша Кара колга.

— Сезнең бәрәнегезнең, әлбәттә, мае күбрәк, олуг ханым! — диде Кара кол.

— Ни өчен бәрәнемнең мае күбрәк дип уйлыйсыз?

— Олуг ханым, минем болай җавап кайтаруыма бер дә гаҗәпләнмәгез, чөнки сөйли торган ул бәрәнегезне мин сез үзегез дип беләм, сезнең яхшылыгыгыз турында бөтен дөнья сөйли. Бәрәнегезнең мае да шул яхшылык, шул шәфкать һәм мәрхәмәтләрегез булса кирәк.

Кара колның әлеге җавабыннан соң, Кыз-патша бүлмәсеннән чыгып китте, бераздан соң ул, көмеш подноска куеп, бер карбыз белән пычак алып килде. Боларны ул Кара кол каршындагы өстәлгә куеп чыгып китте. Кара кол карбыз белән пычакка бераз карап торды да, пычакны алып, карбызга кадап ул да сарайдан чыгып китте.

Урамда Солтан Хөсәен белән вәзир Кара колны көтеп торалар иде. Кара колны күрү белән, сырып алдылар. «Кыз-патшага нинди җавап бирдегез?» — дип сораша башладылар.

— Мин бернәрсә дә белмим, шуңа күрә Кыз-патшаның сөаленә җавап бирә алмадым,— диде Кара кол.

Кара колның сүзләренә патша ышанмады. Ул миңа дөресен сөйләми, Кыз-патшага биргән җавабын миннән яшерә, шуның өчен ул җәзаланырга тиеш, дип, олуг вәзиргә әмер бирде.

Каты җәзага хөкем кылынса да, Кара кол Кыз-патшага әйткән серен Солтан Хөсәенгә ачмаска булды. Кара колны зиндан алдына китереп асарга булдылар. Шул вакыт зиндан алдында Кыз-патша күренде. Аның кулында пычагы кадалган карбыз иде. Кыз-патша Кара кол янына килде дә карбызны икегә кисте һәм, бер сүз дә әйтмичә, үзенең матур атына атланып кайтып китте. Кара кол кызның ишарәсен

аңлады: «Хәзер падишаһка дөресен сөйләп бирергә мөмкин!» — диде ул һәм үзен Солтан Хөсәен катына илтергә кушты.

Аны патша янына китерделәр.

— Олуг падишаһым! Кыз-патша тарафыннан бирелгән өч сөальгә дә мин болай җавап бирдем: симез бәрән дигән нәрсәсен мин аның үзе дип атадым. Бәрәннең мае — аның кылган яхшылыклары. Бәрәннең ите — аның начарлыклары, усаллыклары. Кыз-падишаһның кылган яхшылыклары усаллыкларына караганда артыграк булганга, әлеге бәрәннең итенә караганда мае күбрәк, дидем.

Беренче соравына җавап биргәч, ул минем каршыма карбыз белән пычак китереп куйды, үзе чыгып китте һәм яңадан кайтып кермәде. Мин аның үз алдында ук шул карбызга пычак кадап куйдым. Бу минем Кыз-патшага: менә шул пычак белән суйсалар да, берәүгә дә серне ачачак түгелмен, дигән сүзем иде.

Мине җәзага хөкем иттеләр, асарга алып килделәр. Асар минутлар җиткәч, ул, һәйбәт атка атланып, минем янга килде, күз алдында әлеге карбызны урталай кисте. Моның белән ул минем авызымны ачты, миңа серне сөйләргә рөхсәт бирде.

Мин дә менә сезгә бар нәрсәне сөйләп бирдем. Йа, падишаһым, ул бер генә минутка кичексә, мин харап булачак идем, — дип сүзеннән туктады.

Солтан Хөсәен Кыз-патшаның сөаленә үзе җавап таба алмаса да, җавап бирерлек кешене тапканы өчен Кыз-патша аңа кияүгә чыкты. Кара колның гакыллы җавабы аркасында матур гына туй да булып үтте.

1915

БЕРЛЕКТӘ — ТЕРЕКЛЕК

Дөньядагы хайваннар һәрвакыт адәмнән зарланалар, һәрвакыт адәмне дошман күреп килгәннәр. Бу дошманлык соңгы заманнарда гына булган дошманлык түгел, бу дөнья яратылганнан бирле шулай килгән.

Борын-борын заманнарда бу дошманнарыннан котылу өчен хайваннар үзара киңәш мәҗлесе корганнар. Бу мәҗлескә җир хайваннары гына түгел, ике аяклы канатлы кошлар да җыелган. Бер яланга Арыслан, Төлке, Дөя, Бүре һәм Ала карга, бергә җыелып, киңәшә башлаганнар. Иң көчле, иң гайрәтле, иң батыр хайван Арыслан булганга, аны мәҗлес башлыгы итеп сайлаганнар. Һәрберсе үзе башлык булырга теләсә дә, гаять көчле Арысланнан кем алга чыга ала, аңа буйсынырга туры килгән. Башкалар аны сүзсез генә тыңлап торганнар. Арыслан исә сүзгә керешкән:

— Сез мине мәҗлес башлыгы итеп сайладыгыз. Моның өчен рәхмәт. Хәзер бүгенге җыеныбыз хакында берничә сүз әйтеп китим. Соңыннан, әгәр теләгегез булса, тәртип белән генә үз фикерегезне, үз уйларыгызны әйтерсез.

Безнең бик начар, бик хәйләкәр дошманыбыз барлыгын сез һәммәгез дә беләсез инде. Бу дошманыбызны без адәм дип йөртәбез. Ул зирәк, ул гакыллы, арада нинди көчле иптәшләребез булса да, бу дошманга каршы ялгыз бернәрсә дә эшли алмаячагын без аңларга тиеш. Нинди генә көчсез, нинди генә зәгыйфь адәм булса да, үзенең зирәклеге, хәйләкәрлеге аркасында безнең иң көчле, иң гайрәтле булганыбызны да җиңәчәгенә шөбһә итәргә ярамый. Бу көчле дошман белән көрәшү өчен бер генә юл

бар: ул безнең тупланудыр. Әгәр дә төрле җенестәге хайваннар, кошлар, кортлар бергә туплансак, бер-беребез белән дус торсак, бер-беребезне җәберләмәсәк һәм бүтәннәрне дә җәберләмәсәк — менә шул вакытта гына без дөньяда рәхәт яши алырбыз. Шул вакытта гына дөньяда иң көчле дошманыбыз булган кешегә каршы тора алырбыз,— дигән.

Арыслан туктагач та, мәҗлестәге хайваннар тиз генә сүз алырга ашыкмадылар, һәммәсе берничә минутка сүзсез калды. Бу хәлне күреп, Арыслан, Дөягә карап:

— Йә, арабыздагы иң зур хайван, син бу хакта ни уйлыйсың? — диде.

Дөя башта читкә карап берничә мәртәбә төчкерде, аннан сүзгә кереште:

— Әйе шул, гайрәтле Арысланның сүзләре бик дөрес, адәм белән көрәшергә кирәк. Юкса ул бик начар зат, әле күптән түгел генә шул адәм дигән зат минем атамны тотып алды. Кичә бичара атамны күрдем. Чыдый алмадым, күзләремнән мөлдерәп яшьләрем агып төште. Аның өстенә әлеге адәм дигәннәре тау хәтле йөк төягән, ул гына җитмәгән, үзе дә менеп утырган. Атам дуламасын өчен, аның өске иренен тишеп өч бармак калынлыгы кылдан ургән җеп үткәргән. Әгәр дә без аңар каршы бергәләп көрәш ачмасак, безнең дә шулай өске иреннәребезне тишеп, бау үткәреп, үзенә буйсындырыр,— диде Дөя.

Ләкин дөянең сүзләре чын күңелдән сөйләнгән сүзләр түгел иде. Ул эченнән генә: «Бу бәдбәхетләрнең шулай уйланып йөрүләрен адәмгә җиткерсәм, ул атамны азат итәр дә әле, өстәвенә мине сыйлар да»,— дип уйлый иде.

Моны адәмгә җиткерү өчен вакытны кичектерергә

ярамый, нинди дә булса хәйлә табып, бу мәҗлестән китәргә кирәк. Дөя шактый уйланып торгач, Арысланга әйләнеп: «Олуг башлыгыбыз! Минем бик эчәсем килә, бик күптәннән эчкәнем юк. Әнә теге тау артындагы инешкә барып эчеп килергә рөхсәт итегез лә!» — диде.

— Яхшы, барыгыз, ләкин озак тормагыз, күп нәрсәләр тугрысында бергәләп уйлау яхшырак,— диде Арыслан.

Дөя артыннан Бүре сүз алды:

— Элек сөйләгән туганнарымның фикерләренә мин дә кушылам. Адәм дигән нәрсәнең усаллыгы турында сөйләп бетерәсе дә юк. Үткән ел мин ачка үлә язгач, бер кешенең, сарык бәтиен урларга дип, йортына кергән идем. Шунда әлеге адәм дигәннәре, сәнәк белән чәнчеп, чак кына үтермәде. Қот та калмады, көчкә котылып өлгердем. Ул гына да түгел, үләр алдыннан адәм турында бабам бер хикәя сөйләгән иде. Ул хикәя минем белән бер нәселдән булган эт тугрысында. Бабамның сүзләренә караганда, бүгенге мең газаплар күреп, көн-төн йокламыйча, хуҗасының мал-мөлкәтен саклап көн кичерә торган эт — ул минем якын кан-кардәшем икән. Борын-борын заманнарда ул да, безнең кебек, караңгы урманнарда иректә яши торган булган. Безнең белән бер телдә сөйләшкән. Бервакыт шул кардәшемне әллә ничек кенә адәм тотып алган да кулга ияләштергән һәм үзенә кешеләр алдында иң түбән санала торган «эт» дигән исем биргән. Адәм аны шул дәрәҗәгә җиткергән ки, ул үзенең туган теле булган бүре телен дә оныткан. Аның белән генә калса бер хәл иде, ул әле минем кардәшемне безгә, ягъни бүреләргә дошман итеп карарга өйрәткән. Әгәр без авылга барсак, үзебезнең кардәшләребез үк, шул этләр, безне таларга

дип, дөнья күтәрә башлыйлар. Үзеңнең кан-кардәшеңне үзеңә иң зур дошман итеп тәрбияләгән адәмне ничек дус итеп күрергә кирәк? Әлбәттә, без тупланырга тиеш, югыйсә без бу адәмнән гомер буе котыла алмабыз,—дип, Бүре сүзен бетерде.

Дөя кебек тыштан бик кызыл сөйләсә дә, ул да эчендә усал уй саклый иде.— Бу явызларның уйларын адәмгә барып сөйләп бирсәм, ул дөньяда атам, бабам татымаган рәхәтне күрсәтер. Миңа яхшы булса, башкаларның бугазларыннан алса да, бер дә исем китми, юк! —дип уйлана иде Бүре.

Дөя кебек ул да бер хәйлә эзләргә тотынды, озак та үтмәде, Арысланга карап: «Гайрәтле патшабыз! Кичәдән бирле апам авырып ята. Ул моннан ерак түгел, шуның хәлен белеп килергә рөхсәт бирсәгез, яхшы булыр иде»,—диде.

— Бар, ләкин тиз кайт,—диде Арыслан.

Үзенә чират җиткән Карга да адәмнән зарланырга тотынды:

— Миңа хәтле бик күп сүзләр сөйләнде, мин аларның барысына да дөрес дип карыйм. Адәм дигән нәрсәнең хайваннарга, кошларга кылган явызлыкларын әле әйтеп бетерә алмадылар. Без һавада очучы кошлар өчен ул нинди генә явызлык уйлап чыгармады. Белсәгез, исегез, гакылыгыз китәр! Үзегез дә беләсез: безне чабып кына тотып булмый. Борын заманда безнең бабайлар тыныч кына курыкмыйча яши биргәннәр. Көннәр үтү белән заманалар алмашынган. Адәм дә безне үз кулына кертү өчен гакыл ирешмәслек нәрсәләр уйлап чыгарган. Аңардан очып китеп кенә котылып булмый башлаган, чөнки ул безне теләсә кайдан мылтык белән атып төшерергә тотынган. Аның безгә ата торган ядрәсе зур булса иде, тагын бер хәл иде әле, ул бит безне тары ярмасы хәтле

ядрә белән атып төшерә. Бу хурлыкка ничек итеп түзәргә кирәк. Үзегез дә беләсез инде, дуслар, бу адәм дигән нәрсә көннән-көн гакыллылана, көчәя бара. Моңа каршы без бергә туплана алмасак — аның һәммәбезнең башына җитәчәген көтегез дә торыгыз! — дип туктады Ала карга.

Үзе: «Туктале, барып, болар өстенә адәмне китерим әле, моның өчен адәм мине гомерем буе бал-май эчендә тотар»,— дип уйлана иде. Ул, Арысланга әйләнеп: «Кадерле патшабыз, миңа балаларымны гына карап килергә рөхсәт итегез лә, юкса мин аларны иртәдән бирле күргәнем юк»,— диде.

Арыслан каршы килмәде. Эчендәге явызлыгы белән Карга адәмгә китте. Аланда тик көчле Арыслан белән хәйләкәр Төлке генә калды. Бүтәннәр киттеләр. Үзләренең кардәшләрен адәмгә сатарга киттеләр.

Төлке дә шул качып киткән иптәшләренең фикерендә иде. Ләкин ул элек Арысланны сынап карарга уйлады. «Арыслан да минем якка күчсә, адәм тизрәк ышаныр иде»,— дип уйлады. Һәм шул турыда Арыслан белән сүзгә кереште:

— Гайрәтле Арыслан,— дип сүз башлады,— безнең иптәшләр күп сөйләделәр, кызу сөйләделәр, аларның сүзләрен сез аңлагансызмы-юкмы, белмим, әмма мин аларның сүзләрендә ниндидер бер җинаять барлыгын сиздем, минемчә, аларның монда сөйләгән сүзләре гел алдау гына иде. Алар безне адәмгә сатмасалар ярар иде. Шуңа күрә дим, без үзебез алданрак барып ул кабахәтләрне адәмгә сатсак, яхшырак булмасмы? — дим.

Ләкин Төлке ялгышты. Арыслан андый явызлыкны эшләүдән өстен тора иде. Аның өчен үз файдаң бәрабәренә, атаң-бабаларың дошманы булган адәм алдын-

да яхшатлы булган булып, кардәшләреңне сатуга караганда, дөньяда мең газап эчендә үлүең мең мәртәбә артыграк иде. Төлкенең хыянәтчел сүзләрен ишеткәч, ул үзен-үзе өзгәләр хәлгә килде.

— Алдакчы,— дип, ул Төлкене әрләргә кереште,— мондый явыз уйлар ничек итеп синең башыңа килде? Иптәшләрең тугрысында шундый уйда булу оят түгелме сиңа?! Шундый явыз сүзләр әйтергә ничек телең әйләнә, уйлап кара, үзеңнең туганнарыңны бабайлар дошманына сатудан да кабахәтрәк эш булырга мөмкинме? Юк, мин андыйлардан түгел, хакыйкать өчен үлү минем каршымда тау күтәрүдән дә җиңелрәк,— диде Арыслан һәм, ачуына чыдый алмыйча, койрыгы белән җиргә сукты.

Арыслан белән бергә эш итүдән өметен өзгәч, Төлке, Арысланнан исән-сау котылып, үзенең элекке явыз уйларын җиренә җиткерергә юл эзли башлады һәм моның өчен хәйләгә кереште. Әүвәл Арысланга карап көлемсерәде, уфтанып алды һәм сүзгә кереште:

— Хөрмәтле Арыслан, сез инде мине гафу итегез, үземнең шаярып кына әйткән сүзләрем белән сезне шактый борчыдым. Минем кебек җүләрләр һәрвакыт урынлы-урынсыз сезнең кебек олугларны борчыйлар, зинһар, инде мине гафу кылыгыз. Мин болай шаярып кына әйткән идем. Үз кардәшләреңне дошман кулына бирү — зур кабахәтлек бит ул. Без бит шул дошманыбызга каршы бергәләп көрәшү өчен монда җыйналдык. Тукта әле, безнекеләр бик озакладылар, аларны барып чакырасы иде бит. Әгәр сез рөхсәт итсәгез, мин алар артыннан чабар идем,— диде һәм үзе тагын бер көлемсерәп алды.

Арыслан үзенең иптәшләрен көтеп калды. Төлке китте. Иптәшләреннән аерылгач, Дөя бер көн барды, ике көн барды, өч көн барды. Шулай бара торгач, ул адәм тора торган җиргә килеп чыкты.

Адәмнең тауга терәп салган йорты бик үк шәп булмаса да, бик үк начар да түгел иде. Ләкин Дөя өчен бу йорт яхшы гына түгел, әллә нинди сарайлардан да артыграк булып күренде. Ул бу өйгә бик озак карап торды. Эченнән генә үзенең дә шундый өйнең хуҗасы буласы килә иде. «Тегеләрнең серләрен ачкач, бәлки адәм миңа да шундый өй салып бирер әле»,— дип уйланып алды.

Өйнең ишегеннән Адәм килеп чыкты. Ул Дөянең кәкре-бөкре кыяфәтен күргәч, мыек астыннан гына көлеп куйды. Бу көлемсерәү Дөяне кулга төшерү өчен бер хәйлә генә иде.

— Әйдүк, әйдүк, алланың зур хайваны, сине монда нинди җилләр ташлады, килгән бер кунакка безнең ишекләр ачык, ашарсың-эчәрсең, ял иткәч, барасы җиреңә китәрсең,— диде. Адәмнең татлы сүзләре Дөяне бөтенләй эретеп җибәрде, ул серне тиз генә ачып бирергә булды:

— Рәхмәт инде, сез безне бик олуглап каршы аласыз, бәлки минем яхшы эш белән килгәнне күңелегез алдан ук сизгәндер. Мин сезне зур бәладән коткару өчен ашыгып килдем.

— Минем башка нинди бәла киләчәк, йә, тизрәк сөйләгез,— диде Адәм.

— Әйе шул, шуны әйтергә дип, монда чабып килдем, чаба-чаба тиргә батып беткәнмен.

Дөя үзе турында шулай озаклап сөйләгән булыр иде, ләкин Адәм аны бүлде: «Тизрәк сөйләгез, йөрәгем сикерә»,— диде.

— Эш менә нәрсәдә,— диде Дөя.— Арысланны беләсез бит. Ул җүләрлекнең чигенә чыккан. Ул беркөнне безне, ягъни хайваннарны җыеп, сиңа каршы котыртып маташа башлады. Бүреләр, төлкеләр, каргалар, барысы бергә тупланып, сиңа каршы сугыш

ачарга булдылар. Моны сизгәч тә, мин аннан чап та монда кил. Эчемнән генә әйтәм: «Туктагыз әле, мин сезнең болай маташканыгызны адәмгә җиткерсәм, кирәгегезне алырсыз», дим, шуннан соң белгертмәстән генә монда чап та кит!

— Ах алла! Рәхмәт сиңа, юкса алар бергә тупланып минем көлне күккә очырачаклар икән. Мондый хезмәтең өчен мин сине гомердә дә онытачак түгел. Рәхим ит, әнә синең өчен генә әзерләп куелган сараем бар, теләгәнчә шунда рәхәтләнеп гомер итәрсең,— дип, Адәм Дөяне бер пычрак кына абзарга кертеп бикләп куйды.

Капка алдына чыккан иде, таудан ук кебек атылып чабып килүче Бүрене күрде.

— Нихәл, туган, алла сине монда нинди бәхет белән җибәрде? — дип, Бүрене каршы алды.

— Туган түгел, атай диярсең әле. Синең өчен монда чаба-чаба җанымнан аерыла яздым. Синең, бәлки, үзеңә киләчәк бәладән хәбәрең дә юктыр. Арыслан синең өстеңә килер өчен хайваннарны гына түгел, хәтта бөтендөнья кошларын да бергә туплый. Безнең иң куркыныч дошманыбыз — Адәм. Без бергә тупланып кына аңардан котыла алачакбыз, юкса ул безне кырып бетерәчәк, кырып бетермәсә, мәңгегә үзенә кол итәчәк, ди. Дөяләр, төлкеләр, каргалар шуның сүзен хуплыйлар тагын. Тукта дим, Адәм каршында шуларның серләрен чишеп бирсәм, ул мине буш итмәс дим,— диде Бүре. Адәм көлемсерәде дә:

— Әйе, әйе, мондый зур яхшылыкны оныту мөмкинме соң, бик рәхмәт сиңа мине дус күргән өчен. Күрәм, бик арыганга охшыйсың, әйдә әле, мин сине бик яхшы гына урынга алып керим, аш-су әзерләтим, тамагың да ачыккандыр. Әнә синең кебек кадерле кунаклар өчен генә хәзерләнгән бүлмә бар, үзе якты,

һавасы саф, җил кереп тора, бераз ял итәрсез,— дип, хәйләкәр Адәм Бүрене тимер рәшәткә эченә кертеп бикләп тә куйды.

Яңадан капка алдына чыкканда, Адәмне Карга көтеп тора иде.

— Көтә-көтә арып беттем,— дип, Ала карга сүзгә кереште.— Башыгызга килгән бәладән хәбәрсез-нисез ята бирәсез, бичаракаем,— дип, Ала карга озын фәлсәфә корырга уйлаган иде дә, Адәм аны кырт кисте:

— Җитәр сәнә, зинһар, каркылдап башымны авырттырып торма. Башыңда гакылың булса, уйланырлык миең булса, сиңа «Карга» дип исем бирмәсләр иде. Исән-сау гына үз юлыңа китә бир. Иптәшләреңне сатып йөргәнче, балаларыңны туйдырсаң, мең өлеш артыграк булыр,— диде дә Адәм Карганы куып җибәрде.

Югарыдан очып китүче Карга югалырга да өлгермәде, куе куаклар арасыннан Төлке килеп чыкты. Аны күргәч тә, Адәм үзалдына болай дип уйланды: «Бу да әүвәлгеләре кебек туганнарын сатарга килгәндер. Моны да эләктереп булса, шәп булыр иде. Ләкин бусы бик хәйләкәр шул. Элеккеләре кебек тиз генә алдана торган түгел. Сакланыбрак булса да, моны да кулдан ычкындырмаска кирәк».

— Нинди фәрештәләр сине монда алып килде? Нинди бәхет җилләре монда очырды? Рәхим ит, рәхим ит! Синең кебек кадерле кунакларны еллар буенча көтеп тә алып булмый,— дип, Кеше Төлкене каршы алды. Төлкене хайваннар арасында иң зирәк, иң хәйләкәр итеп йөртәләр. Ул Адәмнең татлы сүз, ачык йөз белән каршы алуына бик исе китмәде. Төлке үзе Адәмне ничек булса да тозакка эләктереп булмасмы дип хыяллана иде. Бу Кешене, алдап, Арыслан тырнагына эләктереп булса, шушы өйләрнең хуҗасы,

һичшиксез, мин булыр идем дип уйлана иде һәм ул сүзгә кереште:

— Дуслык тойгысы йөрәгеңне яндырса, фәрештә канатына утырып түгел, дустыңны бәладән коткару өчен, аны бәхетле итү өчен җәяү дә чабасың, җаныңны фида итәсең[1].

Төлкенең бу сүзләреннән Адәм көлемсерәп куйды. Ләкин Адәм теләсә нәрсә уйласын, Төлкенең анда эше юк иде, ул һаман сөйли бирде:

— Менә шул дуслык тойгысы мине монда алып килде. Әгәр дә мин булмасам, синең көннәрең, сәгатьләрең, минутларың саналган иде. Син беләсең бит гайрәтле Арысланны, аның алдында бөтен дөнья хайваннары калтырый. Менә шул хайван синең башка җитәр өчен бөтен хайваннарны бергә тупламакчы була. Хайваннар арасында әллә нинди туганлык, кардәшлек фикерләре таратмакчы була. Мәҗлестә һәммәсе сине дошман күрәләр, сине теге дөньяга җибәрергә кирәк, дип кызу-кызу сөйлиләр. Әгәр теләсәң, мин сине шулар өстенә алып барам. Мин беләм: син коралсыз кеше түгел. Иң элек башлыклары Арысланны бетерергә кирәк. Башкалары синең өчен зарарлы түгел. Арысланнан башка сиңа каршы туплану аларның башына да кермәячәк.

Ул явыздан котылу өчен мондый хәйлә корырбыз: син шунда бер куак төбенә качып торырсың, мылтыгың, әлбәттә, хәзерләнгән булыр. Ә мин, аның янына барып: «Падишам, солтаным, сиңа бик олуг киңәш бар, бүтәннәр ишетмәсен өчен, әнә тегендәрәк китеп сөйләшсәк, бик яхшы булыр иде»,— дип чакырып, синең янгарак алып килермен. Шул арада син аны ук белән сыйларсың да, вәссәлам,— дип,

[1] *Фида итәсең* — бирәсең, корбан итәсең.

Төлке сүздән туктады. Төлке шулай сөйләнеп торганда, хәйләкәр Адәмнең тозагы әзерләнгән иде инде. Аның үзе ясаган бер рәшәткәсе бар иде. Ул рәшәткәнең ишеге бер сер белән бикләнә иде. Рәшәткәнең уртасында гына эшләнгән бер кечкенә генә өстәлгә ниндидер бер әйбер белән тисәң, ишек үзеннән-үзе шап итеп ябыла да куя. Бу рәшәткә амбар алдында тора иде. Төлкене шул рәшәткәгә эләктерер өчен Адәм ишеккә менә нинди хәйлә эшләде:

— Ай-һай, дускаем, сезгә нинди генә рәхмәтләр әйтим икән. Ничек кенә сезнең күңелегезне табыйм, нәрсә генә эшләсәм дә, күңелегезне таба алмам кебек тоела. Сезне монда калдырып, бер генә минутка өемә кереп чыгарга рөхсәт итегез лә, хатыныма тизрәк мунча ягарга, аш-су хәзерләргә кушыйм, юкса ул кунак килгәнен дә белми торгандыр әле.

Төлке капка алдында калды. Адәм, шул арада бер тавыкны тотып, рәшәткә эчендәге өстәлгә бәйләп куйды. Рәшәткәнең ишеген ачык калдырды. Төлкеләрнең тавык-кошлар яратканын ул күптән белә иде.

Тозагын рәтләп бетергәч, ишек алдына чыгып, Төлкене алып керде. Йортка кергәч тә, Төлкенең күзе әлеге тавыкка төште, күзләре ут кебек яна башлады. Адәм моны күргәч: «Ах алла! Мин бит хатыныма бер нәрсә тугрысында әйтергә онытканмын»,— дип чабып өенә кереп китте. Төлке өчен шул гына кирәк тә иде. Ул шунда ук рәшәткә эчендәге тавыкка ыргылды һәм, тозакка эләгеп, гомерлеккә тоткын булып калды.

Арыслан исә далада бер ялгызы һаман иптәшләрен көтеп тора, ди.

1915

ТИМЕРЛӘН

Тимерләннең атасы күптән үлгән. Ул вакытта аңа өч яшь кенә булган әле, шуңа күрә ул әтисен бөтенләй белми. Унбер яшь тулганда әнисе дә үлеп китте.

Тимерләннең туган авылы да бардыр, бәлки анда кардәшләре дә бардыр, ләкин малай аларның берсен дә белми. Ул әнисе үлү белән бөтенләй ялгыз, ятим калды. Инде нишләргә, урам чатына чыгып, үткән-барганнан: «Абый! Бер тиен генә бирсәнә!» — дип теләнергәме? Бу бик хурлык бит. Дөньяда хәер сорашудан да зуррак хурлыкның булмавы тугрысында анасы күп мәртәбәләр сөйләгән иде. Бу сүзләр онытылмыйлар, гомердә истән чыкмыйлар. Соң нишләргә?! Урамда кунарга ярамый. Ач та торыр хәл юк. Кайда барырга? Ярый әле, тышта көннәр җылы тора. Берничә көнне шулай ачык күк астында үткәрергә мөмкин булыр. Ашарга да бераз ипи бар. Шул арада хәлфәне табып булмасмы? Ул берәр файдалы киңәш бирмәсме, дип ул уйлана-уйлана шәһәр кырыендагы болынга китте.

Көн эссе. Күктә бер болыт та йөзми. Кошлар, канатларын салындырып, телләрен чыгарып, агач ботакларында утыралар. Утларга диеп төшерелгән сыерлар да, кызулыктан куркып, тез тиңентен су эченә кергәннәр. Әнә су кырыенда әллә ничек кенә киселми калган имән күләгәсендә көтүче карт утырган. Тимерлән аны таный. Аның бу картны әллә ничә мәртәбә күргәне дә бар, аның тугрысында күп сүзләр дә ишеткәне бар. Шунысы гаҗәп, малай аның исемен берәүдән дә ишеткәне юк, аны барысы да «көтүче карт» дип кенә йөртә. Үткән ел әнисе генә көтүче карт тугрысында бераз сөйләгән иде. Әнисенең сөйлә-

венә караганда, бу карт кайчандыр бик бай булган. Шәһәрдәге иң зур кибетләр, иң яхшы йортлар, иң кыйммәтле атлар аныкы булган. Хатыны да, балалары да булган. Ләкин ул балалар дөньяда тора алмаганнар, туган берсе берничә җомгадан соң үлә барган. Алар ирле-хатынлы бик кайгырганнар, баласыз торуы һәр икесе өчен дә бик күңелсез булган. Зур дәүләт эчендә кайгыда торган вакытта, көннәрнең берендә, ходай аларга бер кыз бала биргән. Ата-ана бик шатланганнар. Ләкин аларның икесенең дә йөрәгендә бер курку урнашкан. «Бу кыз бала да бүтәннәре кебек үлеп кенә китмәсә ярар иде»,— диләр икән. Шуңа күрә бу балага «Үлмәс» дигән исем биргәннәр. Үлмәс кыз, чыннан да, озын гомерле булган. Ул бик иркә үскән. Ата-анасы аның бөтен теләгән нәрсәсен алып кына торганнар, ул ни теләсә, шуны эшләгәннәр.

Үлмәс матур гына үсеп барганда, атасының байлыгы бетә башлаган, ахыргы көннәрендә чын фәкыйрьлектә калган. Әлеге көтүче карт шул бәхетсез Үлмәснең атасы икән.

Тимерлән, көтүче картны күргәч тә, аның янына китте. Көтүче карт изүләрен чишкән, чабатасын тукып утыра иде.

— Әс-сәламе галәйкем! — диде аңар Тимерлән.

— Ә-ү, галәйкем әс-сәлам! Шәкерт,ниләр бетереп йөрисең бу тирәдә, әллә шәһәрдән кайтып барасыңмы? — диде карт.

— Юк, бабай, шәһәрдән кайтып бармыйм,— дип сүзгә кереште Тимерлән,— кайтып барыр өчен кайтыр урының булырга кирәк, минем андый урыным юк. Шәһәрдә торыр урыным булмаганга, монда чыктым.

— Атаң-анаң юкмыни? — дип сорады карт.

— Әйе шул, бабай, атам мин бик кечкенә чагында

ук үлгән. Мин аны бөтенләй белмим. Анам моннан ике генә көн элек үлде,— диде дә Тимерләннең күзләренә яшь тыгылды. Җисәк кенә тавышы киселде һәм иреннәре калтырый башлады. Ләкин малай күзләренә тыгылган яшьләренә ирек бирмәде, аларны йотарга тырышты.

— Ә, алай икән,— диде бабай,— ата-анасыз икәнсең, кардәшләрең дә юкмы?

— Белмим, бәлки бардыр, мин беркемне дә белмим, шәһәрдә бер кардәшем дә юк.

— Соң син кайда торасың? — диде карт.

— Хәзергә һичбер торыр урыным юк.

— Әй, бәхетсез бала, бәлки синең ашыйсың килә торгандыр. Менә минем бераз икмәгем бар, әнә шул кувшинда бераз әйрән дә калган иде бугай, шуны да эчеп җибәр.

— Рәхмәт, бабай, минем әле үз ипием дә бар бераз. Рәхим итсәң, менә әйрәнеңне берничә йотым эчәр идем, бик сусаганмын,— диде Тимерләнһәм тар муенлы кувшиннан әйрәнне эчә башлады. Артык сусаган булганга, әйрәннең һәр тамчысы аның җанына рәхәтлек бирә иде, ул бөтенләй терелеп киткән кебек булды, бөтен тәнендә бер салкынлык сизде.

Әйрәнне эчеп туйгач, көтүче картка чын күңеленнән рәхмәтләр укыды.

— Яхшы, балам, аш булсын, мин бит әле синең исемеңне дә сораганым юк. Исемең кем соң синең?

— Минем исемем, бабай, Тимерлән.

— Бик яхшы, угылым, мин карт кеше инде, күп кеше минем белән сөйләшми, бер сөйләшик әле синең белән.

Тимерлән утырды. Бабайның тотлыккан тавыш белән сөйләшеп утыруы аңар күңелле иде.

— Рәхмәт, бабай, сезгә,— диде Тимерлән, артык

бер сүз дә әйтә алмады. Аның уйлары әллә кайда, еракта йөриләр иде.

— Менә, балам, минем бер малаем бар иде. Мин инде үзем бик карт, хайваннар артыннан чабып йөри алмыйм. Әлеге малай ут кебек чабып йөри иде. Миңа бик булыша иде. Кичә генә әбисе килеп аны авылга алып китте. Бөтенләй кулсыз калдым. Шул малай урынына миңа бер бала кирәк иде. Шундый баланы син белмисеңме, угылым? — диде көтүче карт. Бу сүзгә Тимерлән шатланып китте: «Бәлки, үзем шул урынга ярармын», дип уйлап куйды. Шулай булса да, ул бу турыда бабайга әйтергә яхшысынмады. Бераздан соң акрын гына, куркып кына сүзгә кереште:

— Юк, бабай, мин балаларны күп белмим, мәктәптә бергә укыган иптәшләремнең берсе дә бу урынга килмәс дип уйлыйм. Алар барысы да аталы, хәлле кешеләр. Үзем бу урынга ярамас идемме? Мин ятим, барып керер урыным юк. Сез риза булсагыз, мин бик тырышып хезмәт итәр идем,— диде. Шул сүзләрне әйтеп бетерүгә, Тимерләннең өстеннән зур бер тау төшкән кебек булды. Ул җиңеләеп китте.

— Ник ярамассың? Монда эш алай бик авыр түгел. Ачык һавада көтүне бер урыннан икенче урынга күчереп йөрүдән башка эш юк. Көн уртасында көтүне шушы су янына алып киләсең. Кояш түбәнгә таба киткәч, көтүне яңадан кырлар, болыннар буенча алып барасың. Кич җиткәч, шәһәргә кайтырбыз. Анда минем кечкенә генә фатирым бар. Шунда бергә торырбыз. Эшкә өйрәнәсең килсә, чабата тукырга өйрәтермен. Көз җиткәч, тубаллар ясарбыз. Хәзер әле чыбык бик яшь, тиз сына. Көзен халык ашлык суга, бәрәңге, кыяр, шалкан җыя. Менә шул вакытта тубалларны җиткер генә.

Тимерләннең күзләрендә инде күптән шатлык нуры

яна иде. Урам малае булып, узган бер кешедән теләнеп йөргәнче, бер эш эшләү аның өчен мең өлеш артык иде. Тимерлән көтүче картка малай булып керде. Чабата тукый белү дә хурлык түгел. Инде хәзер хәлфәгә дә барырга кирәкми. Күз җиткәч, барып, аның белән бер киңәшермен әле дип уйлады Тимерлән. Шул көннән башлап ул көтүче малае булып китте.

1915

НИ ӨЧЕН КИТ БАЛЫГЫНЫҢ БУГАЗЫ ТАР?

(Инглиз мөхәррире Киплингтан) [1]

Борын-борын заманда зур диңгездә йөзеп йөргән ди бик зур Кит балыгы. Аның ашар ашы зур һәм кечкенә балыклар булган ди. Очраган балыкларны «хап!» иттереп йотып кына җибәрә икән ди. Шуңа күрә диңгездә балыклар бетеп, бер генә балык калган ди. Бу балык бик кечкенә, бик шаян, хәйләкәр икән ди. Кит үзен йотып җибәрмәсен өчен, ул аның уң колагы яныннан гына йөзеп йөри икән ди.

Балыклар калмагач, Кит, койрыгын күтәреп:

— Мин ач! Ашыйсым килә,— дип кычкырган икән, шунда аның уң колагы яныннан гына йөзеп йөрүче теге Кечкенә хәйләкәр аннан:

— Синең адәм ите ашаганың бармы? — дип сораган ди.

— Юк, адәм ите ашаганым юк,— дигән ди Кит балыгы,— нинди ул адәм ите? — дип сораган ди Кечкенә балыктан.

---

[1] *Киплинг Джозеф Редьярд* (1865—1936) — күренекле инглиз язучысы, шагыйрь, прозаик, әкиятче.

— Бигрәк тә тәмле инде ул адәм ите, ләкин ул адәм дигәннәре бигрәк тә гакыллы һәм чиксез шаян нәрсә диләр, бер генә дә бер урында тора алмый диләр,— дип җавап биргән Кечкенә балык.

— Алай булса, син миңа берничә адәм табып бир,— дип әйткән ди Кит балыгы һәм үзе койрыгы белән суга шулкадәр каты бәрде ди, зур диңгезнең асты өскә килердәй булып кайнап китте ди.

— Хәзергә берсе дә җитеп торыр. Әйдә әле, алга таба йөзәбез, моннан ярты көнлек юлда, диңгез уртасында кечкенә генә сал өстендә агып барган бер адәмне очратырбыз. Аның өстендә чалбары, кызыл путасыннан башка фәкать бер зур пычагы гына бар (сөекле бәбкәем, кызыл путаны хәтереңнән чыгара күрмә). Бу кеше диңгездә барганда баткан пароходтан котылып калган, ә иптәшләре һәммәсе батып үлгәннәр. Тагын да әйтим сиңа, ул бик гакыллы, бик зирәк кеше,— дип өстәгән Кечкенә балык.

Озак та үтмәде, Кит Кечкенә балык әйткән җиргә барып та җитте. Дөрестән дә, әлеге кеше нәкъ Кечкенә балык әйткәнчә киенгән иде: күк чалбар, кызыл пута, бер зур пычагы бар. Сал кырыена утырган да аякларын суга тыгып, шаярып, суны бутап утыра.

Менә шул вакыт Кит балыгы үзенең зур авызын ачарга тотынды ди, әй ача, әй ача! Шулай ача торгач, өске ирене аз гына койрыгына җитмәде ди.

Озак та үтмәде, сал кырыенда аяклары белән суны чәчрәтеп шаярып утыра торган кешене Кит балыгы йотып та җибәрде ди. Әлбәттә, аның чалбарын да, зур пычагын да, кызыл путасын да калдырмады ди, алар барысы да хуҗалары белән бергә Китның ашказанына керделәр дә югалдылар ди. Кит балыгы шатлыгыннан берничә мәртәбә авызын чапылдатып алды да, койрыгын өскә күтәреп, өч мәртәбә әйләнеп китте

ди. Теге кеше Кит корсагына эләккәч тә дөнья куптарырлык итеп дулый башлады ди. Әй кычкыра, әй сызгыра, әй сикергәләнә, әй бии-җырлый башлады ди!

Бичара Кит инде бу кешене йотуына үкенә дә башлаган.

— Дөрестән дә, бу адәм дигәннәре бер җирдә генә тора белми икән, мине укшыта башлады, инде ничек бу бәладән котылырга? — дип Кечкенә балыктан сораган.

— Син аңар, аннан чык, дип әйт, — дигән Кечкенә балык.

— Әй, кара әле, чык әле син аннан, — дип, үз корсагына карап кычкырган ди балык, — сине йотканнан бирле укшыта башлады, — дип тә өстәгән.

— Юк, аппагым! Мин тиз генә чыгучылардан түгел, минем чыгуны теләсәң, син мине туган илем Албиун[1] янындагы ак таулар янына илтерсең. Әнә шунда барып җиткәч, мин уйлап карармын! — дигән кеше һәм шуннан соң тагын да көчлерәк итеп бии-җырлый, кычкыра башлаган. Китның уң колагы янында гына йөзеп йөрүче Кечкенә балык әйткән:

— Шулай шул, олуг хайван, бу кешедән котыласың килсә, аның теләгәнен эшләргә тиешсең.

— Инде нишләмәк кирәк? Бу кешенең теләгәнен эшләми чара булмастыр, ахыры, — дип, Кит балыгы уйга калган.

Бераз үзалдына уйлангач, ул бар көче белән йөзәргә керешкән, әй йөзә, әй йөзә, аткан ук та аның артыннан җитә алмас.

Йөзеп бара торгач, кешенең туган иле Албиун

---

[1] Англияне борын заманда *Албиун* дип йөрткәннәр. *(Ф. Агиев.)*

кырыена да килеп җиткәннәр. «Килеп җиттек»,— дип кычкыру белән, балык эчендәге кеше атылып килеп тә чыкты ди. Ләкин бу кеше чыгып китү белән генә эш бетмәде. Әле балык карынында чакта ул үзенең зур пычагы белән сал агачларын кискәләде дә аларны чалбар путасы белән бер-берләренә нык кына бәйләп бер рәшәткә эшләде дә рәшәткәне бик һәйбәтләп кенә Китның бугазына беркетеп куйды. (Менә инде чалбар путасын хәтердә тотуның файдасын белдеңме?)

Балык эченнән чыккач, безнең кешебез рәхәтләнеп әнисе янына кайтып китте. Әнисен ул бик ярата иде.

Өенә кайтканнан соң ул өйләнде һәм хатыны белән бик бәхетле генә тора башлады.

Бу кешедән аерылгач, Кит балыгы да бик рәхәтләнеп китте. Әмма инде теге рәшәткә аның бугазында мәңгелеккә урнашып калды. Ул бу рәшәткәне йөткереп чыгарып ташларга да теләп карады, йотып та карады, ләкин чыгара алмады. Шуңа күрә ул, ашыйсы килгәндә, иң кечкенә балыкларны гына ашый ала торган булып калды.

Менә шуның өчен хәзерге кит балыклары зур кешеләрне дә, кечкенә балаларны да йота алмыйлар ди. Шушы вакыйгадан соң Китның уң колагы янында гына йөзеп йөрүче Кечкенә балык та әллә кая качты ди. Ул Китның ачулануыннан курыкты булса кирәк.

Теге кеше өенә кайтканда зур пычагын да үзе белән алып кайтты, күк чалбары да балык эчендә калмады, чөнки ул аны кигән иде. Фәкать путасы белән нәрсә бәйләп калдырганны син, бәлки, хәтереңнән чыгармагансың әле, кадерле укучым! Менә шуның белән әкият бетте.

1915

ҖИЛ АРБА[1]

(Халык әкияте)

Борын-борын заманда җиде тауның артында, җиде суның янында, җиде юлның чатында яшәгәннәр ди бер карт белән карчык.

Болар үз кул көчләре белән гомер иткәннәр. Берәүгә дә тимәгәннәр, берәүгә дә усал сүз әйтмәгәннәр. Йомыш белән кергәннәрне кире борып чыгармаганнар, ялган сүз сөйләмәгәннәр, булдыра алмаслык эшкә керешмәгәннәр, шуның өчен аларны һәммә кеше яраткан ди.

Карт белән карчыкның җиде улы һәм бердәнбер кызлары булган ди. Угыллары үсеп җиткәч тә, ата-аналары белән саубуллашып, бәхет эзләргә чыгып киткәннәр ди. Ә үзләре янында алтын алмадай матур кызлары Җилбикә генә калган ди.

Угылларының чыгып киткәннәренә җиде ел тулып үтсә дә, бер хәбәрләре дә булмаган ди.

Угылларының чыгып китеп югалуы карт белән карчыкны бик пошындырса да, Җилбикәгә карап, алар кайгы-хәсрәтләрен оныталар, ярсыган күңелләрен юаталар икән ди. Җилбикәнең дә бертуган абзыйларын күрәсе, алар белән сөйләшәсе, аларга иркәләнәсе килә икән ди.

Бер дә беркөнне эче пошып, абзыйларын сагынып утырганда Җилбикә шундый җыр чыгарган ди:

Абзыйларым, җаннарым,
Минем алтынкайларым.
Кайда, кайда очтыгыз,
Нинди сулар кичтегез?

---

[1] Фәхрелислам Агиевның 1926 елда чыккан «Хикәяләр җыентыгы»ннан кыскартып алынды.

Нинди таулар артында,
Нинди җиргә җиттегез?
Нинди хәсрәт чиктегез?
Нинди сулар эчтегез,
Җиде елның эчендә
Нинди бәхет таптыгыз?

Җилбикә шулай моңаеп җырлап утырганда, аның янына атасы килгән дә:

— Матуркаем, Җилбикәм, сиңа ни булды, ник болай моңаеп утырасың? — дип сораган.

— Әтием, җаным, абзыйларымны сагындым, күңелем ташыгач җырлап җибәрдем. Кайда соң минем абзыйларым, аларны күрәсем килә,— дип җавап биргән ди.

— Ай-һай, кызым, башыңа юк уйлар кергән икән. Абзыйларыңның кайда икәнен мин дә белмим, алар моннан җиде ел элек, безнең белән саубуллашып, бәхет эзләргә чыгып киткәннәр иде, шуннан бирле бер хәбәрләре дә юк. Без дә анаң белән аларны сагынып кайгырабыз, кайгырабыз да, сиңа карап, күңелебезне юатып торабыз,— дигән ди атасы.

Атасының сүзләре генә Җилбикәне тынычландыра алмаган. Ул һаман абзыйлары турында уйлана, алар белән күрешер өчен төрле юллар эзли, кайгысыннан күз яшьләрен түгә икән. Бик озак уйлана торгач, кыз утырган җирендә йокыга киткән. Йоклар алдыннан:

— Ичмасам, абзыйларымны төшемдә генә булса да күрергә насыйп булсачы,— дип әйткән ди һәм төш күргән ди.

Җилбикәнең төше

«Өнеңдә уйлаганны төшеңдә эшлисең», дигәннәр картлар. Җилбикә дә шулай. Күне буе абзыйлары турында уйлап йөргәнгә, төшендә дә аларны эзли икән. Кырлардан, урманнардан, болыннардан, шәһәрләрдән эзләп йөри икән.

Бер атна эзләгән, бер ай эзләгән, һаман да абзыйларын таба алмаган. Шулай йөри торгач, ул бер тау тишеге янына килеп чыккан.

— Туктале, бу тау тишеге бушка гына уелмагандыр, монда берәр сер юк микән? — дип, Җилбикә тау тишегенә, эчкә кергән ди.

Анда ни күзе белән күрсен, ап-ак сакаллы, ап-ак киемле бер бабай, алдына зур китап ачып куеп, йомшак мамык мендәр өстендә утыра ди. Җилбикә башта куркынып киткән. Тик бабайның:

— Хуш килдең, кадерле кунагым, әйдүк, әйдүк. Үзем дә әле адәм баласын күрәсем килеп, бик сагынган идем. Хуш килдең дип, ачык йөз, йомшак сүз белән каршы алгач, Җилбикәнең куркуы бөтенләй беткән ди.

— Исәнме, бабакаем, нишләп монда утырасың? — дип сүз башлаган ди Җилбикә.

— Бик сәламәт, балам, бик сәламәт. Китап карыйм, гыйлем эзлим. Син нинди йомыш белән йөрисең, кызым, сине нинди җил ташлады монда? Сөйлә, кызым, сөйлә, бер дә тартынма. Кайгың булса, уртаклашырмын, йомышың булса, ярдәм итәргә тырышырмын,— дигән ди бабай Җилбикәгә.

Җилбикә бабай янына якын ук килгән дә аңа үзенең теләген, кайгысын сөйләгән.

— Ай-һай, балам, теләгең зур икән, шулай булса да ирешмәслек түгел. Син, балам, өеңә кайт та, әт-

кәҗнән җиде канатлы җил арба эшләт. Шул арба эшләнеп беткәч, аңар син мин өйрәткән җырны җырларсың. Шуннан соң арба күтәрелеп очып китәр, сине абзыйларың тора торган җиргә илтер,— ди бабай.— Инде, кызым, өеңә кайтсаң да ярый. Юкса әти-әниләрең борчылыр, минем дә вакытымны алма. Әле укыйсым күп. Бушка үткәргән вакытны сатып алып булмый. Бар, балам, бәхетле бул,— дип әйткән ди.

— Нәрсә соң ул бәхет, бабам? — дип сораган Җилбикә.

— Бәхет — берәр һөнәрнең хуҗасы булу ул, кызым. Берәр һөнәрең булса, син бәхетле, бер нәрсә дә белмәсәң, син бәхетсез. Шуңа күрә борынгы картлар: «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми»,— дигәннәр. Бабайлар сүзне бер дә уйламыйча сөйләмәгәннәр, балам,— дигән бабай.

Шул вакыт Җилбикәне әнкәсе иртәнге чәйгә уяткан, аның төшен шул җирдә бүлгән.

Чәй янында Җилбикә әтисеннән:

— Әтием, син миңа җиде канатлы җил арба эшләт,— дип сораган.

— Нигә ул сиңа җиде канатлы җил арба? Аның белән нишләмәкче буласың?

— Абзыйларым бәхет эзләргә киткәннәр, ә мин, шул арбага утырып, аларны эзләргә барам, зинһар, эшлә инде, әтием,— дигән Җилбикә.

— Ярар, балам, алай булса эшләрмен,— дигән ди әтисе.

Әти кеше җиде төн эчендә җиде канатлы җил арба эшләгән. Җилбикә исә күрше кызы Сылубикәне чакырып, бүләкләр әзерләгән, җиде күлмәк, җиде ыштан теккән, җиде сөлге чиккән. Шуннан соң, әти-әнисе белән саубуллашып, Сылубикәне юлдашлыкка алып, икәү җил арбага утырганнар да:

Әй, җил арба, җил арба,
Җиде агайга барамын,
Җиде агайга барамын,
Җиде күлмәк илтәмен,
Җиде ыштан илтәмен,
Җиде сөлге илтәмен,
Кузгал, арбам, оч, арбам,
Канатларың как, арбам,
Җиде көннең эчендә
Абзыйларны тап, арбам! —

дип җырлый-җырлый очып киткәннәр ди.

Җилбикә белән Сылубикә бертуктамый алты көн, алты төн очканнар, җиденче көннең таңында, агымсуның янында коенырга дип, җил арбаны туктатканнар. Туктатканнар да су коенырга кергәннәр.

Җилбикә яхшы күңелле, эчкерсез кыз булган. Эчендәге серләрен барысын да Сылубикәгә сөйли икән.

Сылубикә исә үги ана кулында кысылып, җәберләнеп үскән, ул усал, зәһәр, икейөзле кыз булган, бик көнче дә, алдакчы да икән. Су коенганда менә нәрсә уйлаган: алты төн, алты көн килдек инде. Бүген җиденче көн. Җилбикәнең абзыйлары янына барып җитсәк кирәк. Бәхет эзләргә киткән абзыйлары янында Җилбикә дә бәхетле булыр. Ә мин һаман элеккечә бәхетсез булып калачакмын. Туктале, тизрәк судан чыгыйм да, Җилбикәнең киемнәрен киеп, җил арбага утырып, бер үзем генә очып китим әле. Ләкин эш Сылубикә уйлаганча барып чыкмаган. Арбаны урыныннан кузгатыр өчен теге бабай өйрәткән җырны әйтергә кирәк, ә Сылубикә аны белми бит. Шулай да ул үз уеннан кайтмаган. Куркытып, көчләп Җилбикәгә үзенең киемнәрен кидергән, куркытып, аңардан теге серле җырны әйттергән, арба тагын күтәрелеп очып киткән.

Көн уртасында кызлар бер шәһәргә барып җиткәннәр, Җилбикәнең абзыйларын эзләп тапканнар.

Җилбикәнең абзыйлары, Сылубикәне үзләренең сеңелләре дип белеп, аны иркәлиләр, яңа киемнәр тектерәләр, энҗе-калфак эшләтәләр, үзләре белән бергә тәмле ризыклар ашаталар, баллы чәйләр эчерәләр икән ди.

Җилбикәне начар ашаталар, үзләре эшкә киткәндә тары сакларга калдыралар, аның ашый торган савыты да ватык чүлмәк төбе икән ди.

Сылубикә уйный, көлә, Җилбикәгә: әгәр абзыйларыңа дөресен әйтсәң, кара аны, минем усаллыкны күрерсең дип, аны гел куркытып тора ди. Җилбикә куркуыннан авызына су капкан кебек бер нәрсә дә дәшми, тик, ялгыз калганда, тары саклаганда гына, үзенең моң-зарларын күктә очып баручы торналарга гына җыр итеп җырлый икән ди.

Очыгыз, торналар, очыгыз,
Безнең кырга барыгыз.
Минем карчык анамны,
Зинһар, эзләп табыгыз.
Табыгыз да әйтегез:
Кызың тары саклыйдыр,
Абзыйларын тапса да,
Чирәбтән[1] аш ашыйдыр.

Бер дә көтмәгәндә, ниндидер эш белән, Җилбикәнең җиденче абзыйсы өйгә кайткан булган. Ул сеңлесенең җырлавын ишеткән. Бу бала бер дә юкка офтанып җырламый торгандыр. Туктале, бу турыда абзыйларыма да әйтим әле, дип уйлаган да ди, әйткән ди.

Эшнең дөресен белер өчен җиде абзыйсы, Җилбикәне яннарына чакырып, аңардан башыннан үткән-

---

[1] *Чирәб* — кызыл балчыктан ясалган савыт.

нәрнең барысын да сөйләткәннәр. Эшнең төбе беленгәч, аларның Сылубикәгә бик ачулары килгән. Кылган усаллыклары өчен аны өйрәтелмәгән ат койрыгына бәйләп җибәрмәкче булганнар, ләкин Җилбикә моңа риза булмаган, абзыйларына әйткән:

— Абзыйларым, минем юлдаш иптәшемне кыерсытмагыз, Сылубикәгә минем һич үпкәм юк,— дигән.

— Усаллыклары өчен аны нишләтик соң? — дип сораганнар абзыйлары.

— Мине дә, Сылубикәне дә бертигез бәхетле итегез, үзегез белгән һөнәрләрегезне безгә дә өйрәтегез,— дигән Җилбикә.

— Ай-һай, сеңлем, теләгең изге икән. Әйдә, алай булса, Сылубикә безнең икенче сеңлебез булсын. Икегезне дә бәхетле итик, икегезне дә һөнәр мәктәбенә бирик, белемле дә, һөнәрле дә, бәхетле дә булырсыз,— дигән ди олы абзыйсы Җилбикәгә.

Һөнәр мәктәбен бетергәч, Җилбикә белән Сылубикә эти-әниләре янына кайтканнар ди. Әле дә булса матур гына яшәп яталар ди. Шатлыкларыннан зур мәҗлес кордылар ди. Мәҗлестә мин дә булдым. Ике чынаяк чәй ашадым, бер телем икмәк эчтем. Сезгә күчтәнәч алып кайткан идем, кесәм тишек булганга, юлда төшеп калган.

1926

ЭЧТӘЛЕК

Төзүчедән 3
Аның шатлыгы 5
Шатлык эчендә кайгы . 10
Мин шатлана алмыйм! . 13
Ялгыз кабер 15
Кечкенә карак 22
Фатиханың яшерен сере 23
Кечкенә Гайшәнең бүләкләре 26
Күбәләк 31
Гармун 36
Ике җирдә ике — дүрт (швед халык әкиятеннән) 41
Ни өчен дөянең аркасына бүкән үскән? . . 47
Зур сугыш 51
Булдыклы табиб . . . 57
Сәмруг һәм май коңгызы 63
Сукыр Ильясны без һаман да күрә алмый идек 64
Куяннар 77
Кыз-патша (Кыргыз әкияте. Әбүбәкер Диваевтан) 80
Берлектә — тереклек . . 86
Тимерлән 97
Ни өчен кит балыгының бугазы тар? (Инглиз мөхәррире Киплингтан) . 101
Җил арба (Халык әкияте) 105

Кече яшьтәге мәктәп балаларына

Агиев Фәхрелислам Нигматуллович

МИЛОСЕРДИЕ

(рассказы и сказки)

(на татарском языке)

Редакторы *И. Зәлкарнәева*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Р. Ильясова*
Корректорлары *Ф. Гыйниятуллина, Т. Шакирова*

ИБ № 5690

Җыярга тапшырылды 30.01.90. Басарга кул куелды 29.10.90. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Типогр. кәгазе № 1. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 7,0. Шартлы буяу-оттиск 14,5. Нәшер-хисап табагы 4,62. Тиражы 28 000 экз. Заказ Л-44. Бәясе 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарстан ССРның Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

20 тиен